КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ЛЕВ ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА
БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ
Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАРИСТИКА ҺӘМ ТЮРКОЛОГИЯ
ЮГАРЫ МӘКТӘБЕ
ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕ КАФЕДРАСЫ

Белгечлек: 44.04.01 «Педагогик белем бирү»
(квалификация (дәрәҗә) «магистр»)

МАГИСТЕРЛЫК ДИССЕРТАЦИЯСЕ

# РУС МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП, АЛМАШЛЫКЛАРНЫ ӨЙРӘТҮНЕҢ ЛИНГВОДИДАКТИК НИГЕЗЛӘРЕ

Эш төгәлләнде:
«    » ________________ 2018 ел _______________ А.Х.Шәехова

Эш яклауга тәкъдим ителде:
Фәнни җитәкче
филология фәннәре кандидаты, доцент
«    » ________________ 2018 ел ______________ Х.Х.Кузьмина

Кафедра мөдире
филология фәннәре докторы, профессор
«    » ________________ 2018 ел ____________ Г.Р. Галиуллина

Казан – 2018

**Эчтәлек**

**Кереш**.........................................................................................................3

**I бүлек. Алмашлыкларны өйрәнү тарихы һәм аларның мәктәп программасындагы урыны**.......................................................10

1.1. Алмашлык сүз төркемен өйрәнү тарихы..........................................10

1.2.Хәзерге программа һәм дәреслекләрдә алмашлык сүз төркемен өйрәтүнең торышы.............................................................................................43

**II БҮЛЕК. Рус мәктәпләрендә укучыларга алмашлыкны уен технологияләре кулланып өйрәтү нигезләре**...............................................51

2.1. Яңа педагогик технологияләрнең берсе буларак уен технологиясе.........................................................................................................51

2.2. Фонетик уеннар.........................................................................................62

2.3. Лексик уеннар...........................................................................................70

2.4. Грамматик уеннар.....................................................................................81

2.5. Рольле уеннар............................................................................................97

**ЙОМГАК**......................................................................................................105

**Кулланылган әдәбият исемлеге**..........................................................108

## КЕРЕШ

**Теманың актуальлеге.** Бүгенге көндә без үзгәрешләр чорында яшибез. Җир шарының төрле өлкәләрендә барган үзгәрешләр безнең тормышыбызга көннән-көн ныграк тәэсир итә бара. Җәмгыятьнең социаль-икътисади һәм рухи өлкәләрендә барган глобаль үзгәрешләр мәгариф эчтәлегенә дә яңа төсмерләр кертә, яңа таләпләр куя, аның үсешенә яңа юнәлешләр билгели. Бу исә заман мәктәбе укучыларга билгеле бер дәрәҗәдә белем бирү белән генә чикләнмичә, аларны мөстәкыйль рәвештә даими белем тупларга, һәрьяклап үсешкә ирешергә, үз-үзе белән идарә итә белергә, җәмгыятьтәге мөһим процесслар турында хәбәрдар булырга өйрәтергә тиеш дигән сүз.

Мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын нәтиҗәле укыту – бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Укытучы буларак, безнең төп максатыбыз – замана таләпләренә җавап бирә торган, тормышта үз юлын табарга сәләтле, иҗади, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү, аларны хезмәттәшлеккә өйрәтү, чөнки бүгенге көндә яшүсмерләр арасында сүлпәнлек, битарафлылык, белмәгәнне белергә теләмәү, матур әдәбият укудан бөтенләй бизү, яхшылыкны күрергә теләмәү кебек кире сыйфатларның көчәюе сизелә. Шуңа күрә без балаларга теоретик белем генә биреп калмыйча, аларның алган белемнәрен тормышта куллана белүләренә зур игътибар бирәбез.

Белем бирү эшен үзара хезмәттәшлек шартларында оештыру – тәрбияләүнең төп ысулы. Мөгаллим һәм балаларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә шәхеснең ихтыяҗы һәм сәләте тулысынча ачыла. Бу очракта укытучы да, укучы да бер-берсенең ярдәмчесе, киңәшчесе булырга тиеш. Белгәнебезчә, яңа дәүләт стандартларында дүрт эшчәнлеккә өстенлек бирелә: шәхси, регулятив, танып-белү эшчәнлеге һәм коммуникатив эшчәнлек. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә. Укытучы алдында яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып, аны үзләштерү зарурлыгы

туды. Хәзерге уку-укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган уен технологиясе алып тора. Укучыларга белем бирү, тәрбияләү процессында уен технологиясен куллану мәгълүматны кабул итү, игътибарны көчәйтү, хәтер һәм интеллектны үстерүдә югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирә; образлы кабул итү аша кешенең ми эшчәнлеген, уйлау сәләтен активлаштыра.

Сүз төркемнәре арасында алмашлыклар аерым урын алып тора. Бу сүз төркеме исем, сыйфат, сан, рәвеш һәм фигыльләрне алыштырып, алар урынында кулланыла. Алмашлык бу сүз төркемнәренең мәгънәләрен турыдан-туры белдерми, ә аларга ишарә итә, алыштыра. Сөйләмдә аларның роле гаять зур, чөнки алмашлыклар бер үк сүзне кабатлаудан коткара, сөйләмне стилистик яктан шомарта, җыйнакландыра, матурлый. Шуңа күрә аларны ныклап өйрәнү аеруча әһәмиятле. Алмашлыкларның өйрәнелү тарихы, мәктәптә уку-укыту барышында алардан уңышлы файдалану, сөйләмдә алмашлыкларны урынлы куллану, ныклы күнекмәләр булдыру, дөрес язарга өйрәтү – мөһим мәсьәләләрдән санала. Мөстәкыйль сүз төркеме буларак алмашлыклар киләчәктә дә ныклап өйрәнүне һәм үстерүне сорый. Шуларны истә тотып, мин бу хезмәтемдә рус төркемнәрендә белем алучы укучыларга алмашлык сүз төркемен өйрәтүдә уен техгологиясен урынлы һәм нәтиҗәле файдалану юнәлешләрен күрсәтергә тырыштым.

Хезмәтнең **төп тикшерену проблемасы** – татар телен дәүләт теле буларак укытканда алмашлыкларны өйрәнүнең лингводидактик нигезләре һәм заманча технологияләрен (уен технологиясен) билгеләү.

**Тикшеренүнең максаты** – рус мәктәбенең татар һәм рус төркемнәрендә алмашлыкларны өйрәтүнең лингводидактик нигезләрен ачыклау һәм аларны уен технологияләре белән бәйләп өйрәтүнең алымнарын билгеләү.

**Тикшерену объекты** − татар телен дәүләт теле буларак укыту барышында алмашлыкларны өйрәтү процессы.

**Тикшеренү предметы** − гомуми белем бирү оешмаларында алмашлык сүз төркеменә өйрәтүнең яңа технологияләре.

Куелган максатка мөнәсәбәтле рәвештә, тикшеренүнең түбәндәге **бурычлары** билгеләнде:

1. Татар тел белемендә алмашлыкларны өйрәнүнең тарихына күзәтү ясау;

2. Татар теле дәресләрендә алмашлык сүз төркеменнең хәзерге программа һәм дәреслекләрдә бирелешен ачыклау;

3. Уен технологиясе турында мәгълүмат туплау;

4. Алмашлык сүз төркемен өйрәтүдә уен технологиясен куллану мөмкинлекләрен ачыклау.

Тикшеренүнең **методологик нигезен** алмашлык сүз төркемен тикшергән хезмәтләр, тел һәм аны укыту методикасы буенча уздырылган фундаменталь тикшерүләр, рус мәктәпләрендә укыту программалары һәм татар теле дәреслекләре тәшкил итә.

Хезмәтнең теоретик базасын түбәндәге тикшерүләр тәшкил итте:

- сүз төркемнәренең бүленеше буенча теорияләр (А.Казембек, К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Г.Алпаров, В.Н.Хангилдин, З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, Д. Г. Тумашева һ.б.)
- «алмашлык» терминының башка атамаларының өйрәнелеше (М.Корбангалиев, Х.Бәдигый, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Л.Җәләй, Г.Нугайбәк һ.б.)
- алмашлыкның төркемчәләргә бүленеше (Ч.М.Харисова, Ф.С.Сафиуллина, Д.Г.Тумашева, З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, Җ.Вәлиди, Г.Алпаров, В.Н.Хангилдин, Ф.М.Хисамова);
- уен технологиясе буенча теоретик мәгълүмат (Ф.Ф.Харисов, Б.Г.Лихачев, В.П.Беспалько, М.А.Чошанов, С.Х.Айдарова, Г.К.Селевко һ.б. );
- татар теленә өйрәтү теориясе һәм методикасы (Ф.С.Валеева, З.М.Валиуллина, Г.Р.Галиуллина, М.Ш.Галлямова, М.З.Зәкиев,

Д.Г.Тумашева, Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Ф.М.Хисамова, Р.Р.Җамалетдинов, М.М.Шәкүрова, Р.А.Юсупов һ.б.).

**Тикшеренү методлары һәм алымнары.** Укучыларга татар теленең морфология бүлеген өйрәнү аеруча зур кыенлыклар тудыра, чөнки фәннең бу тармаклары аңлау өчен дә, гамәлдә куллану өчен дә укучы тарафыннан чагыштырмача авыррак үзләштерелә. Шуңа күрә дә татар теле морфологиясен укыту методикасына багышланган хезмәтләрнең булуы зур әһәмияткә ия, укытучыга белем бирү процессын оештыруга булышлык итә. Морфологияне укыту ысулларын билгеләү максаты белән, тикшеренү барышында түбәндәге метод һәм алымнардан файдаланылды: ысулларны тикшереп анализлаганда – *тасвирлама*; темага кагылышлы тарихи материалны төрле яклап системалы тикшергәндә – *тарихи-этимологик;* элеге теоретик өйрәнүләрне чагыштырып өйрәнгәндә – *чагыштыру* ысулларын методларны кулландык.

**Тикшеренү базасы** – Казан шәһәре Авиатөзелеш районының 36 нчы гимназиясе. Фәнни хезмәтне язу барышында әлеге гимназиядә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләү тәҗрибәсенә таяндык.

**Тикшеренү этаплары.**

Беренче этап – **эзләнү**: тикшерелгән проблема буенча булган фәнни әдәбиятка теоретик анализ ясау; алмашлыкларны өйрәнүнең тарихын ачыклау, тикшеренүнең темасын, максатын, объектын, предметын һәм методларын ачыклау; татар теле буенча кулланылышта булган программа, дәреслек һәм укыту кулланмаларына лингводидактик анализ ясау; укучыларның «Алмашлык» темасы буенча алган белем, күнекмәләрен өйрәнү.

Икенче этап – **төп**: татар теле дәресләрендә алмашлыкларны өйрәнүнең эчтәлеген теоретик һәм гамәли рәвештә дәлилләү; заманча технологияләрне (уен технологиясен) куллану.

Өченче этап – **тәмамлау һәм гомумиләштерү**: фәнни эшне гомумиләштерү, нәтиҗәләр формалаштыру, диссертацияне язып бетерү.

**Тикшеренүнең фәнни яңалыгы** түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Рус мәктәпләре өчен чыккан дәреслекләр һәм программаларга, фәнни хезмәтләргә анализ ясап, алмашлыкларның өйрәнелү дәрәҗәсе ачыкланды.

2. Алмашлыкларны өйрәнү буенча мәктәп программасы һәм дәреслекләренең лингводидактик потенциалы билгеләнде.

3. Алмашлыкларны өйрәнү вакытында укучыларның эшчәнлеген, заманча технологияләргә нигезләп, махсус күнегүләр, биремнәр, төрле уеннар ярдәмендә оештырылды.

Тикшеренүнең **теоретик әһәмияте** түбәндәгедән гыйбарәт: әлеге фәнни эш алмашлыкларны өйрәнүнең тулы бер системасын күз алдында тота, мәктәптә уку-укыту теориясен баета; укучыларга алмашлыкларны өйрәткәндә заманча технологияләр белән эш итәргә ярдәм итә.

Тикшеренүнең **гамәли әһәмияте:** хезмәттә китерелгән аерым күзаллаулар, гомумиләштерүләр татар тел гыйлеме, татар телен укыту методикасы фәне белән кызыксынучылар, югары белем бирү йортлары студентлары өчен, урта һәм махсус белем бирү учреждениеләре укучылары һәм укытучылары өчен чыганак булып торалар.

**Чыгарылган нәтиҗәләрнең дөреслеге һәм расланганлыгы** тикшеренүдә кулланылган методларның максат һәм бурычларга тәңгәл булуы, тикшеренүнең эзлеклелеген саклау, төп нигезләмәләрнең һәм фәнни нәтиҗәләрнең педагогика, лингводидактика, психология, психолингвистика, татар телен укыту методикасы өлкәләрендәге казанышларга таянуы белән тәэмин ителде.

**Яклауга түбәндәге нигезләмәләр чыга:**

1. Рус мәктәпләре өчен чыккан дәреслекләр һәм программаларга ясалган анализны истә тоту мәктәптә алмашлыкларны билгеле бер системага салып өйрәнү мөмкинлекләре бирә;

2. Алмашлык сүз төркемен өйрәнү тарихы буенча хезмәтләр аны билгеле бер системага салып анализлау мөмкинлеге бирә;

3. Уен технологиясен яңа педагогик технологияләрнең берсе буларак танырга һәм актив кулланырга мөмкин;

4. Татар теле дәресләрендә алмашлыкларны өйрәткәндә яңа педагогик технология буларак, уен технологиясен куллану уңышлы.

**Апробация.** Диссертациядә яктыртылган теоретик материал, нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм басылып чыккан 4 хезмәтемдә яктыртылды:

1) Шәехова А.Х. Татар тел белемендә алмашлык сүз төркеме һәм аны өйрәнү тарихы / Казанский университет и мировая тюркология: Материалы Международной научно-практической конференции студентов, магистров и аспирантов (18 ноября 2016 г.) – Казань : Изд-во Казан. ун-та, 2016. – Б. 278-280

2) Шәехова А.Х. Татар тел белемендә алмашлык сүз төркеме һәм өйрәнүнең тарихы / Татарское языкознание в контексте Евразийской гуманитарной науки: Материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 1–4 ноября 2016 г.). – Казань : Изд-во Казан. ун-та. – 2016. – Б. 432-435

3) Шәехова А.Х. Татар теле дәресләрендә төрле педагогик технологияләр кулланып, алмашлык сүз төркемен өйрәтү / Национальный язык и культура в условиях глобализации: Материалы V заочной Международной научно-практической конференции студентов вузов, ссузов и учащихся школ (Казань, 15 декабря 2017 г.) / Под науч. ред. Л.И. Фидаевой, Р.М. Амировой, А.Г. Гилемшиной – Казань: ИД«МеДДоК», 2017. – Б. 208-211

4) Шәехова А.Х. Татар телендә алмашлык сүз төркемен уен технологиясенә нигезләп өйрәтү / Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар: Гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү

йортларында укучыларның IX Халыкара фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Казан, 20–21 февраль, 2018 ел). – Казань : Изд-во Казан. ун-та. – 2018. – Б. 245-247

**Диссертациянең структурасы һәм эчтәлеге.** Диссертация керештән, 2 бүлектән, йомгак, әдәбият исемлеге, кушымтадан тора. Хезмәтнең күләме – бит.

## I бүлек. Алмашлыкларны өйрәнү тарихы һәм аларның мәктәп программасындагы урыны

### 1.1. Алмашлык сүз төркемен өйрәнү тарихы

Сүз төркемнәре, гомумән, татар теленең иң беренче грамматикаларында ук күрсәтелә башлады. Мәсәлән, **А. Троянскийның** «Краткая татарская грамматика»сында 8 сүз төркеме бирелгән: исем, алмашлык, фигыль, сыйфат, рәвеш, бәйлек, теркәгеч, ымлык. [Троянский, 1814: 13]

**А. Казембекның** «Общая грамматика турецко-татарского языка» исемле китабында 9 сүз төркеме күрсәтелгән: исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, бәйлек, теркәгеч, ымлык. [Казембек, 1846: 13]

**К. Насыйриның** «Әнмүзәҗ»ендә 3 сүз төркеме күрсәтелә: исем, фигыль, хәреф. [Насыйри, 1895: 7] Шул ук бүленеш Җ.Вәлидинең «Татар теленең грамматикасы» исемле хезмәтендә кабул ителгән. [Вәлиди, 1919: 54]

**Г. Ибраһимов** үзенең 1915 елда чыккан «Татар сарыфы» дигән китабында беренчеләрдән булып татар теленең морфологиясен тәртипкә, системага сала. Яшәештә булган, ләкин аңлашылмый торган гарәп атамаларын алып ташлый, алар урынына татар теленә нигезләнгән яңа атамалар тәкъдим итә. Бу атамалар хәзерге көндә дә сакланган. Галим татар телендә тугыз «сүз төрен» күрсәтә: исем, сыйфат, сан, фигыль, кушымта, алмаш, каед, ярдәмлек, ымлык.

**Г. Алпаров** «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дигән хезмәтендә 5 сүз төркемен төрләнүче (исем, фигыль) һәм төрләнмәүче (рәвеш, ымлык, ярдәмлекләр) дип аталган ике төркемгә бүлә. [Алпаров, 1945: 69-70]

**В. Н. Хангилдинның** «Татар теле грамматикасы»нда сүзләр өч зур типка аерылган:

1) мөстәкыйль сүзләр (исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш);

2) ярдәмлек сүзләр (бәйлек, теркәгеч, кисәкчә, модаль сүзләр);

3) ымлык сүз.

Барлыгы 11 сүз төркеме күрсәтелгән. Алмашлык – исем, сыйфат, рәвеш, сан урынына йөри торган яки шундый сүзләрне алмаштыра торган сүзләр, дип билгели [Хангилдин, 1959; 135].

1972 нче елда чыккан «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе»ндә (Авторлары – **З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов**) 12 сүз төркеме билгеләнә: исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, бәйлек, теркәгеч, кисәкчә, ымлык, аваз ияртемнәре, модаль сүзләр. Алмашлык – исем, сыйфат, рәвеш, сан урынына йөри торган сүз төркеме, дип яза авторлар [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972; 83].

**Д. Г. Тумашева** үзенең «Хәзерге татар әдәби теле» дигән хезмәтендә сүз төркемнәре турында тирән мәгълүмат бирә, сүзләрне төркемләү принципларын, сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтен күрсәтә, татар телендә 12 сүз төркеме барлыгын ассызыклый:

1) мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, рәвеш, алмашлык, сан, фигыль;

2) ярдәмлек сүз төркемнәре: бәйлек, теркәгеч, кисәкчә;

3) ымлыклар, аваз ияртемнәре, модаль сүзләр.

Алмашлык – исем, сыйфат, рәвеш, сан урынына килеп, шул сүз төркемнәренең гомуми мәгънәләренә ишарә итә торган сүзләр, ди автор [Д. Г. Тумашева, 1978; 93].

Күргәнебезчә, һәрбер грамматик төркемләүдә алмашлык сүз төркеме күрсәтелгән. Терминнарга күз салсак, алар бер-берсенә охшаган, ягъни терминнар аерылмый дип әйтә алабыз.

Алмашлыклар, аерым бер сүз төркеме буларак, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында өйрәнелә башлый. Аларны өйрәнүдә К. Насыйри, Г. Алпаров, Ш. Иманаев, Г. Тәуфикъ, Г. Нугайбәк, М. Корбангали, Х. Габделбәдигъ һ.б. зур өлеш керткәннәр.

Татар тел белемендә «алмашлык» термины беренче башлап **М. Корбангалиев** һәм **Х. Бәдигый** тарафыннан язылган «Татар теле

сарыфы» дигән морфология дәреслегендә кулланыла (1918); Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди грамматикаларында «алмаш» термины, ә аңа кадәрге грамматикаларда «замир», «исме замир» терминнары кулланыла.

Алмашлык сүз төркемен тану һәм билгеләү мәсьәләсе антик филология тарафыннан ук көн тәртибенә куелган була. Анда бу төр сүзләрне «прономен» (<лат. pronomen = pro nomer + исем өчен) дип атаганнар, ягъни «исем урынына» йөртелә торган сүзләр булып чыга. Гарәп тел белемендә исә бу төр сүзләрне «замир», «исме замир» дип атаганнар. Бу сүзнең этимологиясе бик кызыклы. Замир «эч, нәрсәнеңдер эчке торышы, яшерене...» дигән мәгънәләрне аңлата. Кыскасы, гарәпнең замире (алмашлыгы) башка бер төшенчәләрне аңлатуны «эченә яшергән» сүзләр төркеме булып чыга [Җәләй, 2000; 117].

**Г. Нугайбәк** «Төрлек» исемле грамматикасында (1911) «атлык» // «исемлек» дигән атамалар да кулланып карый, ләкин аның бу атамалары, бер яктан, артык туры калька булганга, икенче яктан, алмашлыкларның төп функциясен бик тарайтып аңлатканга булса кирәк, кабул ителмичә калалар. Гомумән, алмашлыклар читләтелмә уйлау, абстракцияләү нәтиҗәсендә туган сүз төркеме. Телдәге тарихи закончалык буенча, читләтелмә сүзләр борынгы конкрет мәгънәле сүзләрдән килеп чыкканнар. Бу – тел белемендә күптән расланган һәм дәлилләнгән хакыйкать.

Хәзерге татар әдәби телендәге алмашлыклар һәм аларның төркемчәләре борынгы төрки телдән үк килә. Кайбер алмашлыклар фонетик үзгәрешкә тартылган: *бән > мән > мин, сән > син, ол > ул, нә > ни* һ.б. Морфемалары кушылу аркасында кайбер алмашлыклар тамыр һәм кушымча бергә аерылмас хәлгә килгәннәр: *ба – бә – би + з > без, ки + м > мин* һ.б. Борынгы төрки телдә һәм татар язма истәлекләрендә кулланылган *нәтәк / ник, канча / күпме, ошбу / шушы* һ.б. алмашлыклар архаиклашканнар. Татар телендә *кайчан / кай + чагын, нәрсә / нә + ирсә* кебек кушма алмашлыклар туган [Нуриева, 1975; 70].

Төрки телләрнең хәзерге грамматикаларында алмашлыкларны төрле төркемчәләргә бүләләр. В. В. Радлов карашы буенча, күрсәтү алмашлыклары зат алмашлыкларыннан килеп чыкканнар. Аның хезмәте буенча: *бән – бу, сән – шу*. Ул үзенең фикерен якут телен тикшергәч әйткән.

Л. П. Якубинский, төрек теле алмашлыкларына нигезләнеп, бөтенләй икенче төрле әйтә. Ул зат алмашлыклары күрсәтү алмашлыкларыннан килеп чыккан ди. Шуны дәлил итеп, төрек теленнән түбәндәге схеманы китерә:

*Бун – «этот», «здесь», бен – «я».*

*Шун – «тот», «этот», «там», сен – «ты».*

Кайбер галимнәрнең алмашлыкларны өйрәнгән хезмәтләре белән якыннан танышып анализ ясадым.

**Харисова Чулпан Мөхәррәм кызы** үзенең югары уку йортлары өчен чыгарган «Татар теле. Морфология» дәреслегендә алмашлыкка мондый билгеләмә бирә: «Алмашлык – татар телендә исем, сыйфат, сан, рәвеш һәм фигыльләрне алыштырып, алар урынында кулланыла торган сүз төркеме». [Харисова, 2010: 52-53] Алмашлыкларның бу сүз төркемнәренең мәгънәләрен турыдан-туры белдермәвен, бәлки аларга ишарә итүен, алыштыруын ачыклап китә. Димәк, лексик-грамматик мәгънәсе буенча алмашлыклар предметларга, аларның билгеләренә һәм микъдарына, шулай ук аларның эш-хәленә яки аның билгесенә ишарә итә, аларны алыштыра. Мәсәлән, *Урамда һичкем күренми, беркайчан да булмаган хәл бит бу!* (К. Нәҗми) җөмләсендә *һичкем* – исемне алыштырып килгән юклык алмашлыгы; *беркайчан* – рәвешне алыштырып килгән юклык алмашлыгы; *бу* – сыйфатны алыштырып килгән күрсәтү алмашлыгы. [Харисова, 2010: 53]

**Харисова Ч. М.** алмашлыкларның мәгънәләре шактый гомуми булуын ассызыклый. Шунлыктан аларның эчтәлеге җөмлә эчендә генә конкретлаша төшә. Мәсәлән, ***Үзебезнең*** *өй түбәсенә мендем дә* ***аның*** *иң очланып килгән җиренә ябышып, басып тора башладым.* (Ф. Әмирхан) [Харисова, 2010: 53]

Сөйләмдә алмашлыкларның роле гаять зур, чөнки алар бер үк сүзне кабатлаудан коткара, сөйләмне стилистик яктан шомарта, җыйнакландыра, матурлый. Алмашлыклар, гадәттә, үзләре алыштырып килгән сүз төркеменең гомуми билгеләренә ишарә итүен дә әйтеп узарга кирәк.

Морфологик яктан бу сүз төркеме үзләре белән мөнәсәбәттәш булган сүзләрнең грамматик категорияләрен ала һәм шул сүз төркеменә хас булган синтаксик функцияне үти. Мәсәлән, исем урынында кулланыла торган алмашлыклар предметка ишарә итә, грамматик яктан килеш, тартым белән төрләнә, берлек һәм күплек санда килә.

Синтаксик яктан җөмләдә ия яки тәмамлык, аергыч, хәл яки хәбәр булып килә. *Исемең матур* ***кемнәр*** *куйган* дигән җөмләдә билгеләнгән сүз исемне алыштырган, баш килештә, күплек санда, тартым белән төрләнмәгән, җөмләдә ия булып килгән. [Харисова, 2010: 53]

Харисова Ч. М. алмашлыкларның грамматик төркемчәләрен түбәндәгечә бүлә: кайсы сүз төркеме урынында кулланылуларына карап, икенче төрле әйткәндә, нинди сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш булулары ягыннан чыгып, алмашлыклар түбәндәге грамматик төркемчәләргә бүленә:

1. Исем алмашлыклары: *мин, син, ул, без, сез, алар, һичкем, беркем, һичнәрсә, бернәрсә, әллә кем, әллә нәрсә* һ.б. Бу алмашлыклар предметка гомуми планда ишарә итә. Морфологик яктан килеш һәм кайберләре тартым белән төрләнә, берлек яки күплек санда кулланыла: ***Сиңа миннән*** *хәбәр китерсәләр,* ***ул*** *егылган арып, дисәләр, син ышанма, бәгърем...* (М. Җәлил) Исем алмашлыклары *-ныкы, -неке* кушымчалары белән тартым алмашлыклары барлыкка китерә: *Бу китап* ***минеке****.* [Харисова, 2010: 53-54]

2. Сыйфат алмашлыклары: *ул, бу, шул, теге, андый, мондый, шундый, тегенди, бөтен, бар, һәммә, һәр, нинди, әллә нинди, ниндидер, кайсыдыр, кайсы, әллә кайсы* һ.б. Алар предметның билгесенә ишарә итә, исемне ачыклаганда төрләнми, ләкин кайберләре сыйфат кебек чагыштыру дәрәҗәсендә килә (*Карлыгач-сылу да* ***шундыйрак*** *фикергә килгән иде.* (Г.

Ибраһимов); исемләшергә дә мөмкин (***Кайсыгызның** кулы җылы, бәйлисе бар йөрәкне...* (Х. Туфан) Гадәттә, сыйфат алмашлыклары җөмләдә аергыч була: *Бер җирдә юк **андый** ак каеннар, бер җирдә юк **андый** урманнар*. (Һ. Такташ) [Харисова, 2010: 54]

3. Рәвеш алмашлыклары: *кайчан? әллә кайчан, кайчандыр, кайда? әллә кайда, кайдадыр, ничек? әллә ничек, ничектер, алай, болай, шулай, тегеләй* һ.б. Алар рәвешләрнең гомуми мәгънәсенә ишарә итә, төрләнми, кайберләре чагыштыру дәрәҗәсендә килә, җөмләдә төрле хәлләр була: *«Сез **кайдан**?» – дип сорыйсыз*. (С. Хәким) *«**Кайчанрак** кайтасыз?» – дип сорады абыйсы белән җиңгәчәсе Кларадан*. (Ә. Еники) ***Кая** барсам, **кайда** торсам, нишләсәм дә, хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.* (Г. Тукай)

Сыйфат алмашлыклары дип йөртелә торган кайбер сүзләр, мәсәлән, *андый, мондый, шундый* алмашлыклары җөмләдә еш кына рәвеш алмашлыклары буларак очрый, җөмләдә, билгенең билгесен яки эш-хәлнең билгесен белдереп, хәл була: *Бөтен буыннар талып кала, тар парта арасында тик утыруы **шундый** рәхәт.* (М. Мәһдиев) [Харисова, 2010: 54]

4. Сан алмашлыклары: *ничә? ничәнче? әллә ничә, әллә ничәнче, ничәнчедер* һ.б. Алар предметның микъдарына ишарә итә, төрләнми, җөмлә эчендә ачыклаган исеме төшеп калганда исемләшергә дә мөмкин: *Быел **ничәнчене** тәмамлыйсыз?* Шулай итеп, сыйфат, рәвеш һәм сан алмашлыклары – гомуми планда предметның, эш-хәлнең яки билгенең билгесенә яисә предметның исәбе буенча билгесенә ишарә итә торган грамматик төркемчәләр. Морфологик яктан бу алмашлыклар төрләнмәүләре белән аерылып тора; сыйфат һәм сан алмашлыклары исемләшергә мөмкин; сыйфат һәм рәвеш алмашлыклары исә чагыштыру дәрәҗәсендә кулланыла. [Харисова, 2010: 54-55]

5. Фигыль алмашлыклары: *нишли? нишләде? нишләгән? әллә нишли, нишлидер* һ.б. Бу алмашлыклар зат яки предметның эшенә ишарә итә, фигыльләргә хас булган морфологик күрсәткечләрне, ягъни заман, зат-сан,

барлык-юклык һ.б. категорияләрнең кушымчаларын кабул итә, җөмләдә еш кына хәбәр яки башка җөмлә кисәге дә булып килә: *«**Нишләргә** соң?» дигән сорау белән киләм синең рәсмең каршына*. (Х. Туфан) *Әллә ничек булды синең гомер, син, Мокамай, **әллә нишләдең***. (Һ. Такташ) [Харисова, 2010: 55]

Шулай итеп, алмашлыклар, нинди сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш булса, шул сүз төркеменең мәгънәсенә ишарә итә, аның грамматик билгеләрен алып, җөмләдә шул сүз төркеменә хас булган вазифаларны үти.

Мөгаллимә Чулпан Мөхәррәм кызы мәгънәләре буенча алмашлыкларның берничә төрле булуын күрсәтә: зат, күрсәтү, сорау, билгесезлек, юклык, билгеләү һәм тартым алмашлыклары.

**Зат алмашлыклары:** *мин, син, ул, без, сез, алар*. *Мин* сүзе – сөйләүче затны, *син* – тыңлаучы яки сөйләм төбәлгән затны, *ул* сөйләмдә катнашмаган башка бер зат яки, гомумән, предметны белдерә; *без* коллектив исеменнән сөйләүчене һәм шул коллективка кергәннәрне үз эченә ала, *сез* – тыңлаучыларны, ягъни сөйләм төбәлгән затларны, *алар* сөйләшүдә катнашмаган затларны һәм, гомумән, предметларны белдерә. [Харисова, 2010: 55]

Беренче һәм икенче зат алмашлыклары, гадәттә, кешегә карата кулланыла, өченче зат алмашлыклары исә затны да, предметны да алыштырып килә ала. Мәсәлән, кеше яки поезд турында сөйләгәндә, *Ул килә* дип әйтергә мөмкин.

Стилистик максатлардан чыгып, зат алмашлыклары башка мәгънәләрдә дә кулланыла ала: син алмашлыгы матур әдәбиятта, аерым алганда шигърияттә, сурәтләү чарасы буларак предметка карата да кулланыла: *Синме соң бу бөек Маркс иле һәм давыллы Шиллер ватаны?* (М. Җәлил) Без алмашлыгы фәнни стильдәге сөйләмдә мин сүзе урынына да килә ала: *Без югарыда әйтелгән фикер белән килешәбез*. Сез алмашлыгы еш кына таныш булмаган яки аерым хөрмәткә лаек булган өлкәнрәк яшьтәге бер затка карата да кулланыла: *Сез, Сания апа, җыелышка кайчан барасыз?* (М. Әмир) Зат

алмашлыклары, исем алмашлыклары буларак, берлек һәм күплек санда булалар: *мин – без, син – сез, ул – алар*. [Харисова, 2010: 55]

Бу алмашлыкларның килеш белән төрләнеше шактый үзенчәлекле.

| Б.к. | *мин* | *син* | *Ул* | *без* | *сез* | *алар* |
|---|---|---|---|---|---|---|
| И.к. | *минем* | *синең* | ***аның*** | *безнең* | *сезнең* | *аларның* |
| Ю.к. | *миңа* | *сиңа* | ***аңа***<br>***аңар***<br>***аңарга*** | *безгә* | *сезгә* | *аларга* |
| Т.к. | *мине* | *сине* | ***Аны*** | *безне* | *сезне* | *аларны* |
| Ч.к. | *миннән* | *синнән* | ***аннан***<br>***аңардан*** | *бездән* | *сездән* | *алардан* |
| У.-в.к. | *миндә* | *синдә* | ***анда***<br>***аңарда*** | *бездә* | *сездә* | *аларда* |

Мисаллардан күренгәнчә, берлек сандагы I һәм II зат алмашлыклары иялек һәм юнәлеш килешләрендә үзенчәлекле кушымчалар ала; III зат алмашлыгы исә, килеш белән төрләнгәндә, тамырыннан ук үзгәрә, икенче төрле мондый күренешне супплетивизм дип йөртәләр. III зат алмашлыгы юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешләрендә икешәр, хәтта өчәр вариантта кулланыла.

Күплек сандагы зат алмашлыкларның килеш белән төрләнешендә үзгәрешләр күзәтелми.

Зат алмашлыкларының тартым категориясенә мөнәсәбәте шактый кызыклы. Алар тартым белән төрләнмиләр, үзләре шушы категориянең аналитик (***минем*** *китап*) һәм аналитик-синтетик формаларын (***минем*** *китаб****ым***) белдерү өчен кулланыла.

Исем алмашлыклары буларак, зат алмашлыклары җөмләдә ия яки тәмамлык һәм башка җөмлә кисәкләре дә булып килергә мөмкин: *Һәрбер*

*нәрсә* ***безгә*** *яңа иде*. (Һ. Такташ) *Күптән түгел* ***безнең*** *тәрәзә капкачын оя итте* ***минем*** *сөйгән карлыгачым.* (Г. Тукай) [Харисова, 2010: 56]

Зат алмашлыклары *-ныкы, -неке* кушымчалары белән тартым алмашлыклары ясый һәм предметның иясен белдереп килә.

Күрсәтү алмашлыклары: *ул, бу, шул, теге, андый, мондый, шундый, тегенди, алай, болай, шулай, тегеләй* һ.б.

**Күрсәтү һәм сыйфат алмашлыклары** буларак, *ул, бу, шул, теге, андый, мондый, шундый, тегенди* сүзләре зат, предмет яки төшенчәләргә күрсәтү өчен кулланыла. Алар исемне ачыклаганда төрләнмиләр, җөмләдә аергыч булалар: *Һич бетәрме тарихи* ***бу*** *бергәлек*? (Г. Тукай) *Әнә* ***шул*** *бабай миңа бер уч тутырып орлык бирде*. (Г. Ибраһимов) Мондый алмашлыклар җөмләдә ачыклап килгән исеме төшеп калганда исемләшә, шуңа, килеш һәм тартым белән төрләнеп, берлек яки күплек санда килә: ***Тегесе****, чыннан да, хәйләкәр булып чыкты*. (Ш. Маннур) *Ул* һәм *бу* алмашлыклары исемләшеп, килеш белән төрләнгәндә, тамырларыннан ук үзгәрә: *Бу ташкынны (****моны****) күргән кеше аптырап кала*. (Ә. Баянов) [Харисова, 2010: 57]

Күрсәтү алмашлыкларыннан рәвеш алмашлыклары, эшнең яки билгенең билгесенә ишарә итеп, җөмләдә хәл булып килә: ***Шулай*** *матур сөйли.* ***Болай*** *эшләү бик үк килешеп бетмәс кебек.* Күрсәтү алмашлыклары чагыштыру дәрәҗәсендә дә килә ала: *Андый****рак*** *фикер әйтелгән иде инде. Болай****рак*** *итеп язарга кирәк.* Күрсәтү алмашлыклары парлы яки ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр составында кулланыла: *Кем эшләми,* ***шул*** *ашамый*. Исемләшкән күрсәтү алмашлыклары аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләләрнең баш җөмләсендә мөнәсәбәтле сүз буларак кулланыла: *Тик (****шул нәрсә) шунысы*** *бар: дәрестән соң барлык укучылар да өмәдә катнашырга тиеш*. Күрсәтү алмашлыклары арасында карала торган әнә һәм менә сүзләре төрләнмәүләре һәм җөмлә кисәкләре була алмаулары белән аерылып тора. *Әнә* сүзе – ераграк, *менә* якынрак урнашкан әйбергә күрсәтә. Бу сүзләр күрсәтү кисәкчәләренә охшаган. [Харисова, 2010: 57]

**Билгеләү алмашлыклары** предмет, күренеш яки төшенчәләрне берәм-берәм (*һәркем, һичнәрсә, һәрбер, һәркайсы*) яки җыеп (*бар, барлык, барча, бөтен, һәммә*) билгеләү өчен кулланыла. Билгеләү алмашлыкларыннан *һәркем, һәрнәрсә*, исем алмашлыклары буларак, килеш һәм тартым белән төрләнә, берлек яки күплек санда кулланыла: *Бу мәсьәлә **һәркемне** борчый*.

Билгеләү алмашлыкларының зур күпчелеге – сыйфат алмашлыклары: *бар, барлык, бөтен, һәммә, һәр, һәркайсы.* Алар исемнәрне ачыклап килгәндә төрләнми, җөмләдә аергыч була: *Һәрбер нәрсә безгә яңа иде, **һәр**нәрсәгә исебез китә иде*. (Һ. Такташ) Бу алмашлыклар, җөмлә эчендә ачыклап килгән исеме төшеп калганда, бик җайлы гына исемләшә: ***Барын** да беләм дигән бер нәрсә дә эшли алмас*. (Мәкаль) ***Бөтенесе** дә баскан урыннарында катып калды*. (Г. Бәширов) [Харисова, 2010: 58]

Билгеләү алмашлыкларыннан үз сүзе татар телендә башкаларыннан аерылып тора. Ул бер үк вакытта исем алмашлыгы һәм сыйфат алмашлыгы буларак та кулланыла; исем алмашлыгы булганда, исем кебек төрләнә. Ия янында килеп, җыйнак аныклагыч була: *Әлфия бу мәсьәләне **үзе** эшләде*.

Тартым белән төрләнгән үз алмашлыгының килеш формалары тартымлы исемнәрнеке белән туры килә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Б.к. | *үзем* | *үзең* | *үзе* |
| И.к. | *үземнең* | *үзеңнең* | *үзенең* |
| Ю.к. | *үземә* | *үзеңә* | *үзенә* |
| Т.к. | *үземне* | *үзеңне* | *үзен* |
| Ч.к. | *үземнән* | *үзеңнән* | *үзеннән* |
| У.-в. к. | *үземдә* | *үзеңдә* | *үзендә* |

Сыйфат алмашлыгы булганда, бу сүз исемне ачыклап килә һәм төрләнми, җөмләдә аергыч була: *Үзем күрдем, **үз** күзләрем белән, үкереп акты ничек елгалар*. (М. Җәлил) Шактый гына билгеләү алмашлыклары

тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүз буларак кулланыла: *Бүген **һәммәсе**: олысы, кечесе печән басуына китте*. [Харисова, 2010: 58]

**Сорау алмашлыклары** сорауны белдергәндә кулланыла. Алар – үзләре алыштырып килгән сүз төркемнәренең морфологик-синтаксик билгеләре җыелмасын белдерә торган сүзләр: *кем? нәрсә? нинди? кайсы? ничә? ничаклы? ничек? кая? кайда? кайдан? кайчан? нишли? нишләгән?* һ.б. *Кем? нәрсә? кемнең? нәрсәнең? кемгә? нәрсәгә? кемне? нәрсәне? кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә?* – исем алмашлыклары, килеш һәм тартым белән төрләнә, берлек яки күплек санда килә, җөмләдә ия яки тәмамлык һәм башка җөмлә кисәкләре була: ***Кем** уйлаган шушы шаярулар синдә кәсеп булып калыр дип?* (Һ. Такташ) *Нинди? кайсы? кайдагы?* – сыйфат алмашлыклары, исемне ачыклап, аергыч була, исеме төшеп калганда исемләшә: ***Кайсысы** өстенә иске кием элеп, **кайсысы** яланөс килеш халык җыелган җиргә киттеләр*. (М. Юныс) *Ничәү? ничә? ничәләп? ничәшәр? ничәнче?* – сан алмашлыклары, исемне ачыклап, аергыч була, исемләшергә дә мөмкин: *Улы **ничәнчене** тәмамлаганны Мәфтуха апа исенә төшерә алмады*. (Р. Гариф) *Кая? кайдан? кайчан? ник? ничек?* – рәвеш алмашлыклары буларак төрләнми, хәл булалар, кайберләре чагыштыру дәрәҗәсендә кулланыла: ***Кайчанрак** кайтасың?* Җөмләсендә кайчанрак сүзендәге чагыштыру дәрәҗәсе кушымчасы белән билгесезлек мәгънәсе дә өстәлә. *Әй син, картлыгым, **ник** иртә килдең? Минем адресны син **кайдан** белдең?* (Р. Нуруллин) – бу җөмләләрдәге билгеләнгән сүзләр – хәл булып килгән сорау һәм рәвеш алмашлыклары. *Нишли? нишләгән? нишләде? нишләячәк? нишләр?* – фигыль алмашлыклары, шушы сүз төркеменең грамматик күрсәткечләрен кабул итә: *Хәсән бүген үзен аеруча авыр хис итте; шунлыктан күңеле сыкранды, **әллә нишләде***. (Ф. Яруллин) [Харисова, 2010: 58-59]

**Юклык алмашлыклары** сорау алмашлыкларына һич яки бер инкарь кисәкчәләре ялганып ясала: *һичкем, беркем, һичнәрсә, бернәрсә, һичнинди, бернинди, һичничек, берничек* һ.б. Алар, нинди сүз төркеме урынында

кулланылса, шул сүз төркеменең грамматик күрсәткечләренә ия була: *Мин сезгә боларның **һичберен** теләмим*. (С. Габделмән) Юклык алмашлыгы урынында бер саны да кулланыла: *Бу егетләр, бу кызлар шәһәрнекеләргә **бер** дә охшамаган*. (Ә. Еники) Берничә сүзе сан һәм билгесезлек алмашлыгы буларак кулланыла, исемләшеп килергә дә мөмкин: *Араларында **берничәсе** кайтып китте*. (Г. Ибраһимов) [Харисова, 2010: 59]

**Билгесезлек алмашлыклары** сорау алмашлыкларына *әллә* яки *-дыр, -дер; -тыр, -тер* кисәкчәләре өстәлеп ясала: *кемдер, әллә кем, нәрсәдер, әллә нәрсә, ниндидер, әллә нинди*. Аларның төрләнү-төрләнмәүләре яисә нинди җөмлә кисәкләре була алулары кайсы сүз төркемен алыштырып килүләренә бәйле: *Күзгә **нәрсәләрдер** өелә, **нәрсәдер** өстәл яныннан очып килә*. (М. Мәһдиев) Исем һәм билгесезлек алмашлыгындагы күплек сан һәм килеш кушымчалары билгесезлек кисәкчәсе алдына куела: *кемнәргәдер.* Билгесезлек алмашлыгы белән белдерелгән субъектның эше үтелгән була, тик үтәүчесе генә билгесез (*Дәрестә **кемдер** сөйләшә*); юклык алмашлыгы белән белдерелгән субъектның эше үтәлми, чөнки үтәүчесе юк (*Дәрестә **һичкем** сөйләшми*). [Харисова, 2010: 59-60]

**Тартым алмашлыклары** исем алмашлыкларына *-ныкы, -неке* кушымчалары ялганып ясала. Алар, гадәттә, предметка ничәнче затның ия булуын, ягъни тартымны белдерү өчен, логик басым белән хәбәр иткәндә кулланыла: *кемнеке? минеке, һәммәбезнеке* һ.б. Тартым алмашлыклары, җөмлә ахырында килеп, хәбәр була: *Син үзең соң **кемнеке**? Ә син – Туган **җирнеке***. (Р. Фәйзуллин) [Харисова, 2010: 60]

Алмашлыклар башка сүз төркемнәре белән бик тыгыз мөнәсәбәттә яшәвен дә язып китә галимә Харисова Ч. М. Бу беренче чиратта аларның сүз төркемнәрен алыштырып килә алуына бәйле. Шуннан чыгып, алмашлыклар югарыда саналган грамматик төркемчәләргә бүлеп карала. Сыйфат һәм сан алмашлыклары, исемләшеп, исем кебек төрләнергә мөмкин: ***Болар** үзләре барырга теләмәделәр*. (Г. Ибраһимов) Кайбер сорау һәм күрсәтү

алмашлыклары җөмләләрне бәйләүче ялгызак яки парлы мөнәсәбәтле сүзләр хезмәтен үти: ***Кемнең** эше бар, **шуның** ашы бар*. (Мәкаль) Нәрсә алмашлыгы әйбер, предмет мәгънәсендә йөри: *Менә труба эчендәге төтен сыман **нәрсә,** чыгып, синең күзләреңне томалый*. (М. Мәһдиев) Шул сүзе раслаучы кисәкчә урынында кулланыла: *«Җитми **шул»,** – ди.* (М. Җәлил) Анда, монда, шунда сүзләре конверсия ысулы белән рәвешләргә күчеп, яңа лексик берәмлек барлыкка килгән. [Харисова, 2010: 60]

**Сафиуллина Флера Садрый кызы** һәм **Зәкиев Мирфатыйх Зәки улының** «Хәзерге татар әдәби теле» хезмәтендә исем, сыйфат, рәвеш, сан кебек сүз төркемнәрен алмаштырып килә ала торган сүз төркеме **алмашлык** дип атала. Башка сүз төркемнәреннән алмашлыклар лексик мәгънәләренең гомумилеге белән аерылып торалар. Алмашлык җөмләдә ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл булып килә. алмашлыклар үзләре белән мөнәсәбәттәш сүз төркемнәренең морфологик күрсәткечләрен алалар. [Сафиуллина, 2006: 290]

Мәгънә һәм вазифаларына карап, алмашлыклар җиде төркемгә бүленә:

**Зат алмашлыклары:** *мин, син, ул, без, сез, алар.*

**Күрсәтү алмашлыклары:** *бу, теге, ул, шул, әнә, андый* һ.б.

**Сорау алмашлыклары:** *кем, нәрсә, ник, нигә, ни өчен, нинди, ничек, кайсы, кайда, кайчан* һ.б.

**Билгеләү алмашлыклары:** *һәр, һәркем, барлык, һәммә, бөтен, үз* һ.б.

**Билгесезлек алмашлыклары:** *әллә кем, әллә ничек, әллә нәрсә, кемдер, никтер, нидер, ни дә булса, кем дә булса* һ.б.

**Юклык алмашлыклары:** *һичкем, һичнәрсә, һичкайда, һичкайчан, бернәрсә дә, беркайчан да, берничек тә, беркем дә.*

**Тартым алмашлыклары:** *синеке, аныкы, минеке, безнеке* һ.б.

**Зат алмашлыклары** сөйләү процессына катнашкан затларны белдерә: *мин, без* – сөйләүчеләр, *син, сез* – тыңлаучылар, *ул, алар* – аның хакында сүз барган, читтәге зат яки әйберләр. Зат алмашлыклары сан һәм килеш белән төрләнә, тартым категориясе аларга хас түгел: *Эндәшә батыр утынчы: –*

***Сиңа миннән*** *ни кирәк?* (Г. Тукай) [Сафиуллина, 2006: 291] Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше исемнәр төрләнешеннән беркадәр аерыла:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Б.к. | *мин* | *син* | *ул* |
| И.к. | *минем* | *синең* | *аның* |
| Ю.к. | *миңа* | *сиңа* | *аңа / аңар (га)* |
| Т.к. | *мине* | *сине* | *аны* |
| Ч.к. | *миннән* | *синнән* | *аннан / аңардан* |
| У.-в. к. | *миндә* | *синдә* | *анда / аңарда* |

**Сорау алмашлыклары** әйберне, затны, билгене, рәвеш һәм саннарны ачыклау өчен кулланыла. Сорау алмашлыклары: *кем, ни, нәрсә, кай, кайсы, каян, кайдан, кайчан, нинди, ник, нигә, ничек, ничә, күпме*. Сорау алмашлыкларының төрләнеше нинди сүз төркемен алыштырып килүенә бәйләнгән. [Сафиуллина, 2006: 291]

**Күрсәтү алмашлыклары** зат яки әйберне күрсәтү, билге яки рәвешләргә ишарә итү өчен кулланыла. Күрсәтү алмашлыклары: *ул, бу, шул, теге, мондый, андый, тегенди, шундый, алай, болай, тегеләй, шулай*. Күрсәтү алмашлыклары, билге яки рәвешкә ишарә иткәндә, җөмләдә аергыч яки хәл булып киләләр. Исемне алмаштырып килгәндә исә, алар килеш, тартым, сан белән төрләнәләр һәм җөмләдә ия, тәмамлык, хәбәр булалар. Мәсәлән: ***Бу*** *читек бөтенләй башка*. (Г. Исхакый) ***Ул*** *авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде*. (Г. Тукай) [Сафиуллина, 2006: 291] Төрләнгән вакытта кайбер алмашлыкларның тамыры үзгәрешләр кичерә: бу урынына кыек килешләрдә һәм күплек санда *мо(н)-; бо-; шул* урынына *шу(н)-; ул* урынына *а(н)*- тамырлары кулланыла.

| | | |
|---|---|---|
| Б. к. | *Бу* | *шул* |
| И. к. | *Моның* | *шуның* |
| Ю. к. | *моңа(-р)-га* | *шуңа(-р)-га* |

| | | |
|---|---|---|
| Т. к. | *Моны* | *шуны* |
| Ч. к. | *Моннан* | *шуннан* |
| У.-в. к. | *Монда* | *шунда* |

Тартым белән төрләнгәндә, өченче зат кушымчасы гына ялгана: *бу – бусы, мон(ы)-сы, болары; шул – шунысы, шулары.*

**Билгеләү алмашлыклары** зат һәм әйберләрне тулаем җыеп яки аерым-аерым билгеләп күрсәтәләр. Алар күп түгел: *һәр, бар, бөтен, һәммә, үз, һәркем, барысы, барча, бөтенесе*. Билгеләү алмашлыклары, исемне ачыклап, аергыч булып килгәндә төрләнмиләр; исем урынына килгәндә исә, килеш, тартым, сан белән төрләнеп, җөмләнең теләсә кайсы кисәгә була алалар: ***Һәр*** *яңа көн белән ни дә булса туа, ни дә булса арта бара.* ***Бөтен*** *ил,* ***бар*** *халык өчен генә түгел,* ***һәр*** *шәһәр,* ***һәр*** *авыл,* ***һәрбер*** *кеше өчен бу шулай.* (Г. Бәширов) [Сафиуллина, 2006: 292]

**Билгесезлек алмашлыклары** зат яки әйбернең, билге, рәвеш, сан һәм кайбер хәлләрнең билгесезлегенә ишарә итә. Алар *әллә* һәм -*дыр/-дер, -тыр/-тер* кисәкчәләре ярдәмендә сорау алмашлыкларыннан ясалалар. Мәсәлән: *әллә кем, кемдер, әллә ничек, әллә нинди, нindидер*. ***Әллә ничек*** *булды безнең гомер, син, Мокамай, әллә нишләдең*. (Һ. Такташ) *Бер, бер-бер, берәү, берәр* саннары да билгесезлек алмашлыгы функциясендә кулланыла: *берәр кем, бер-бер эш*. Мәсәлән: *Югары очтан* ***берәү*** *килә, Хафизәләм иркәм атлавы*. (Җыр) [Сафиуллина, 2006: 292]

**Юклык алмашлыклары** зат яки әйбернең, билге, рәвеш яки берәр хәлнең инкяр ителүен (кире кагылуын) белдерәләр. Алар сорау алмашлыклары алдына *һич* яки *бер* сүзләрен кую юлы белән ясала: *һичкем (беркем), һични (берни), һичничек (берничек), һичкайчан (беркайчан), һичнинди (бернинди), һичкайсы (беркайсы): Нәрсә әйтсен –* ***берни*** *белми ул*. (Х. Туфан) [Сафиуллина, 2006: 292]

**Тартым алмашлыклары** әйбернең кемнеке, кайсы затныкы икәнен белдерәләр. Алар *-ныкы, -неке* кушымчалары белән ясала: *минеке, сезнеке, үзебезнеке, аларныкы*. Тартым алмашлыклары килеш белән төрләнә һәм күплек кушымчалары ала: *минекендә, минекенең, синекенә, аныкына, безнекеләр, синекеләр*. Тартым алмашлыгы җөмләдә ия, хәбәр һәм тәмамлык булып килә: *Минеке матур. Яулык синеке.* [Сафиуллина, 2006: 293]

**Тумашева Диләрә Гариф кызы** үзенең «Хәзерге татар әдәби теле. Морфология» хезмәтендә исем, сыйфат, сан һәм рәвеш урынына килеп, шул сүз төркемнәренең гомуми мәгънәләренә ишарә итә торган сүзләрне алмашлык дип атый. Алмашлыклар башка сүз төркемнәреннән лексик мәгънәләренең гомумилеге белән аерылалар, чөнки алар конкрет предмет, конкрет сыйфат, сан һәм рәвешне атап белдермиләр, бәлки гомуми төстә предмет, сыйфат, сан һәм рәвеш мәгънәләренә ишарә итәләр. Грамматик яктан алмашлыклар үзләре белән мөнәсәбәттәш сүз төркемнәренең морфологик категорияләре буенча төрләнәләр һәм синтаксик функцияләрен үтиләр. Мәсәлән, исем урынына йөри торган алмашлыклар килеш, сан һәм (зат алмашлыкларыннан башкалары) тартым белән төрләнәләр; сыйфат һәм рәвешне алыштыручылар, исемләшкән очракларны исәпкә алмаганда, төрләнмиләр; сан урынына йөри торган алмашлыклар төрлечә үзгәрәләр, чөнки сан төркемчәләре морфологик табигатьләре ягыннан бердәй түгел.

Төрле сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттәшлекләре нигезендә алмашлыклар дүрт төркемчәгә аерылалар. [Тумашева, 1978: 93-94]

1. Исем алмашлыклары гомуми рәвештә предмет мәгънәсен белдерәләр: *мин, син, ул, без, сез, алар, кем, нәрсә, үзе, һичкем, һичнәрсә, әллә кем, нәрсәдер* һ.б.

2. Сыйфат алмашлыклары гомуми рәвештә сыйфат мәгънәсенә ишарә итәләр: *бу, ул* (ул кеше), *теге, шул, андый, мондый, нинди, әллә нинди, кайсы, барлык, һәммә, үз* һ.б.

3. Сан алмашлыклары гомуми рәвештә сан мәгънәсен күрсәтәләр: *ничә, ничәнче, ничәләп, ничәшәр, ничаклы* һ.б.

4. Рәвеш алмашлыклары гомуми төстә рәвешкә ишарә итәләр: *ничек, кайчан, әллә ничек, ничектер, алай, болай, тегеләй, шулай* һ.б.

Алмашлыклар һичбер вакыт затланышлы фигыльләрне алыштырмыйлар, ләкин исем фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыль формаларын, соңгылары исем, сыйфат, рәвеш белән якын булганлыктан, алыштыра алалар: *ул тырышып укый, шулай укыса, мәктәпне уңышлы тәмамлаячак, пешкән алма – шундый алма, нинди алма?; яшәү өчен – нәрсә өчен?* һ.б. [Тумашева, 1978: 94]

Синтаксик яктан исем алмашлыклары, исемнәр кебек, җөмләнең һәр кисәге ролендә килә алалар. Мәсәлән: *Әти, мин сиңа шәһәрдән нәрсә алып кайтырмын?* (И. Гази). *Бүген мин сыерларны тирән чокырга алып бардым. Анда ашау яхшы.* (Т. Гыйззәт). *Сары чәчлесе – ул мин идем* (Һ. Такташ). Китерелгән җөмләләрдә *мин, сиңа, нәрсә* алмашлыклары ия, кыек һәм туры тәмамлык, *анда* – хәл булып, *мин* – хәбәр составында килгәннәр. Кагыйдә буларак, сыйфат алмашлыклары аергыч, рәвеш алмашлыклары хәл булып киләләр: *Нинди тылсымлы бу таң беленгән чаклар! Шул нурлар белән бергә күңелдә ниндидер изге тойгылар уяна* (Г. Бәширов). *Кайдан килдегез, кайчан?* (Г. Әпсәләмов). [Тумашева, 1978: 94]

Сыйфат алмашлыклары аергыч булып килмәгәндә исемләшәләр һәм төрләнәләр: *Атасы пароходларны тавышларыннан таный. Бусы фәлән бай пароходы, бусы фәлән бай пароходы...* (И. Гази). Алмашлыклар бер сүзне генә түгел, бәлки сүз тезмәләрен, җөмләләрне, хәтта зур гына сөйләм кисәкләрен алмаштырып килергә мөмкин: *Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады – анысын белмим* (Г. Тукай). [Тумашева, 1978: 94]

Мәгънәләре буенча алмашлыкларны җиде төркемчәгә бүлә:

1) **Зат алмашлыклары**: *мин, син, ул, без, сез, алар*. Беренче һәм икенче зат алмашлыклары – *мин, син* – сөйләүче һәм тыңлаучы затны белдерәләр; өченче зат алмашлыгы – *ул* – сөйләмдә катнашмый торган затны яки гомумән предметны күрсәтә: *ул иртәгә кайта* (зат), *мин дә аны укыдым* (предмет). Күплек сандагы алмашлыклар затларның күплеген белдерәләр һәм башкачарак мәгънәләрдә дә кулланылалар. Мәсәлән, *без* алмашлыгы, беренчедән, коллектив исеменнән сөйләүче затны белдерә (*без укыйбыз*), икенчедән, фәнни стильдә автор, ягъни сөйләүче зат – берлек сандагы *мин* алмашлыгы мәгънәсендә кулланыла. Күплек санда килгән икенче зат алмашлыгы тыңлаучы затларның күплеген күрсәтә (*сез укыйсыз*), һәм, ихтирам белдергәндә, икенче зат берлек сан мәгънәсендә кулланыла (*Мин Сезне күрә алмадым, Фатыйма апа*). Зат алмашлыклары сан һәм килеш белән төрләнә, тартым категориясе аларга хас түгел. Килеш һәм сан белән төрләнгәндә, III зат алмашлыгы *ул* тамырын *а* га алмаштыра: *ул, аның, аңа, алар*. Бу алмашлыкның тагын да борынгырак варианты *ан* рәвешендә әйтелгән: *Күрерсең син боларның йөргәнен һәр дәм коридорда: Йөриләр карт кәҗәдәй, үзләрен анлар саный зурга* (Г. Тукай). [Тумашева, 1978: 95] Шул ук *ан-* тамыры кайбер кыек килешләрдә күренә: *ан-нан, ан-да*. I зат берлек сан алмашлыгының иялек килеше *миннең* урынына әдәби телдә *минем* дип әйтелә. Урын-ара килешләрдә килгән III зат алмашлыгы хәл функциясен үти һәм рәвеш урынына йөри торган күрсәтү алмашлыкларына якыная: *анда – монда, аннан – моннан* һ.б. Мәсәлән, *Димәк, ул уйлаганча, бу кыз бик үк мескен түгел, димәк, анда* (затны алмаштыра) *егетләрнең күңелен тынычландыра ала торган көч тә, җитлеккәнлек тә бар* (Н. Фәттах). [Тумашева, 1978: 96] Мондый алмашлыкларның рәвешкә әйләнү очраклары да бар.

III зат алмашлыгы заттан башка предметны алыштыра алганга һәм урын-вакыт килеш формалары күрсәтү алмашлыкларына һәм рәвешкә якынайганга күрә, телдә затны алмаштыру өчен шушы килешләрдә махсус

формалар туган булган. Мәсәлән: *ул – аңа, аңар, аңарга; аннан һәм аңардан;анда һәм аңарда.* Шулардан *аңар, аңарга, аңардан, аңарда* формалары кешене-затны гына алмаштыралар: *Аңар унтугыз яшь тулган иде* (Ш. Камал). [Тумашева, 1978: 96] *Аңа, аннан, анда* затны да, предметны да белдерә алалар.

2) **Күрсәтү алмашлыклары**: *ул, бу, шул, теге, мондый, андый, тегенди, шундый, алай, болай, тегеләй, шулай.* Бу алмашлыклар предмет, сыйфат, рәвешкә күрсәтәләр: *бу – өстәл, мондый төн. Ул, бу, шул, шушы, теге* – күрсәтү алмашлыкларының төп формалары. Калган алмашлыклар шушы төп формалардан -*дый, -ди, -лай, -ләй* кушымчалары ярдәмендә ясалганнар: *бу – мондый, болай; шул – шундый, шулай; ул – андый, алай; теге – тегенди, тегеләй*. Күрсәтү алмашлыкларыннан *ул, бу, шул, шушы* һәм *теге* үзара урын һәм вакыт ягыннан төрле чикләрне белдерүләре белән аерылалар.

Күрсәтү алмашлыклары исемнән башка килсәләр, килеш, сан белән төрләнәләр һәм чикле күләмдә тартым кушымчаларын алалар: *бу, моның, моңа, моны, моннан, монда; бу – болар, тегеләр, шундыйлар, бу – монысы, сирәгрәк – бусы, теге – тегесе, шушы – шушысы, шунысы* һ.б. Төрләнгән вакытта алмашлыкның тамыры үзгәрешләр кичерә: *бу* урынына кыек килешләрдә һәм күплек санда *мо(н)-, бо-; шул* урынына *шу(н)-* тамырлары кулланыла. [Тумашева, 1978: 97]

Рәвеш урынына йөри торган *алай, болай, тегеләй, шулай* кебек күрсәтү алмашлыклары, кагыйдә буларак, төрләнмиләр, ләкин аларның да кушымчалар белән катлауландырылган формалары очрый: *эш шулайга таба бара* һ.б.

3) **Сорау алмашлыклары**: *кем, ни, нәрсә, кай, кайсы, каян, кайдан, кайчан, ник, нигә, нинди, ничек, ничә, ничәнче, ничәшәр, ничәләп, никадәр,ничаклы* һ.б. Боларның төп формалары: *кем, ни, кай. Ни* алмашлыгының борынгырак формасы *нә* булган, аннан *нәрсә* (*нә ирсә*) ясалган. *Нәрсә* – сорау алмашлыгы булу белән беррәттән билгесезлек

төсмере белән «әйбер»мәгънәсен белдерә: *Анда бер ак нәрсә күренә башлады* (Ш. Камал). [Тумашева, 1978: 98] *Ни* алмашлыгыннан сыйфат, рәвеш, сан кушымчалары һәм бәйлекләр белән күптөрле сорау алмашлыклары ясалган: *нинди, ник, нигә, ничә, ничәнче, ничәшәр, нихәтле* һ.б. *Кай* алмашлыгы үзе сирәк очрый, ләкин аннан ясалган алмашлыклар бик киң таралган: *кая, кайда* (урын-вакыт килеше), *кайдан* (чыгыш килеше), *кайчан, кайсы*. Мәсәлән: *Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә, Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем* (Г. Тукай). [Тумашева, 1978: 98] Сорау алмашлыкларының төрләнеше нинди сүз төркемен алыштырып килүенә бәйләнгән: *кем, ни, нәрсә* – исем кебек, *кайсы, нинди, ничәнче* – сыйфат һәм тәртип саны кебек төрләнәләр; *ник, ничек, кайчан* – рәвеш кебек төрләнмиләр һ.б.

4) **Билгеләү алмашлыклары**: *бары, барлык, барча, һәммә, һәр, һәрбер, үз, бөтен. Бары, барлык, барча* – бар тамырыннан ясалганнар; *һәммә, һәр* – алынма алмашлыклар; *бөтен* – хәзерге телдә кулланылмый торган бөтү (үсү, җитлегү мәгънәсендә) фигыленнән барлыкка килгән; *үз* алмашлыгы үз-әк сүзе белән бер тамырдан. Җыйма мәгънә белдерә торган алмашлыклар да, аерым предметларны билгели торганнары да үз төркемнәре эчендә бер-берсеннән мәгънә төсмерләре белән аерылалар: *барлык* һәм *бөтен* алмашлыкларының беренчесе күплек сандагы исемнәрне ачыклый (*барлык кешеләр, китаплар, өйләр*) һәм аерылмышның аерым-аерым предметлардан торганлыгына ишарә итә; *бөтен* исә берлек сандагы исемнәрне ачыклый һәм аерылмышны җыйма бер бөтен итеп күрсәтә (*бөтен халык, бөтен авыл*) һ.б. Билгеләү алмашлыкларының барысы да диярлек аергыч ролендә һәм исемләшкән хәлдә кулланыла: *Айсылу һәммәсен дә хуҗаларча үз итеп карап үтә* (Г. Бәширов). *Өстегезгә төшкән бурычларны Егетләрчә барын эшләгез* (Һ. Такташ). [Тумашева, 1978: 99] *Үз* алмашлыгы аергыч ролендә килгәндә төрләнми: *Шәһәрне үз кулына алган пролетариат... Советлар төзү эшенә кереште* (Ш. Усманов). Мөстәкыйль кулланганда, *үз* алмашлыгы һәрвакыт тартым һәм килеш белән килә. Аның янында зат алмашлыгы да булырга

мөмкин: *Мин үзем дә шул сорауга җавап эзлим* (Ш. Усманов). [Тумашева, 1978: 100]

5) **Билгесезлек алмашлыклары** сорау алмашлыкларына препозитив (алдан куела торган) *әллә* кисәкчәсе яки постпозитив (сүзнең азагына ялгана торган) -*дыр/-дер* кисәкчәләре кушылып ясалалар: *әллә кем – кемдер; әллә ни – нидер; әллә ничек – ничектер, әллә кая - каядыр* һ.б. Төрләнү-төрләнмәүләре, башка алмашлыклардагы кебек, нинди сүз төркемен алыштырулары белән билгеләнә. Килеш, сан, тартым кушымчалары -*дыр, -дер* кисәкчәсе алдыннан ялганалар: *кемнедер, кемгәдер, нәрсәседер, нәрсәсенәдер* һ.б. Билгесезлек алмашлыгы функциясендә *бер* саны һәм аның төрле төркемчәләре кулланыла: *бер-бер, берәү, берәр*. *Бер* саны ярдәмендә күп кенә билгесезлек алмашлыклары ясала: *берәр кем, берәр нәрсә, берничә, кайбер, кайсыбер* һ.б. [Тумашева, 1978: 100]

6) **Юклык алмашлыклары**: сорау алмашлыкларына инкярне белдерә торган *һич* сүзе, *бер* саны белән ясалалар: *һичкем, һичнәрсә, һичнинди,һичкайчан, беркем, бернәрсә, бернинди, беркайчан, беркая, берничек* һ.б. *Һич, бер* сүзләре аерым торганда да алмашлык ролен үтиләр һәм исем яки фигыль алдыннан киләләр: *Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин, Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин* (Г. Тукай). [Д. Г. Тумашева, 1978: 100].

**7) Тартым алмашлыклары** төрле төркемчәдәге субстантив (исем урынына йөри торган) алмашлыкларга -*ныкы, -неке* кушымчасы ялганып ясалалар: зат алмашлыкларыннан – *минеке, синеке, безнеке, сезнеке* һ.б.; күрсәтү алмашлыкларыннан – *моныкы, тегенеке, шушыныкы* һ.б.; билгеләү алмашлыкларының тартымлы формасыннан – *барысыныкы, үземнеке, үзеңнеке, һәммәгезнеке* һ.б.; сорау алмашлыкларыннан – *кемнеке, нәрсәнеке, кайсыныкы* һ.б.; билгесезлек алмашлыкларыннан – *кемнекедер, нәрсәнекедер* һ.б.; юклык алмашлыкларыннан – *беркемнеке, һичкемнеке, бернәрсәнеке* һ.б. Тартым алмашлыкларының кушымчасы ике кисәктән тора: *ны-кы*. Тартым

алмашлыклары тартымлы исем урынына йөриләр, тартым кушымчасы алган алмашлыклар кебек төрләнәләр: *Синең кул-аягыңны бәйләп куймаганнар, минекен шулай ук* (Ф. Хөсни) [Д. Г. Тумашева, 1978: 101].

Д. Г. Тумашеваның югары уку йортлары өчен тәкъдим ителгән әлеге дәреслектә алмашлыкларны җиде төркемгә аерып карый. Алда каралган югары уку йортлары өчен дәреслекләр белән уртаклык күренә. Әмма Д. Г. Тумашева җиденче төркем итеп тартым алмашлыкларын күрсәтә. Ул Н. В. Хангилдинның «бу форманы алмашлыкның тартым белән төрләнешенең икенче варианты» дигән фикерен «зат алмашлыклары тартым белән төрләнми» дигән фикергә каршы килә дип таный һәм тартым алмашлыклары дигән төркемчәне бүлеп чыгара.

«Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» студентлар һәм укытучылар өчен дәреслектә **З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов** алмашлыкны болай дип билгелиләр: «Алмашлык – исем, сыйфат, сан һәм рәвеш урынына йөри торган сүз төркеме. Ләкин алардан аермалы буларак, алмашлык предмет яки билге белдерми, аңа тик исем, сыйфат, сан һәм рәвеш мәгънәләренә ишарә итү функциясе хас. Димәк, алмашлык – предмет яки аның билгесенә яисә эш-хәл һәм билгенең билгесенә ишарә итә торган сүз төркеме» [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 83].

Авторлар алмашлыкның кайсы сүз төркеме урынына йөрүләреннән чыгып: исем (*мин,син, ул, без, сез, алар; кем, нәрсә, һичкем, һичнәрсә, кемдер, нәрсәдер, үзе* һ.б.), сан (*ничә, ничәнче, ничәләп,ничәү, берничә* һ.б.), сыйфат (*бу, теге, шул, шушы, ул, шундый, мондый, нинди, кайсы, әллә нинди, барлык, бөтен, һәр, һәммә* һ.б.) һәм рәвеш (*кая, ничек, кайда, ник, кайчан, тегеләй, болай, шулай* һ.б.) алмашлыкларына бүләләр. Авторлар мондый нәтиҗәгә киләләр: «Алмашлыклар кайсы сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш булсалар, шул сүз төркеменең мәгънәсенә ишарә итәләр һәм шуның грамматик билгеләренә ия булалар» [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 85].

Авторлар алмашлыкларны мәгънәсе буенча 6 төргә бүләләр. Алар: зат, күрсәтү, сорау, билгесезлек, юклык һәм билгеләү.

1) **Зат алмашлыкларына** *мин, син, ул, без, сез, алар* керә. *Мин* – сөйләүче зат, *син* – тыңлаучы зат, *без* – коллектив исеменнән сөйләүче затны һәм шул коллектив эченә кергән затларны үз эченә ала, *сез* – тыңлаучылар, ягъни сөйләм төбәлгән затлар. Бу алмашлыклар барысы да тик затка карата кулланылалар. *Ул* – өченче бер сөйләшүдә катнашмаган зат, *алар* – сөйләшүдә катнашмаган берничә зат. Башка зат алмашлыкларыннан аермалы буларак, *ул* һәм *алар* предметларга карата да кулланылалар. Зат алмашлыклары исем алмашлыкларына керәләр. Димәк, исем кебек үк килеш белән төрләнәләр: *картаюны сизгәч, аның китмәскә килгәнлеген аңлагач, кешеләр үлем турында уйламый булдыра алмыйлар* (А.Гыйләҗев). Тартым белән төрләнмиләр, алар үзләре иялек килештә килеп, тартым категориясен формалаштыруда катнашалар: *минем урын(ым), синең урын(ың), аның урын(ы)* һ.б. Зат алмашлыклары, исем алмашлыклары буларак, -*ныкы, -неке* кушымчасы алып, нинди дә булса предметның иясен белдерәләр: *китап синеке* [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 86].

2) **Күрсәтү алмашлыкларына** авторлар *бу, теге, шул, шушы, ул, шундый, андый, мондый, шулай, тегеләй, болай* алмашлыкларын кертәләр. *Аулак чакта Хәйдәр белән шуны аударды* (А. Гыйләҗев). Күрсәтү алмашлыкларыннан *бу, теге, ул, шул, шушы, андый, мондый* – сыйфат алмашлыклары. Алар сыйфат кебек исемне ачыклап киләләр, төрләнмиләр һәм җөмләдә ешрак аергыч булалар: *шул кеше, мондый төн* һ.б. *Андый, мондый, шундый* кебек алмашлыклар сыйфат һәм рәвешне дә ачыклыйлар, җөмләдә хәл булалар: *андый яхшы* һ.б. *Тегеләй, болай, шулай* – рәвеш алмашлыклары. Алар фигыльне ачыклап, җөмләдә хәл булалар: *шулай яз, болай эшлә* һ.б. [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 87].

3) **Сорау алмашлыкларына** авторлар *кем, нәрсә, нинди, кайсы, ничә, ничек, кая, кайда, кайчан, ник, нигә* алмашлыкларын кертеп карыйлар. *Кем, нәрсә* – исем алмашлыклары. Алар килеш яки тартым белән төрләнәләр, берлек яки күплектә кулланылалар: *кем, кем-нең, кем-гә* һ.б. *Кем* алмашлыгы татар телендә тик затны (кешене) белдерә: *кем минем чүкечне алды?* (А.Гыйләҗев). *Нинди, кайсы* – сыйфат алмашлыклары, исемне ачыклап, җөмләдә аергыч булып йөриләр: *кайсы якка барасың инде син?* (А.Гыйләҗев). *Ничә, ничәнче* – сан алмашлыклары, шулай ук исемне ачыклап килеп аергыч булалар: *өстәлдә ничә китап? Ничек, кая, кайда, кайчан* – рәвеш алмашлыклары. *«Ничек итеп?» – дип кычкырды тәкатьсез калган Наилә* (А. Гыйләҗев) [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 88].

4) **Билгесезлек алмашлыкларына** сорау алмашлыкларыннан -*дыр/-дер* яки *әллә* кисәкчәләре кушылып ясалган алмашлыклар керә: *кемдер, нәрсәдер, ниндидер, кайсыдыр, ничектер, каядыр, кайчандыр, әллә кем, әллә нәрсә, әллә нинди, әллә ничек, әллә кая, әллә кайчан*, *берничә* һ.б.: *Иван Илларионович җилкәсенә авыр йөк салган йөкче кебек иелеп нәрсәдер мыгырдады* (А. Гыйләҗев). Сорау алмашлыклары кебек үк *кемдер (әллә кем), нәрсәдер (әллә нәрсә)* – исем алмашлыкларына, *ниндидер (әллә нинди), кайсыдыр (әллә кайсы)* – сыйфат алмашлыкларына, *ничектер (әллә ничек), каядыр (әллә кая), кайчандыр (әллә кайчан)* – рәвеш алмашлыкларына, *берничә (әллә ничә)* – сан алмашлыкларына керәләр [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 89].

5) **Юклык алмашлыклары** шулай ук сорау алмашлыкларыннан ясалалар. Бу очракта сорау алмашлыкларына *һич* яки кисәкчә ролендә кулланыла торган *бер* сүзе кушыла: *һичкем, беркем, һичнәрсә, бернәрсә, һичнинди, бернинди, һичничек, берничек, һичкая, беркая, һичкайчан, беркайчан. Һичкем (беркем), һичнәрсә (бернәрсә*) – исем алмашлыклары, килеш һәм тартым белән төрләнәләр, җөмләдә ия яки тәмамлык булып

киләләр. *Һичнинди (бернинди)* – сыйфат алмашлыгы, исемне ачыклап, аергыч була. *Һичничек (берничек), һичкая (беркая), һичкайчан (беркайчан)* – рәвеш алмашлыклары, гадәттә фигыльне ачыклап, хәл булып киләләр. Юклык алмашлыклары күп очракта көчәйтү кисәкчәләре булган *да-дә* белән кулланылалар: *Варис белә: яңалык беркайчан да җиңел юл ярмый* (М. Хәсәнов) [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 90].

6) **Билгеләү алмашлыкларына** *бары, барча, барлык, бөтен, һәммә, һәр, һәрбер, үз(е)* алмашлыклары керә. Бу алмашлыкларның күбесе (*һәркем, һәрнәрсә, үз* алмашлыкларыннан башкалары) – сыйфат алмашлыклары, исемне ачыклап, җөмләдә аергыч булып йөриләр. Билгеләү алмашлыклары еш кына исемләшеп, килеш һәм тартым белән төрләнәләр, җөмләдә ия, тәмамлык булып киләләр: *Килергә тиешле иптәшләрнең һәммәсенә тиз-тиз хәбәр иттеләр* (Г. Ибраһимов). Билгеләү алмашлыкларыннан *һәркем* – затка карата, *һәрнәрсә* – башка предметларга карата кулланыла. Алар – исем алмашлыклары. *Һәркем үз уйларына чумды* (Г. Мөхәммәтшин). *Үз* исем алмашлыгы буларак, нинди дә булса затны (ә өченче затта предметны да) билгеләү, аерып күрсәтү өчен кулланыла һәм кайсы затны билгеләп килсә, шул затка караган тартым кушымчасы ала: *мин үзем укыйм* һ.б. [З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, 1972: 91].

Җ. Вәлиди исемнәрнең иярченнәре, алмашлар төрле исемнәр урынында кулланылалар, төрле җирдә, төрле сүз урынында килә ала һәм бер нәүгыдән булган төрле сүзнең урынын алмаштыра торган сүзләрдер, дип яза үзенең «Татар теленең граматикасы» хезмәтендә. Болар *зат алмашлары, рәвеш алмашлары, сан алмашлары, күргәзү алмашлары, сөаль алма алмашлары* исемнәре белән бишкә бүленәләр.

Зат алмашлары зат исеме урынында йөри торган алмашлар булып, барысы алтаудыр: *мин, син, ул, без, сез, алар*.

Рәвеш алмашлары – сыйфат исемнәре урынында кулланыла торган алмашлардыр. Болар ике төрле: 1) әйбернең рәвешен аңлатучы, ягъни *нинди? ни төсле? кайсы?* кебек сөальләргә җавап булучы алмашлардыр. Болар түбәндәгеләрдер: *шундый, андый, мондый, тегенди, шушындый, шундаен, мондаен*. 2) Эшнең рәвешен аңлатучы, ягъни *ничек? ни рәвешле?* кебек сөальләргә җавап булучы алмашлардыр: *шулай, алай, болай, тегеләй*.

Сан алмашлары нәрсәнең микъдарын белдереп, *никадәр? ни чаклы?* кебек сөальләргә җавап була: *аз, күп, һәммә, барлык, барча, бөтен*. Боларга югарыда мәзкүр саннарга махсус кушымталар кушылмый, тик *күп* дигән алмашка гына -*әү* кушымтасы кушыладыр: *күбәү*.

Күргәзү алмашлары бернәрсәгә ишарәне аңлата торган түбәндәге сүзләрдән торалар: *бу, шул, ул, теге, анавы, монавы, ушбу, шушы*.

Сөаль алмашлыгы сорауны аңлата: *кем, нәрсә, ни, нинди, кайсы, ничек, никадәр, ничаклы*. Болардан башка исемнәрнең ахырына тоташып килә һәм нисбәтне аңлата торган алмашлар бар. Болар *тоташ алмаш* дип атала. Болар өчәүдер:

| | | |
|---|---|---|
| Сөйләгеч өчен<br>Эндәшелгеч өчен<br>Гаип өчен | *-м/-м китабым*<br>*-ң/-ң китабың*<br>*-ы/-е, -сы/-се китабы, атасы* | *(күплеге – китабыбыз)*<br>*(күплеге – китабыгыз)*<br>*(күплеге – китаплары)* |

Гыйбад Алпаров алмашлыклар турында болай яза: алмашлыклар үзләрендә башка исемнәрдә табылган табигатьләрнең юклыгы белән, гомумән, ясаучы кушымчалар белән әйтелмәүләре һәм төрлекләр белән төрләнүдә дә беркадәр аерымлыклары булу белән аерылалар.

**Алмашларның төрләнеше.** Исем алмашлары шул ук исем төрлекләре белән төрләнәләр, ләкин аларның төрләнешләрендә фонетика ягыннан, башка исемнәргә караганда, байтак аерымлыклар бар. Бу аерымлык, бер яктан, төрлекләрнең үзгәреп әйтүендә булса, икенче яктан, алмашларның үзләре

үзгәреп йөрүендә күренә. Мәсәлән: *мин, син, ул, бу* алмашлары күплек санында *без, сез алар, шулар, болар* төрендә килә. *Мин, син, ул* алмашлары икенче рәттәге япсару төрлекләре белән бөтенләй төрләнмиләр. Чөнки алар үзләре япсару өчен йөргән сүзләр. *Бу, ни, ул, теге, кай* алмашларының япсару формалары *ансы, бусы, ние – нисе, нием, тегесе, кайсысы, алары, болары, ниләре, кайсылары* төрләре генә телебездә йөри. [Алпаров, 1945: 70]

Алмашларның 3 нче рәт килеш төрлекләре белән төрләнешләре түбәндәгечә була:

| Баш килеш | мин | син | ул | шул | бу | ни | теге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иялек к. | минем | синең | аның | шуның | моның | ninең | тегенең |
| Чыгыш к. | миннән | синнән | аннан | шуннан | моннан | нидән | тегеннән |
| Юнәлеш к. | миңа | сиңа | аңа | шуңа | моңа | нигә | тегеңә |
| Төшем к. | мине | сине | аны | шуны | моны | нине | тегене |
| Вакыт-урын к. | миндә | синдә | анда | шунда | монда | нидә | тегендә |
| Рәвеш к. | минемчә | синеңчә | аныңча | шуныңча | моныңча | ничек (ничә) | тегенеңчә |
| Ошату к. | миндәй (минди) | синдәй (синди) | андый | шундый | мондый | нинди | тегенди |

**Кушма алмашлар**. Сорау алмашлары булган *кем, нәрсә, ни, нинди, нигә, ничек, ничә, кай, кайсы, кая, кайчан* сүзләре алдыннан барлык, бөтенлек мәгънәсен аңлаткан *һәр* сүзе, юклык мәгънәсен *һич* сүзе, билгесезлекне аңлаткан *әллә* сүзе һәм билгесезлек – атаусызлык белдергән *бер* сүзе кушып,

икешәр, катлаулы кушма алмашлар ясала. Мәсәлән: *һәркем, һәрнәрсә, һәрничек, һәркайсы, һәркая; һичкем, һичнәрсә, һичнинди, һичкайсы, һичкая; әллә кем, әллә ни, әллә нигә, әллә ничә, әллә кай, әллә кайчан; бер кем, бер нәрсә, берничә, бер кая, бер кайдан* һ.б. *Һәр, һич, бер, кай, кайсы* сүзләре *бер* сүзенә кушылып та ике катлы алмашлар ясыйлар: *һәрбер, һичбер, бер-бер, кайбер, кайсыбер*. Шулай ук *һәрбер, һичбер* төрләре, яңадан әлеге сорау сүзләренең кайберләренә кушылып, өчәр катлы кушма алмашлар да ясый алалар, мәсәлән: *һәрбер нәрсә, һәрбер кем, һәрбер кайсы, һәрбер кайчан, һичбер кем, һичбер нәрсә, һичбер кая* һ.б. Кушма алмашлар үзләренең урыннарына һәм төрләренә карап, җөмләнең теләсә нинди бер кисәге булып йөри алалар.

В. Н. Хангилдин алмашлыкларны 6 төркемгә бүлә:

1) **Зат алмашлыклары.** Галим ике затны гына күрсәтә: беренче һәм икенче.

Болар мәгънәләре ягыннан бары тик беренче һәм икенче затларны гына күрсәтүче алмашлык булулары белән аерылалар: *мин – без* беренче затны (сөйләүчене), *син – сез* (тыңлаучыны) белдерәләр. Аларның синтаксик-морфологик үзенчәлекләре бар: а) алар тартым төрләнми, ә) кушымчага күчеп, исемнәрнең һәм фигыльләрнең хәбәрлек категориясен формалаштыруга катнашалар. Мәсәлән: *мин – студент, барачакмын, барачакбыз*.

Беренче һәм икенче зат алмашлыкларының лексик-морфологик төзелешләренә килгәндә, хәзерге татар телендә аларның берлек төрләре тамыр кисәктән генә тора кебек күренә, ләкин тарихи яктан караганда, аларның ике кисәккә бүленүе дә мөмкин: *мин+н, син+н.*

Беренче һәм икенче зат алмашлыклары исемгә якын торалар. Бу раслау аларның семантикалары буенча да аңлашыла, шул ук вакытта синтаксик үзенчәлекләре белән дә дәлилләнә. Алар җөмләдә ия һәм тәмамлык функцияләрен үтиләр һәм килеш формаларында да кулланылалар.

Өченче зат алмашлыгы. *Ул – алар* формасы. Ул сүзе зат алмашлыгы гына түгел, күрсәтү алмашлыгының бер төре булып та йөртелә. Ул затны гына күрсәтми, ә гомумән предметны аңлата [Хангилдин, 1959: 140].

2) **Күрсәтү алмашлыклары.** Боларның төп функциясе предметларга төбәп күрсәтү. Күрсәтү алмашлыкларының нигез төрләре: *бу, шул, теге, шуны, әнә, менә*.

Күрсәтү алмашлыкларының гомуми семантик билгеләнеше сөйләүчегә карата икенче чикнең якынлык-ераклык чамасын төбәп күрсәтүдән гыйбарәт. Алар аралык чикләренең ераклык чамасын төрлечә күрсәтәләр һәм шул функцияләре буенча өчкә бүленәләр: а) иң якын аралыкка ишарә итүчеләр; ә) чагыштырмача иң ерак аралыкны күрсәтүчеләр (*бу, шушы, менә*); в) уртача ераклыкка ишарә итүчеләр (*шул, ул*).

Күрсәтү алмашлыкларының башкалары төрле синтаксик функцияләрне үтәргә сәләтлеләр. Шул процесста алар исемләшәләр, төрле килеш формаларында да кулланылалар һәм мондый вакытта кайберләренең нигез кисәкләре төрле фонетик үзгәрешләр кичерәләр (*бу – моның, шул – шуның*) [Хангилдин, 1959: 143].

3) **Сорау алмашлыклары.** Бу алмашлыклар, төп функцияләре буенча сораулы сөйләм яки сорау җөмлә оештыру өчен куллана торган алмашлыклар. Нигез төрләре: *кем, ни, ник, кайсы, ничек* һ.б. Сорау алмашлыклары сорау бирү өчен файдаланылулары буенча бер төркемчә булып оешалар.

*Кем* алмашлыгы татар телендә затны гына (кешене) аңлата. *Ни, нәрсә* башка җанлы һәм җансыз предметларга карата сорау кую өчен кулланыла. *Ни, нәрсә* алмашлыклары телдә киң кулланыла, ләкин *ни* сүзе сөйләшү теле өчен характерлы. *Ни* алмашлыгы нигезендә бүтән сорау алмашлыклары да ясала: *нинди, ничә, ничек, ник*. *Нинди* алмашлыгы предметның охшатылышы, чагыштыруы, билгесенә ишарә итә. *Ничек* алмашлыгында да охшату-чагыштыру төшенчәсе бар, эшкә, хәлгә төбәлгән сорауны да белдерә. *Ничә*

алмашлыгы предметның сан билгесенә ишарә итүче булуы белән аерыла. *Ник* (*нигә*) алмашлыгы эшнең яки хәлнең сәбәбенә яки максатына ишарә итәләр. Сорау алмашлыкларының бер өлеше *кай* сүзе нигезендә формалашкан: *кай-сы, кай-чан* [Хангилдин, 1959: 145].

4) **Билгеләү алмашлыклары.** Бу алмашлыклар предметларны индивидуальләштереп яки җыеп билгеләүче булулары белән аерылалар. *Үз* – бу алмашлык, үзенең шул нигез формасында, янәшәлек юлы белән исемгә бәйләнеп, аергыч функциясендә килә һәм предметның затка нисбәт ителгәнлеген белдерә. *Һәр* – фарсы теленнән кергән сүз. Җөмләдә аерым кисәк булып, аергыч функциясендә килә һәм бер төрдәге предметларны сан ягыннан җыеп күрсәтә. *Барча* сүзе рәвеш формасында. *Барлык* сүзе сыйфатны чагылдыра, җөмләдә аергыч функциясен генә үти. *Һәммә* сүзе фарсы теленнән кергән, җөмләдә аергыч булып килә [Хангилдин, 1959: 149].

5) **Билгесезлек алмашлыклары.** Бу алмашлыклар предметның яки аның билгеләренең, яки эш-хәл белән бәйләнгән төрле хәлләрнең (вакыт, урын, сәбәп һ.б.) билгесезлеген аңлаталар. Билгесезлек алмашлыкларының барлыгы да ясалма-кушма төрдә була ала, алар сорау алмашлыклары нигезендә ясалганнар. Бер төре *–дыр/-дер, -тыр/-тер* (*ниндидер, кемдер* һ.б.) кисәкчәсе ярдәмендә ясалган. Икенче төре фразеологик төзелештә кулланыла: *әллә кем, әллә нинди* һ.б. [Хангилдин, 1959: 151].

6) **Юклык алмашлыклары.** Предметларның яки аларның билгеләренең, яки эш-хәл белән бәйләнгән хәлләрнең (вакыт, урын, сәбәп һ.б.) бөтенләй табылмавын, юклыгын аңлата торган алмашлыклар шушы төркемчәгә керәләр. Тамыр нигез төрләре юк, кушма төрдә генә булалар һәм кайбер сорау алмашлыклары нигезендә ясалалар. *Бер, һич* сүзе теркәлеп ясалалар: *беркем, берничек, һичкем, һичнәрсә* һ.б. *Кем, нәрсә, нинди* кебек нигезләрдән ясалганнары килеш белән дә төрләнәләр. Җөмләдә баш һәм иярчен кисәк булып киләләр, димәк исем белән мөнәсәбәттә. *Кайчан, ничек* сүзләре нигезендә ясалганнары җөмләдә фигыльгә янәшәлек белән бәйләнгән

хәл кисәк булалар, килеш белән төрләнмиләр, димәк рәвеш белән мөнәсәбәтлектә яшиләр [Хангилдин, 1959: 152].

Шулай итеп, В. Н. Хангилдин алмашлыкларны алты төркемчәгә бүлә. Һәрбер төркемчәне дәлилли, үзенең фикерләрен җиткерә. Ул мөнәсәбәт һәм тартым алмашлыклары төркемчәсен аерып чыгаруны кирәк дип санамый, чөнки тартым алмашлыкларын аерым төркем дип караучылар –ныкы/-неке кушымчасын күз алдында тоталар. Н. В. Хангилдин бу форманы алмашлыкның тартым белән төрләнешенең икенче формасы дип кенә карый. Мөнәсәбәт алмашлыкларына килгәндә, галим бу алмашлыкларны (мәсәлән, *кем, нәрсә, нинди* һ.б.) аерым лексик-морфологик төркемчә дип карарга нигез тапмый.

Хәзерге югары уку йортлары **Ф. М. Хисамова** «Татар теле морфологиясе» дәреслегеннән файдаланалар. Алмашлык башка сүз төркемнәре арасында үзенчәлекле урын алып тора. Лексик-семантик яктан ул чынбарлык күренешләрен турыдан-туры атамый, ә аларга күрсәтә һәм сөйләмдә башка сүз төркемнәрен алыштырып килә. Морфологик яктан алмашлыклар үзләре алыштырган сүз төркемнәренең грамматик билгеләрен алалар. Синтаксик яктан шулай ук үзе алыштырган сүзләр вазифасын башкара, күп төрле җөмлә кисәге булып килә ала. Алмашлык предмет, зат, билге мәгънәләренә гомуми рәвештә күрсәтеп, исем, сыйфат, рәвеш, сан сүз төркемнәрен алыштыра һәм аларның грамматик үзенчәлекләрен үзендә чагылдыра. Нинди сүз төркемен алыштыруларына карап, алмашлыклар түбәндәге төркемчәләргә бүленәләр:

1) исем алмашлыклары – предмет мәгънәсен белдерәләр (*мин, син, һичкем, нәрсә* һ.б.);

2) сыйфат алмашлыклары – предмет һәм затларның билгеләренә ишарә итәләр (*бу, шушы, бөтен, һәр* һ.б.);

3) сан алмашлыклары – предмет яки затның санына күрсәтәләр (*ничә, ничәшәр, күпме* һ.б.);

4) рәвеш алмашлыклары – эш-хәл яки билге билгесенә күрсәтәләр (*ничек, болай, шулай, нигә* һ.б.) [Ф. М. Хисамова, 2006: 143].

Мәгънәләре буенча алмашлыкларны җиде төркемчәгә бүлә:

1) **Зат алмашлыклары**: *мин, син, ул, без, сез, алар*. Алар исемне алмаштыралар, сөйләмдә актив кулланылалар. Мәсәлән: *Алар (шәкертләр) озак уйлап тормыйча, алты прибор һәм 18 пәрәмәч китерергә куштылар* (Ф. Әмирхан).

Семантик яктан *ул* алмашлыгының төрле килеш формалары шәхескә мөнәсәбәтле рәвештә кулланыла: *аңар, аңа, аның*. Мәсәлән: *Шул белемсез нәрсәләрне аның беләсе, менә хәзер беләсе килә башлады* (Ф. Әмирхан). Күплектәге алмашлыкларның төрләнеше структур яктан исем төрләнешеннән аерылмый: без – безнең – безгә [Ф. М. Хисамова, 2006: 146].

2) **Күрсәтү алмашлыклары:** *ул, бу, шул, теге, әнә, болай* һ.б. Алар зат яки әйберләргә күрсәтү, сыйфат яки рәвешләргә ишарә итү өчен кулланыла. Мәсәлән: *Хәсәннең бу карточкадагы дүрт иптәшеннән икесе бөтенләй европейский киемнән төшкән.*

Сүз төркемнәренә мөнәсәбәте буенча күрсәтү алмашлыклары сыйфат һәм рәвешне алыштыра. Сыйфатны алыштырган күрсәтү алмашлыклары исем белән белдерелгән кисәкне ачыклап, аергыч ролендә киләләр: *Кем белә, бәлки, бу исем астында аның әллә нинди кадерле хатирәләре саклангандыр*. Рәвешне алыштырып, күрсәтү алмашлыклары фигыльне ачыклап киләләр. Мәсәлән: *Бу юлы да шулай булды* [Ф. М. Хисамова, 2006: 148].

3) **Сорау алмашлыклары**: *кем, ни, нәрсә* (исем алм.); *кайсы, нинди* (сыйфат алм.); *кая, ник, ничек* (рәвеш алм.); *ничә, никадәр, ничаклы* (сан алм.) һ.б. алмашлыклар керә. Алар әйберне, затны, билгене белдерәләр һәм эшне үтәлү рәвеше, урыны, вакыты, сәбәбе, максаты ягыннан ачыклап, сүзләргә күрсәтеп киләләр. Мәсәлән: *Пластинкаларын кем алган иде моның?* [Ф. М. Хисамова, 2006: 149].

4) **Билгеләү алмашлыклары**: *үз, бары, һәр, бөтен, һәммә, барча* һ.б. Сыйфат төркеме белән тыгыз бәйләнештә, һәм алар җөмләдә предмет билгесен күрсәтәләр. Мәсәлән: *Һәр җир карланган, сулар бозланган* (Г. Тукай). *Үз* – мөстәкыйль рәвештә генә килгәндә, бу алмашлык затларга күрсәтә, килеш белән төрләнә: *үзем, үземне, үземә.* Мәсәлән: *Сандугач әле һаман үзенең сөеклесе алдында җырлап армаган иде*. *Барлык, барча, һәммә, бөтен* алмашлыклары предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтәләр: *барлык кешеләр*. *Һәр, һәрбер, һәрнәрсә* кебек алмашлыклар предметларга, затларга яки төркемнәргә аерып, аерым-аерым күрсәтәләр: [Ф. М. Хисамова, 2006: 151].

5) **Билгесезлек алмашлыклары** ике төрле юл белән ясалалар:

– сорау алмашлыкларына билгесезлек белдерә торган *-дыр/-дер* кисәкчәсе ярдәмендә: *кемдер, нәрсәдер, каядыр, кайчандыр* һ.б. Кисәкчә килеш, тартым, сан кушымчаларыннан соң ялгана: *Хәсән, кемнәрнедер күзәтеп, пластинкаларны үзе сайларга тотынды* (Ф. Әмирхан);

– сорау алмашлыклары алдыннан *әллә* кисәкчәсе килә: *әллә кем, әллә нәрсә, әллә ни* һ.б. *Хәсән Исмәгыйльләргә барырга әллә кайчан риза иде инде* [Ф. М. Хисамова, 2006: 153].

6) **Юклык алмашлыклары**: *һичкем, беркем, һичнәрсә, бернәрсә* (исем алм.); *һичнинди, бернинди* (сыйфат алм.); *һичничек, һичкая, берничек* (рәвеш алм.) кебек алмашлыклар керә. Алар сорау алмашлыклары нигезендә барлыкка киләләр, *бер* яки *һич* кисәкчәсе ялганып ясалалар. Сөйләмдә *бер, һич* сүзләре үзләре генә дә юклык алмашлыгы мәгънәсендә кулланылырга мөмкин [Ф. М. Хисамова, 2006: 154].

7) **Тартым (нисбәтләү) алмашлыклары**. Бу алмашлыклар грамматикада соңрак урын ала башлады. *-ныкы/-неке* кушымчасы ялганып ясалган алмашлыкларны (*минеке, безнеке*) аерым төркемчә дип санарга мөмкин. Бу кушымчаны алган сүзләр алга таба да килеш, тартым, сан белән төрләнә алалар: *минеке, минекенең, минекеләрне* [Ф. М. Хисамова, 2006: 156].

Күргәнебезчә, Ф. М. Хисамова алмашлыкларны җиде төркемчәгә бүлә. Шуңа да карамастан, дәреслек белән «Татар теле грамматикасы» (II том) арасында аермалыклар бар.

1) Академик грамматикада алмашлык төшенчәсен аңлату ВУЗ дәреслекләрендә кебек түгел: алмашлык – объектив чынбарлык күренешләрне атамый, бары тик аларга ишарәли генә торган сүз төркеме [Татар грамматикасы, 2002: 305].

2) «Татар теле грамматикасы»нда тартым төркемчәсе күрсәтелмәгән. Ул зат алмашлыклары эчендә карала. Зат алмашлыкларында лексик эчтәлекнең каршы торуы нәтиҗәсендә тартым категориясе өлешчә генә чагылыш таба: *ул – анысы, алар – алары*. Ләкин бу алмашлыклар, иялек килеше һәм -*нык*ы/-*неке* кушымчаларын алып, иялек мөнәсәбәтен белдерүдә катнашалар: *мәктәп безнеке* [Татар грамматикасы, 2002: 312].

3) «Татар теле грамматикасы»нда нинди сүз төркемен алыштыруларына карап исем, сыйфат, сан, рәвешкә генә түгел, ә тагын фигыль (итү, нитү, нихәл итү, фәлән итү сүзләре), теркәгеч (шунысы, шулкадәр, кемнең), кисәкчә (әнә, менә, әле, бары) күрсәтелгән.

**Нәтиҗә** ясап әйткәндә, алда карап үтелгән галимнәрнең хезмәтләрендә алмашлыклар арасында бик зур аерымлыклар юк. Бары тик алмашлыкларның мәгънә төркемчәләре буенча гына фикерләр төрле. Мәсәлән, Ф. Хисамова, Ф. Сафиуллина, Ч. Харисова, Д. Тумашева тартым алмашлыкларын аерым бер төркемчә буларак караса, ә В. Хангилдин, З. Вәлиуллина, К. Зиннәтуллина, М. Сәгыйтов алмашлыкларны мәгънә төркемчәләре ягыннан алтыга бүлеп карыйлар. Безгә Ч. Харисова, Ф. Хисамованың карашлары якын.

## 1.2. Хәзерге программа һәм дәреслекләрдә алмашлык сүз төркемен өйрәтүнең торышы

Бүгенге көндә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбендә татар телен өйрәнү телнең төрле катламнарына караган теоретик материал белән бергә,

татар теленең сүзлек байлыгын, мәгънәви һәм кулланылыш үзенчәлекләрен камил куллана белергә, туган телнең сыгылмалылыгын, аралашу процессында ачыла торган нечкәлекләрен, үзенчәлекләрен өйрәтүне дә күздә тота. Мәктәпләрдә татар теленнән белем бирүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм иң мөһиме — аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә өйрәтүне, заманча технологияләрне файдаланып, телнең психолингвистик үзенчәлекләренә, мәдәният белән бәйләнешенә игътибар бирүне дә таләп итә. Бүгенге җәмгыятьтә барган үзгәрешләр татар телен укытуга яңа таләпләр куя. Беренче чиратта, туган теле дәресләре тел системасын, аның үзенчәлекләрен күзаллаган, милли үзаңга ия, милли менталитетны һәм психологияне аңлаган, заман таләпләренә җавап бирерлек күпкырлы шәхесләр тәрбияләүгә юнәлгән булырга тиеш. Әлеге таләпләр уку-укыту методикасын яңартуны, белем бирүгә яңача якын килүне, хәзерге җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең бала психологиясенә тәэсирен аңлауны һәм шулар нигезендә укыту эчтәлеген яңарту, уку-укытуның яңача алымнарын эзләү бурычын куя.

Рус мәктәпләрендә төрле авторларның татар теле программаларын карап, анализ ясадым: рус балалары татар телен туган тел буларак өйрәнгәндә, алмашлыклар ничәнче сыйныфларда һәм ни күләмдә өйрәнелә икән. Әлбәттә, рус мәктәпләрендә сәгать саны кимеде, кайбер мәктәпләрдә – 3, мин эшләгән гимназиядә, мәсәлән, 2 сәгать кенә калды. Шуңа күрә укытучыларга бик авыр, чөнки алар бөтен теманы да азмы, күпме кыска вакыт эчендә укучыларга өйрәтергә, аңлатырга тырышалар.

**Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева** «Күңелле татар теле» дип исемләнгән курс күп мәктәпләрдә эшләп килә. Мин үзем дә 36 нчы гимназиядә Хәйдәрова дәреслекләре белән эшләдем. 1 нче сыйныфта укучылар зат, кайбер күрсәтү (*бу*), сорау алмашлыклары белән танышалар.

Планлаштырылган нәтиҗәдән күренгәнчә, укытучылар 1 нче сыйныф укучыларына исемнәргә *кем? нәрсә?* сорауларын куя белү, зат алмашлыкларын берлектә баш, иялек, юнәлеш килешләрендә сөйләмдә куллану белән таныштыру, *бу* күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану, *кая? кайда? кайдан? ничә? ничек? нинди?* сорауларына җавап бирә белү күнекмәләрен өйрәтәләр. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

2 нче сыйныфта (Күңелле татар теле. 2 класс. **Р. З. Хайдарова, Н. Г. Галиева, Г. М. Әхмәтҗанова**) укучылар *мин, син* зат алмашлыкларын юнәлеш килешендә сөйләмдә кулланырга, зат алмашлыкларын күплектә сөйләмдә кулланырга өйрәнәләр, *кайчан?* сорау алмашлыгы белән танышалар. Шулай ук *кем? нәрсә? кайда? кая? кайдан? нинди? ничек? ничә? ничәнче?* сорауларына җавап бирә, аларны кулланып, сорау бирә белүне камилләштерәләр. *Бу, ул* күрсәтү алмашлыклары темасы да аерым дәрес итеп каралган. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

3 нче сыйныфта (Күңелле татар теле. **Р. З. Хәйдәрова, Л. Ә. Гыйниятуллина, Г. М. Әхмәтҗанова**) укучылар *һәр, һәркем, барлык* алмашлыклары белән танышалар; зат, сорау, күрсәтү (*бу, менә*) алмашлыкларын куллану күнекмәләрен ныгыталар. Зат алмашлыкларының иялек һәм юнәлеш килешләрендә кулланылуы, *үз* алмашлыгының тартым белән төрләнеше, *ул* алмашлыгының килешләр белән төрләнеше аерым дәресләрдә өйрәнелә. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

4 нче сыйныфта (Күңелле татар теле. **Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ә. Гыйниятуллина**) *мин, син* зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә кулланышы, *кемдер, нәрсәдер* алмашлыклары белән таныштыру, бәйлекләрнең исемнәр һәм алмашлыклар белән кулланылышы өйрәнелә. Күрсәтү, зат алмашлыклары, зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, *син* алмашлыгының килеш белән төрләнеше аерым дәрес темалары булып бара. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

5 нче сыйныфта (Татар теле. **Хәйдәрова Р. З., Г. М. Әхмәтҗанова**) түбәндәге темалар өйрәнелә: зат алмашлыклары, зат алмашлыкларының юнәлеш килешендә төрләнеше, *мин, син, ул* зат алмашлыкларының төшем килешендә сөйләмдә кулланылышы, сорау алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары (*бу, әнә, менә*), тартым алмашлыклары, билгеләү *(барлык, бөтен, үз, һәр),* билгесезлек *(әллә кем, әллә нинди, кайбер)*, юклык *(беркем дә, бернәрсә дә, һич)* алмашлыклары, алмашлыкларны кабатлау, «Сыйфатлар, алмашлыклар» темасы буенча контроль эш. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

6 нчы сыйныфта (Күңелле татар теле. **Р. З. Хәйдарова, З. Р. Нәҗипова**) укучылар сорау, күрсәтү алмашлыкларын сөйләмдә танырга, дөрес кулланырга өйрәнәләр. *Белән, кебек, өчен, соң, аша* бәйлекләрен исемнәр һәм алмашлыклар белән сөйләмдә кулланышын ныгыталар. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

7 нче сыйныфта (Татар теле. **Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова, Р. Л. Малафеева**) алмашлык аерым бер тема буларак каралмый. Бары тик укучыларның сөйләмендә генә кулланыла һәм кабатлана. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

8 нче сыйныфта (Татар теле. **Р. З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева**) укучылар тарафыннан үзләштерелергә тиешле материалга билгеләү, билгесезлек, юклык, тартым алмашлыкларының сөйләмдә еш кулланыла торган очраклары белән таныштыру кирә. 11 нче сыйныфта укучылар зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, алмашлык төркемчәләре кабатлап үтәләр. [https://edu.tatar.ru/aviastroit/about/page2609267.htm]

**К. С. Фәтхуллова** программалары буенча 1 нче сыйныфта укучылар зат алмашлыкларыннан *мин, син, ул, без, сез, алар* сүзләре белән танышалар, *кем, нәрсә, кемнеке, кайда, кая, кайдан, нишли, нинди, ничә, ничәнче* сорау алмашлыкларына җавап бирергә өйрәнәләр. 2 нче сыйныфта укучылар *кем, нәрсә, нишли, нишлиләр, кая, кайда, кайдан* сорауларына җавап бирү

калыпларын ныгыталар. 3 нче сыйныфта укучылар *һәр* билгеләү алмашлыгы, *теге* күрсәтү алмашлыгы белән якыннан танышалар. Шулай ук *нишләде?* соравына җавап бирергә өйрәнәләр һәм *шул* алмашлыгының килеш белән төрләнешен дә өйрәнеп китәләр. [https://edu.tatar.ru/nsav/page2297.htm/page1070681.htm]

**Ф. Ф. Харисовның, Ч. М. Харисованың** 1 – 4 сыйныфларда рус мәктәпләрендә ана теле укыту программасы буенча 1 нче сыйныф укучылары *кем, нәрсә, ничә, ничек, кая, кайда, кайдан, кемнең, нишли, кайсы* сорау алмашлыклары белән танышалар, *мин, син, ул, минем, синең, аның, аңа* зат алмашлыкларын өйрәнәләр һәм аларны кулланып, предметның кемгә караганлыгын белдерергә өйрәнәләр. 2 нче сыйныфта укучылар алда өйрәнгән алмашлыкларны ныгыталар, алар җөмләләрдәге *кем? нәрсә? нинди? кайсы? нишли?* сорау алмашлыкларына җавап бирә торган сүзләрне табып әйтәләр, һәм шул сүзләр белән җөмләләр төзергә өйрәнәләр. 3 нче сыйныфта укучылар зат алмашлыклары, аларның мәгънәсен, килеш белән төрләнешен, сорау алмашлыклары турында мәгълүмат алалар. Ә 4 нче сыйныфта тартым алмашлыклары, аларның мәгънәләре, тартым алмашлыкларының сөйләмдә дөрес кулланылышын, шулай ук күрсәтү алмашлыклары, рус телендә бу алмашлыкларның мәгънәләрен белдерү юлларын өйрәнәләр. Алмашлык – 6 нчы сыйныфта үтелә торган сүз төркеме. Башлангыч сыйныфларда зат һәм сорау алмашлыклары өйрәнелгәнгә күрә, калган биш төркемчәгә вакыт күбрәк бирелә. Аларның сөйләмдәге әһәмияте ассызыклана, морфологик анализ ясау күнекмәләре дә тәрбияләнә. Ә югары сыйныфларда морфология кабатланып китә һәм ныклап синтаксис өйрәнелә. [Харисов, 2003: 5-16]

**Ф. С. Сафиуллина** дәреслеге буенча эш программасында 6 нчы сыйныф укучылары алмашлык мөстәкыйль сүз төркемен танырга һәм кулланырга өйрәнәләр. Ф. С. Сафиуллина, К. С. Фәтхулова 9 нчы сыйныф дәреслегендә алмашлык һәм аның төркемчәләре өйрәнелә. [https://edu.tatar.ru/upload/images/files/татар%20теле(25).pdf]

**И. Л. Литвинов, Э. Р. Садыйкова, Л. И. Гарипова** төзегән 1 нче сыйныф өчен татар теле дәреслегендә укучылар *кем? нәрсә? нинди?* сорау алмашлыкларын актив кулланырга өйрәнәләр; *мин, син, ул, алар* алмашлыкларын өйрәнеп, аларны сорау җөмләләрдә куллану күнекмәләрен ныгыталар. 2 нче сыйныфта укучылар *без, сез* алмашлыкларын җөмләләрдә куллануны активлаштыралар. 3 нче сыйныфта килеш белән төрләнгән зат алмашлыкларын, күрсәтү, сорау, тартым алмашлыкларын сөйләмдә дөрес кулланугa ирешү каралган. Ә 4 нче сыйныфта укучылар күрсәтү алмашлыкларының (*бу, теге*) килеш формаларын, *әнә, менә* алмашлыкларын дөрес куллануга ирешәләр. [https://edu.tatar.ru/nsav/page2298.htm/page488879.htm]

**В. Н. Мещерякова, Р. Р. Нигъматуллинаның «Татарча да яхшы бел»** курсында 1 нче сыйныф укучылары зат алмашлыкларын берлектә баш, иялек, юнәлеш килешләрендә, *бу* күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану белән танышалар. *Кая? кайда? кайдан? ничә? ничек? нинди?* сорауларына җавап бирә белергә өйрәнәләр. **Р. Р. Нигъмәтуллина, Ф. С. Фәизова** 5 нче сыйныф өчен татар теле дәреслегендә алмашлыкларның төркемчәләрен, сөйләмдә алмашлыкларның төрле төркемчәләрен куллануны өйрәнү өчен 10 сәгать каралган. Монда зат, сорау, күрсәтү (*бу, әнә, менә*), билгеләү (*барлык, бөтен, үз, һәр*), юклык (*беркем дә, бернәрсә дә*), тартым алмашлыклары ныклап өйрәнелә. Ә 6 нчы сыйныфта исә билгесезлек (*әллә кем, әллә нинди, кайбер*), юклык (*беркем дә, бернәрсә дә, һич*) алмашлыклары, *үз* билгеләү алмашлыгы ныклап өйрәнелә. 7 нче сыйныфта билгесезлек алмашлыклары өйрәнелә. 8 нче сыйныфта сорау алмашлыклары кабатлана. 9 нчы сыйныфта билгеләү һәм билгесезлек алмашлыклары, алмашлыкларны сөйләмдә куллану дәресләре каралган. [https://edu.tatar.ru/nsav/page2298.htm/page488879.htm]

**«Сәлам»** программасы буенча да 1 нче сыйныф укучылары зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнгән формалары һәм сорау алмашлыклары белән танышып, аларны үз сөйләмендә актив кулланырга

өйрәнәләр.[https://cloud.mail.ru/public/Q7MF/uQsXeBtyx/Татарский%20язык%20и%20татарская%20литература/]

**Нәтиҗә** ясап әйткәндә, кайсы гына программаны карасак та, башлангыч сыйныфларда зат һәм сорау алмашлыклары яхшылап өйрәнелә, ә калган төркемчәләр инде урта сыйныфларда төптән өйрәнелеп, югары сыйныфларда кабатланып кына үтелә.

### Беренче бүлек нәтиҗәләре

1. Алмашлык сүз төркемен өйрәнү тарихы бик күп талантлы галимнәрнең исемнәре белән бәйле. Аны аерым сүз төркеме буларак үзенең хезмәтләрендә А.Казембек, К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Г.Алпаров, В.Н.Хангилдин, З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, Д. Г. Тумашева кебек атаклы телчеләр бүлеп чыгарган. «Алмашлык» термины беренче тапкыр М. Корбангалиев һәм Х. Бәдигый тарафыннан язылган «Татар теле сарыфы» хезмәтендә кулланылган, ә башка атамаларының өйрәнелеше Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Л.Җәләй, Г.Нугайбәк һ.б. исемнәре белән бәйле. Алмашлыкны төркемчәләргә бүлеп өйрәнгән авторлар арасыннан Ч. М. Харисова, Ф. С. Сафиуллина, Д. Г. Тумашева, З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, В. Н. Хангилдин, Ф. М. Хисамова һ.б. атарга була. һәрберсе алмашлыкка аңлатма бирә, аның грамматик һәм мәгънә буенча төркемчәләрен аерып чыгара.

2. Хәзерге программа һәм дәреслекләрдә алмашлык сүз төркемен өйрәтүнең торышы (Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева, Г. М. Әхмәтҗанова, З. Р. Нәҗипова, Р. Л. Малафеева; К. С. Фәтхуллова; Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова; Ф. С. Сафиуллина; И. Л. Литвинов, Э. Р. Садыйкова, Л. И. Гарипова; В. Н. Мещерякова, Р. Р. Нигъматуллина, Ф. С. Фәизова) буенча түбәндәге нәтиҗәне чыгарам: башлангыч сыйныфларда зат, сорау алмашлыклары, *бу* күрсәтү алмашлыгы яхшылап өйрәнелә, ә калган алмашлыкның мәгънә төркемчәләре (билгеләү, билгесезлек, юклык, тартым)

урта сыйныфларда төптән өйрәнелеп, алмашлык гомумән югары сыйныфларда кабатланып кына үтелә.

## II БҮЛЕК. Рус мәктәпләрендә укучыларга алмашлыкны уен технологияләре кулланып өйрәтү нигезләре

### 2.1. Яңа педагогик технологияләрнең берсе буларак уен технологиясе

Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы артты. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә. Шулай да педагогикага яңалык башка фәннәргә һәм тармакларга караганда авыррак керә. Бу хәлнең сәбәбе, бәлки, кешене укыту-тәрбияләүнең гаять дәрәҗәдә авыр булуыннан киләдер. Кайбер яңалыклар киң күләмдә кулланылмау нәтиҗәсендә кире кагыла һәм бик тиз онытыла. Хәзерге чорда укытучы күптөрле мәгълүматлар чолганышы эчендә калды. Алар алдында яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып, аны үзләштерү зарурлыгы туды.

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен алдан уйлап, башкарырга тиешле эшләрне системага салып кую укыту-тәрбия процессында уңышка ирешергә ярдәм итә.

Татар теле һәм әдәбиятын яңа технологияләр аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү. Бүгенге көндә халык мәгарифе икътисадын, укыту техникасын һәм технологиясен, укытуны компьютерлаштыру мәсьәләләрен өйрәнү-тикшеренү эше киң җәелде. Шуңа бәйле рәвештә педагогик технология, педагогик техника төшенчәләре дә актив кулланылышка керде.

Энциклопедик сүзлектә технология – (грек теленнән алынган сүз; сәнгать, осталык дигән мәгънәне белдерә) фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланылучы методлар, алымнар, ысуллар

җыелмасы ул. [Харисов, 2015: 202] Иҗади үсеш технологиясен гамәлгә куючы галимнәрнең берсе Ә. З. Рәхимов: «Технология – дәрестә укучыларның иҗади уку эшчәнлеген оештыру механизмы», – дип дөрес билгели. [Харисов, 2015: 202] «Технология» термины укытучының үз эшендә куллана торган алым һәм ысуллар җыелмасын, шулай ук татар теленә өйрәткәндә файдаланыла торган уку материалларын (УМК, компьютер технологиясе, аудио- һәм видеоматериаллар) да күздә тота.

Педагогик технология – белем бирү һәм тәрбияләү процессында психологик һәм педагогик яктан нигезләнгән, системалы һәм планлаштырылган нәтиҗәләргә алып барырдай итеп кулланыла торган махсус формалар, алымнар, методлар һәм ысуллар җыелмасы. Аның бурычы – укыту процессын, яңалыклар кертеп, даими камилләштереп тору, яңа дәреслекләр, укыту өчен кинофильмнар, компьютерларга программалар һ.б. ярдәмлекләр төзү. Педагогогик технология төшенчәсенә күренекле педагог-галимнәрнең аңлатмалары төрлечә. Б. Г. Лихачев фикеренчә, педагогогик технология – укыту процессындагы махсус ысуллар, алымнар, психологик-педагогик юнәлешләр җыелмасы; ул – педагогик процессны оештыруның төп коралы. [Лихачев, 1998: 9] В. П. Беспалько педагогик технологияне «укыту процессын тормышка ашыруда эчтәлекле техника» дип саный.[Беспалько, 1989: 12] И. П. Волков бу терминны укытуның көтелгән нәтиҗәләрен тасвирлау процессы буларак карый. [Волков, 1989: 16] М. А.Чошанов белем бирү технологиясен дидактиканың состав өлеше дип билгели. [Чошанов, 1996: 5-7] Г. К. Селевко «педагогик технология» төшенчәсен өч яссылыкта тикшерә: беренчесе – фәнни, ягъни педагогика фәнен «белем бирүнең максатын, эчтәлеген һәм методларын өйрәнә, шулай ук педагогик процессларны проектлый»; икенчесе – процессуаль-тасвирлаулы, ягъни күз алдында тотылган нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәк булган максат, эчтәлек, метод, ысул һәм алымнардан торган процессны тасвирлый; өченчесе – процессуаль-тәэсирле, ягъни педагогик процессны гамәлгә ашыру, «барлык

шәхси, инструменталь һәм методологик-педагогик чараларны эшкә җигү». [Харисов, 2015: 203]

Педагогик технологияләр бер-берсеннән төрлечә аерыла:

– килеп чыгышлары ягыннан (педагогик тәҗрибә яки фәнни концепция нигезендә);

– максатлары һәм бурычлары ягыннан (белемне үзләштерү һәм ныгыту, табигый һәм шәхси сәләтне үстерү һәм камилләштерү);

– педагогик чараларның мөмкинлекләре ягыннан (кайсы чаралар иң яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә);

– укытучы эшчәнлеге ягыннан (диагностика ясау яки конфликтны хәл итү һ.б.);

– педагогик процессның кайсы өлкәсенә хезмәт итүе ягыннан һ.б. [Харисов, 2015: 203-204]

Г. К. Селевко педагогик технологияләрне түбәндәгечә классификацияли һәм аларның йөзгә якын төрен билгели:

– гуманлы шәхес тәрбияләүгә юнәлтелгән педагогик технологияләр;

– укучылар эшчәнлеген активлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр;

– уку эшчәнлеген нәтиҗәле итеп оештыру һәм идарә итүгә юнәлтелгән педагогик технологияләр;

– хосусый предметларга караган педагогик технологияләр;

– альтернатив технологияләр;

– үстерелешле укыту технологияләре;

– яңа мәгълүмати чараларны куллану технологияләре;

– иҗтимагый тәрбия технологияләре;

– тәрбия технологияләре;

– авторлык мәктәбендәге педагогик технологияләр;

– хәзерге мәгариф системасындагы педагогик технологияләр һ.б. [Харисов, 2015: 204]

Педагогик технологияләрнең төп билгеләре:

– технологиянең нигезенә аерым бер авторның яки авторлар коллективының фәлсәфи, психологик, дидактик һәм методологик фикерләре салына;

– укыту технологиясе укытучы белән укучының бердәм эшен аерым якын килеп, техник һәм компьютер чараларын файдаланып оештыруны күздә тота;

– укыту технологиясе күптөрле бурычларны, шул исәптән мөмкин кадәр азрак көч түгеп, югары нәтҗәләргә ирешүне максат итеп куя;

– педагогик технологияләр барлык укытучылар һәм укучылар ирешердәй нәтиҗәләрне истә тотып планлаштырыла. [Харисов, 2015: 205]

Шулай итеп, педагогик технология белем бирүнең иң уңышлы юлларын өйрәнүче фән буларак та, педагогик процесста кулланыла торган ысуллар, чаралар системасы буларак та, белем бирү процессы буларак та билгеләнә. Хәзерге заман таләпләренә туры килә торган белем бирү шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш сынауларына, фән нигезләрен ныклы үзләштерүгә әзерләүне күздә тота. Заманча технологияләр кулланып татар телен өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыру ул. Ул түбәндәге максатларны күздә тотып башкарыла: 1) татар телен өйрәнүгә кызыксындыру, теләк уяту; 2) укучыларның танып белү активлыгын арттыру; 3) телне өйрәнү өчен уңай шартлар булдыру; 4)укучыларның иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу.

Белем бирү технологияләре күп төрле. Шулай да алар арасында охшашлыклар күзәтелә. Максаты, эчтәлеге, кулланылган ысуллары, алымнары һәм чараларының охшашлыгы буенча технологияләрне берничә зур төркемгә берләштерергә мөмкин. Мәсәлән: укучылар эшчәнлеген активлаштыру, интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр; уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр; уку материалын методик яктан камилләштерүгә,

дидактик яктан үзгәртүгә нигезләнгән педагогик технологияләр; халык педагогикасына нигезләнгән педагогик технологияләр һ.б.

Соңгы елларда белем бирү системасында заманча технологияләрдән уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр (терәк схемалар кулланып, алга китеп укыту технологиясе, белем бирүнең компьютер технологияләре, үстерелешле укыту технологиясе, проектлар методы, концентрик белем бирү технологиясе) һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр (уен технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, аралашуга өйрәтү технологиясе) уңышлы кулланыла.

Укыту процессында уен технологиясе аерым игътибар таләп итә, чөнки, безнең уйлавыбызча, телне өйрәнгән вакытта, уен кызыксыну уятучы, дәртләндерүче фактор булып тора. Балаларның бай рухлы, сау-сәламәт булып үсүендә уеннарның әһәмияте зур. Өлкәннәргә эштән бушаган вакытларда күңел ачу, ял итү, вакыт уздыру чарасы булса, бала өчен уен – чын шөгыльгә, тормыш көрәшенә һәм хезмәткә әзерләнү ул. Уеннарның эчтәлегенә күз салсаң, аларның тормыш-көнкүрешнең һәм хезмәт төрләренең бер чагылышы икәненә ышанасың. Уен дигәндә, кешелек җәмгыятенең үсеш дәверендә хезмәт формаларын чагылдыру рәвешендә барлыкка килгән, яшь буынны физик һәм әхлакый, эстетик яктан тәрбияләү вазыйфасын һәм шулай ук олылар өчен күңел ачу, вакыт үткәрү һәм көнкүрештә берәр эш-шөгыльне, йоланы үтәү вазыйфасын башкаруы мавыктыргыч чаралар системасын аңлыйбыз. Укучыларның белем һәм күнекмәләрен арттыруда, аларның үз фикерләрен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, укыту һәм тәрбиянең бердәмлегенә ирешүдә, шулай ук балаларны тел фәне белән кызыксындыруда уеннарның әһәмияте зур. Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар укучыларны активлаштыра, аларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә һәм иҗади халәт булдыра. Уеннар вакытында фән нигезләрен үзләштерү белән бергә укучы үз фикерләрен дәлилли белү

күнекмәләре дә ала. Шулай итеп, уеннар бала тормышында әһәмиятле урын алып торалар, белем һәм тәрбия бирүдә мөһим чыганак булалар.

Дәресне тулысынча уен формасында үткәрергә дә, моңа аның бер өлешен генә багышларга да мөмкин. Укырга-язарга өйрәтү, дөньяны танып белү, тәҗрибә туплау, тәҗрибә уртаклашу, фән-техника, сәнгать яңалыклары белән танышу, иҗат итү тел ярдәмендә генә була ала. Тел кешенең барлык иҗтимагый эшчәнлеген оештыра. Шуңа күрә дә борын заманнан ук һәр халык балаларны ана теленә ныклап өйрәткән, аның телен шомартуга, сөйләгәндә һәм язганда аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткән. Һәр ана, баласына «тел ачкычы» бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган; үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән. Аеруча кече яшьтә балага белем һәм тәрбия уен аркылы бирелә, уйнаган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала. Шуның өчен укытучы, татар теле фәненнән белем һәм тәрбия бирү бурычын күздә тотып, тел дәресләрендә балаларның уеннарын максатка ярашлы итеп оештырырга тиеш. Уеннар яки уен элементлары кергән дәресләр укучының татар теле белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, зирәклеген үстерә, алга билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә. Татар теле дәресләрендә кулланылган уеннар балаларга ныклы белем бирергә, тотрыклы күнекмәләр булдырырга, мөстәкыйль рәвештә танып белү эшчәнлеге белән кызыксынуларын уятырга ярдәм итәләр. Уеннар һәм уен элементлары кулланылган дәрестә укучы актив катнаша, мөстәкыйль фикер йөртә, һәр яңаны нәтиҗәле итеп тану ысуллары белән коралллана. Мондый дәресләрдә грамматик теорияне һәм сөйләм практикасын үзләштерү процессы уңышлы барачак. Татар теле дәресләрендә, аерым тел фактын өйрәнгәндә, сөйләү һәм язу күнекмәләре биргәндә, мавыктыргыч уеннар белән читенлек ситуациясе тудырылырга, уен элементлары кертеп, проблемалы сорау һәм мәсьәләләр куелырга тиеш. Аларны чишү балада үз көченә ышану тойгысы уята, аннан зуррак эшләрне башкаруга, катлаулы

күнегүләрне эшләүгә дәртләндерә, максатка ирешүдә бернинди киртәләр алдында да тукталып калмау сыйфатын формалаштыра. Шулай итеп, дәрестә үткәрелгән уеннар, кулланылган уен элементлары дәресне җанлы һәм кызыклы итә, укучыларда ана теленә мәхәббәт тәрбияли һәм аның белән тирән кызыксыну уята.

Уен технологиясе укучыларның танып белү активлыгын үстерә, акыл үсешен активлаштыра, аларда яңа сыйфатлар булдыруга ярдәм итә. Уен вакытында фән белән кызыксыну көчәя, мөстәкыйльлек, ихтыяр көче, игътибарлылык арта, хәтер яхшыра, уйлау күнекмәләре камилләшә. Уен аша укытучы укыту һәм тәрбия бурычларын уңайлы хәл итеп кенә калмый, ә укучы белән аралашуны да җайга сала. Балалар коллективын берләштерүдә, туплауда, дусларча мөгамәлә урнаштыруда да уенның әһәмияте зур.

С. Х. Айдарова билгеләп үткәнчә, теләсә нинди телгә өйрәтүнең төп үзенчәлеге булып аның коммуникатив юнәлгәнлеге тора. [Айдарова, 1998: 36] Татар теле дәресләрендә дә, иң беренче чиратта, балаларга телне аралашу чарасы буларак кулланырга өйрәтелә. Телгә өйрәткәндә, авырлыклар автоматизмнар эшләнүдән башка сөйләшеп, әлеге телне белеп булмау белән бәйле. Шул рәвешле, телне өйрәнү билгеле бер күнекмәләр булдыруны да күз алдында тота. Моңа исә төрле дидактик уеннар куллану ярдәм итә ала.

Уеннар кайчан барлыкка килгән соң? Бу сорауга төгәл генә җавап бирүе читен. Шулай да борынгы чыганакларда бала уеннары турында кайбер мәгълүматлар очрый. Археологлар, мәсәлән, моннан күп гасырлар элек яшәгән кешеләрнең таштан, балчыктан ясалган уенчыкларын табалар. Күренекле фольклорчы Р. Ф. Ягъфәров уеннар турында төрки язма чыганакларда да мәгълүматлар булуын әйтә. Мәсәлән, М.Кашгариның XI гасырда язылган «Диване лөгатет-төрек» хезмәтендә «мөңүз-мөңүз» дигән балалар уенының тасвирламасы бирелә. Бу уен эчтәлеге белән «очты-очты» уенына якын тора дип яза Р. Ф. Ягъфәров.

Чит телне өйрәнгән вакытта, уен кызыксыну уятучы, дәртләндерүче фактор булып тора. Г. К. Селевко, максатчан юнәлеш буенча, дидактик (белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген киңәйтү, белем һәм күнекмәләрне гамәли эшчәнлектә куллану һ.б.), тәрбияви (мөстәкыйльлек тәрбияләү, билгеле бер юнәлешләр, дөньяга караш тәрбияләү һ.б.), үстерелешле (игътибар, хәтер, сөйләм, фикерләүне, уку эшчәнлеген үстерү һ.б.), социальләштерүче (аралашуга өйрәтү һ.б.) уеннарны аера. [Харисов, 2015: 211]

С. Х. Айдарова укытучы башлангыч сыйныфларда ирешергә тиешле максатлар дип, түбәндәгеләрне санап үтә: 1) укучыларны уку уеннары белән мавыгырга өйрәтү; 2) уенга мотивация булдыру һәм үстерү; 3) укучы беренче минуттан ук соңгы нәтиҗәгә игътибарын юнәлткән булырга тиеш; 4) укытучы баланың ирешкән нәиҗәләрен күрергә, аны канатландырырга тиеш. [Айдарова, 1998: 47]

Уку процессын интенсивлаштыруны активлаштыру максатында, уенны төшенчәләрне үзләштерү, теманы өйрәнү, яңа материалны аңлату-ныгыту, сөйләм эшчәнлегенең телдән төрләренә өйрәтү вакытында технология буларак файдаланырга була.

«Уен технологияләре» төшенчәсе үз эчендә педагогик процесста кулланыла торган бер төркем метод һәм алымнарны берләштерә.

Дәрестә уен куллануның төп максаты – укучыда чит телне өйрәнүгә кызыксындыру уяту. Башлангыч сыйныфларда уенны куллану бигрәк тә отышлы, чөнки укучылар әле балалар бакчасыннан гына килгән, уенга күнеккән була. Шул ук вакытта материалны уен формасында тәкъдим итү аны кабул итүне җиңеләйтә.

Уеннарның төп функцияләре түбәндәгеләр:

1) укучыларның уйлау һәм сөйләү эшчәнлеген активлаштыру,
2) аларның сүз байлыгын арттыру һәм фикерләү даирәсен киңәйтү,
3) аралашу культурасы тәрбияләү.

Кешелек тормышында, димәк, мәктәптә кулланганда да, уеннар тагын түбәндәге функцияләрне башкаралар:

1) Күңел ачу. Ул башлангыч сыйныф укучысына үзе өчен авыр тоелган уку мәшәкатьләреннән арынырга ярдәм итә. Дәреснең уртасында җиңел генә уен үткәреп алу киеренкелекне бетерергә булыша.

2) Коммуникатив функция. Уен вакытында балага аралашу психологик яктан җиңелрәк була. Гомумән, уеннар вакытында, бигрәк тә рольле уеннар кулланылганда, табигый шартларда аралашу барлыкка килә, бала уңайсызланмый, иркен ситуациягә куела.

3) Бала уен вакытында үзенең сәләтләрен ача һәм тормышка ашыра ала. Бу да уенның мөһим бер функциясе булып тора.

4) Уен процессында укучыларның төрле кыенлыклар белән көрәшү, үз-үзен җиңү сыйфатлары үстерелә.

5) Диагностик функция. Уйнаганда балалар турында бик күп информация алып була: аларның холык, характер сыйфатлары, сәләте, билгеле бер әйберләргә мөнәсәбәте, башкалар белән аралашу мөмкинлеге, белем дәрәҗәсе һ.б.

6) Коррекция функциясе. Уен балаларның белемен генә түгел, ә бәлки холык-фигылендәге кайбер сыйфатларны да үзгәртергә, төзәтергә мөмкинлек бирә.

7) Социальләштерү функциясе. Уен вакытында бала җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны үзләштерә, башкалар белән мөнәсәбәтләрен җайга сала.

Күренеп тора: уенның функцияләре гаять күп. Ул баланың белем дәрәҗәсен тикшерүдән тыш, аның үз-үзен тотышы нормаларын да формалаштыруга ярдәм итә. Моннан чыгып, уенның татар телен чит тел буларак укыту процессын оештыруда зур ярдәмче булуын күрәбез. Башлангыч сыйныфларда, гомумән, уен элементлары мөмкин кадәр күбрәк кертелергә тиеш.

Уен, бала эшчәнлегенең хәлиткеч сыйфаты буларак, аның активлыгы үсүгә ярдәм итә, иптәшлек, бер-берсенә карата ихтирам хисен үстерә. Уен баланың акыл даирәсе үсешенә ярдәм итә, уенда аларның күзаллаулары, кызыксынулары, тирә-юньдәге тормышка мөнәсәбәтләре күренә, дигән фикер әйтә Н. П. Аникеева. [Аникеева, 2007: 96]

Укытучылар, балалар тормышындагы төрле характердагы уеннарның аеруча әһәмиятле урын алып торуын, аның акыл эшчәнлеген камилләштерү белән бергә белем, тәрбия бирүен дә истә тотып, дәресләрдә уеннарны яратып һәм еш кулланалар. Бигрәк тә башлангыч сыйныфта уку-укыту процессында уеннар куллану яки уен элементларыннан файдалануның әһәмияте гаять зур. Чөнки уенны белем бирүнең барлык этапларында да кулланырга була. Аеруча татар милләтеннән булмаган балаларга татар телен өйрәтүнең башлангыч чорында уеннарны дәрестә һәм дәрестән тыш үткәрү уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Уен балаларда чит телгә кызыксыну уятырга булыша. Уен барышында балалар үзара ярдәмләшеп эшлиләр һәм аларда иптәшлек хисе тәрбияләнә. Шулай ук дәресләрдә уен элементларыннан файдалану аралашуга өйрәтүнең мөһим чарасы булып тора. Рус балаларын татар телендә сөйләшергә өйрәткәндә һәм сөйләм үстерүне күздә тотканда, беренчедән, сүзләрне еш кабатларга, икенчедән, һәр укучы дәрестә күбрәк сөйләргә тиеш. Бу очракта рольле уеннар ярдәмгә килә.

Рус балаларын татар теле белән кызыксындыруда, аларның сүзлек запасын баетуда, шул сүзләрне сөйләмдә кулланырга өйрәтүдә дә уеннарның әһәмияте гаять зур. Дәресләрдә уңышлы кулланылган уеннар укучыларны активлаштыра, аларның игътибарын туплый. Уеннар дәресләрне хисләр белән баета, балаларның иң яхшы сыйфатларын ачарга ярдәм итә. Үзләштерергә читен булган материал да, уен рәвешендә аңлатканда, кызыксыну уята. Укытучы һәр укучыны эшкә тарта, уйната, уйлата, өзлексез иҗат итүгә этәрә.

С. Х. Айдарова билгеләвенчә, татар теле дәресләрендә уеннар дәреснең аерылгысыз өлеше булырга тиеш, чөнки уен балаларны аеруча кызыксындыра. Ә кече сыйныф укучысының хәтере үзенә ошаган әйберне, күренешне бик тиз исендә калдырырга сәләтле. Дәрестә без дидактик уеннар белән эш итәбез. Ә алар методик максатлы булуы белән аерылып тора. Укытучы бу максатларны бик яхшы белә, әмма укучыларга бу турыда әйтергә кирәкми. Әгәр укучылар бу максатны белә икән, уен гадәти бер күнегүгә әйләнеп кала. [Айдарова, 2006: 163]

Күренекле методистлар, укытучылар татар телен чит тел буларак өйрәткәндә, уеннарның файдасын күреп, әһәмиятен сизеп, үзләренең хезмәтләрендә аларны аеруча киң яктырталар. Шундыйларның берсе – Ф.Ф.Харисов. Аның хезмәтләрендә татар теленә өйрәтү чарасы буларак уенның әһәмияте, төрләре, үткәрү методикасы бирелә. Ул иҗади активлыкны үстерүнең иң нәтиҗәле юлларыннан берсе, күзаллауны яхшырту чарасы булып, белем бирүнең коммуникатив юнәлешендә өйрәнелә торган предметка кызыксыну арттыру чарасы булып, төрле уеннар оештыру тора, ди.

Ф.Ф.Харисов дәрестәге уенның аны оештырганда исәпкә алынырга тиешле үзенчәлекләре булуын күрсәтә:

1. Уен дидактика күзлегеннән чыгып төзелергә, көч җитәрлек булырга, катнашучылар тарафыннан үтәлерлек булырга тиеш;

2. Чит телне өйрәнүгә омтылыш булдыру өчен, уен кызыклы да булырга тиеш;

3. Уен барышында дустанә мөнәсәбәт, үзара ярдәмләшү атмосферасы, танып белү шатлыгы һәм нәтиҗә куанычы булу мөһим. [Харисов, 2015: 212]

Рольле уеннар ярдәмендә укучыларны активлаштыру шартлары булып түбәндәгеләр санала:

1. Һәр дәреснең сюжетлылыгы, укучыларның мотивациясе.

2. Уку материалының махсус формада бирелүе (монолог, диалог, полилог).

3. Күрсәтмәлелектән файдалану, театральләштерү.

4. Танып белүнең коллектив формаларын куллану.

5. Гомуми процесста һәр балага индивидуаль якын килә алу.

6. Шатлык атмосферасы һәм киеренкелекнең булмавы.

Уеннар төрле һәм бик күп була. Аларның иң нәтиҗәлеләрен генә сайлап, дәресләрдә кулланырга кирәк. Уеннар белән бик мавыгырга да ярамый. Чөнки дәрес үзенең чиганнән чыгып китәргә мөмкин.

**Нәтиҗә** ясап әйткәндә, балалар тормышында уенның әһәмияте искиткеч зур. Уенны, аның һәм алымнарын балалар бик ярата һәм теләп кабул итә. Ул бала шәхесенә һәрьяклап йогынты ясый, аның акыл үсешен активлаштыра, укучыда хисләр эшчәнлеген көчәйтә, ихтыяр көче тәрбияли. Шул ук вакытта хәрәкәт гүзәллеген камилләштерергә, фантазиясен үстерергә, сөйләм телләрен баетырга, белем алу, тәрбия эшчәнлегенә кызыксыну уятырга, тирә-юнь һәм дөньяны, табигатьне танып белүгә омтылыш булдырырга ярдәм итә.

## 2.2. Фонетик уеннар

Рус телле укучылар татар телен чит тел буларак өйрәнәләр. Моның бик авыр һәм катлаулы процесс булуын укытучылар яхшы аңлыйлар. Һәр авазны, һәр сүзне балаларга дөрес әйтергә өйрәтү өчен татар теле дәресләрендә фонетик уеннар ярдәмгә килә.

**«Беренче авазны бел»** уены укучыларның фонематик ишетү сәләтен үстерергә, сүздән авазларны аерырга ярдәм итә. Укытучы әйткән сүзләрнең укучылар беренче авазны билгеләргә тиеш булалар. Бу уенны без күбрәк башлангыч сыйныфларда уйната алабыз. Мәсәлән, һәрбер, һичничек, һичнинди, һичкем һ.б. һ хәрефенә башланган алмашлыкларда [һ] авазын [х] авазы белән бутарга бик җиңел. Шулай ук әллә кем, әллә ничек, әллә кайчан

һ.б. ә хәрефенә башланган алмашлыкларны рус телендә сөйләшүче укучылар [э] авазы белән бутарга мөмкиннәр. Дөрес җавапларны күбрәк тапкан укучы җиңүче була.

**«Шагыйрьнең хатасын тап»** уены укучыларны авазларны аера һәм алмашлыкларны дөрес куллана белергә өйрәтә. Мәсәлән, Роберт Миңнуллинның «Мияу!» шигырендә алмашлыклар дөрес кулланмаган. Укучылар әсәрдәге җөмләләрнең эчтәлегенә туры килгән алмашлыкларны табарга тиеш булалар.

Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
Йомшак *минем* йоннарың,
Җылы *аның* туннарың.

**«Кем игътибарлырак?»** уены. Бу уенны 1 нче һәм 2 нче сыйныфларда кулланырга була. Балалар өчен бу уен дәрестә физкульт-минут кебек кулларны ял иттерергә ярдәм итәчәк. Укытучы сүз әйтә, укучылар, сүздә ничә иҗек булса, шул тапкыр кул чабалар*: ә-ни, Гөл-фи-я, Ка-зан , мин, у-рам, я-шим, өй, яң-гыр, те-ген-ди, өс-тәл-дә, я-ва, кыз, ма-лай, нәр-сә, әй-те-гез, син-нән, я-ра-мый, сал-кын,а-лар-ның, я-зам, әйт.* Әлбәттә, бу уенда без алмашлыкларны да кулланабыз. Шул рәвешле, укучылар алмашлыклар сүз төркемен ишетеп истә калдыралар.

Татар теленең фонетик системасын үзләштерү өчен **фонетик һәм лексик зарядка битләрен** кулланырга мөмкин. Мәсәлән, уртасында специфик татар [Ә] авазын белдерә торган хәреф язылган альбом бите. Бу хәреф белән янәшә исемнәрендә шундый аваз булган алмашлыклар язып ябыштырылган (нәрсә, әллә кем, һәммә, һәр, әллә нинди, ничә, тегеләй һ.б.). Берьюлы күп информация бирергә ярамый, чөнки балалар бик тиз арыйлар. Башта һәр биткә хәрефкә туры килә торган 5-6 сүз дә җитә. Һәр 2-3 дәрес саен сүзләрнең санын арттырырга була. Мондый «битләр» һәр специфик татар авазына ясалган булырга тиеш. Уку елы ахырына укучыларның лексик

запасы була. Бу уенны, әлбәттә, алмашлыклар белән генә түгел, башка сүз төркемнәре белән дә эшләргә кирәк.

Бу «битләр» һәр дәрес башында фонетик һәм лексик зарядка вакытында кулланылырга тиеш. «Битләрне» төзегәч, укытучы фонетик һәм лексик зарядканы болай үткәрә: специфик татар авазын белдерүче хәрефне күрсәтә һәм әйтә. Аннан соң сүзләрне дөрес итеп укып күрсәтә. Берничә дәрестән соң яхшы әзерлекле укучылар аваз һәм сүзләрне үзләре әйтә башлыйлар. Дәреснең бу этабында алар бернинди авырлыксыз укытучыны алмаштыра алалар. Ә тагын күпмедер вакыттан соң аларны уртача өлгерешле һәм авыр өлгерешле укучылар алмаштырачак, бу вакытта яхшы әзерлекле укучыларга дәреснең бу этабында инде авыррак биремнәр биреләчәк (мәсәлән, бу «бит» буенча җөмләләр уйла һәм яз).

Дөрес әйтүгә өйрәткәндә чираттагы уеннар файдалы:

**«Нинди аваз әйтелә?»** (уен-табышмак): укытучы бер үк төрле аваз ишетелә торган алмашлыклардан торган сүзләр чылбыры әйтә (мин, син, һичнинди, нинди, нишли, ничә, ничек, ниндидер, минеке), беренче булып ([и] авазын) җавап тапкан бала үзенең табышмагын әйтү хокукын ала.

Әлеге уенда дифференциаль якын килүне кулланганда яхшы өлгерүче (1 нче вариант), уртача өлгерүче (2 нче вариант) һәм авырдан өлгерүчеләрне (3 нче вариант) вариантлап утырту сакланырга мөмкин. Башта чагыштырмача авыррак сүзләр чылбыры 1 нче вариантка тәкъдим ителә (чылбырга укучыларга таныш лексика гына түгел, ә таныш булмаганы да кертелә). Шуннан соң 2 нче вариантка бик үк авыр булмаган чылбыр тәкъдим ителә (сүзләр чылбырына берничә таныш булмаган сүз кертелә). 3 нче вариантка темалар буенча үтелгән яхшы белгән сүзләр тәкъдим ителә.

**«Сүзне әйт»** уены. Алып баручы (яхшы өлгерүче укучы) уенда катнашучыларга чираттан аваз әйтеп туп ыргыта (мәсәлән, [к]), катнашучылар әлеге аваз булган алмашлыкны әйтеп ([кэм]), тупны кире кайтаралар.

**«Сүз уйлау»** уенында татар теленә генә авазларны өйрәнгәндә уйнала. Мәсәлән, [ә] авазына башланган яки шушы аваз булган алмашлыкларны кем күбрәк әйтер? Мәсәлән: һәр, үземдә, һәммә, ничә, ничәнче һ.б. Бу уенны барлык сүз төркемнәрен дә кабатлаганда яки искә төшергәндә уйнарга була.

**«Детектив»** уены. Бу уен вакытында тактада яки балаларга өләшелгән индивидуаль карточкаларда кайбер хәрефләре төшеп калдырылган алмашлыклар языла. Укучылар шул хәрефләрне эзләп табарга тиеш булалар. Мәсәлән: б.л.р, һ.м.., н...ә, к.й..н, н.ш..д., ш..а., һ.р..м һ.б. Авыррак үзләштерүче укучыларга җәя эчендә сүзләрнең русчага тәрҗемәсен бирергә мөмкин.

**«Әйтеп бетер»** уены аерым теманы өйрәнгәндә уйнала. Укытучы алмашлыкның беренче иҗеген әйтә, ә укучы аны әйтеп бетерергә тиеш. Мәсәлән, «Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнүе» темасы буенча: ми... , си... , а... , без... ; «Сорау алмашлыклары» темасы буенча: ни..., кай..., нин..., ниш... һ.б.

Сузык аваз хәрефләрен куеп алмашлыклар ясауны да укучыларга аерым бер уен буларак тәкъдим итәргә була: м...н, с...н, ...л, б...з, с...з һ.б.

Иҗекләрне алмашлыклар килеп чыгарлык итеп тоташтырыгыз.

| | |
|---|---|
| ми | дә |
| үзен | ничек |
| һәр | нем |
| әллә | бер |

**«Ничә аваз?»** фонетик уенын физминутка кебек дәреснең 2-3 минуты эчендә үткәрергә мөмкин. Укытучы төрле сүз төркеменә караган сүзләр әйтә, ә укучылар шул сүздәге аваз санын билгеләргә тиеш булалар. Мәсәлән, *чаңгы* сүзендә 5 аваз, *һичкем* сүзендә 6 аваз, *ямьле* сүзендә – 6, *һәммә* алмашлыгында 4 аваз ишетелә.

**«Сүзне уйлап тап»** уены укучыларны сүзне фонема ягыннан тикшерергә, аларның сүзлек байлыгын арттырырга ярдәм итә. Укытучы

тактада теләсә кайсы алмашлыкның график схемасын күрсәтә, ә укучылар шуңа туры китереп алмашлыклар әйтергә тиеш булалар. Күбрәк сүз тапкан укучы уенның җиңүчесе була. Мәсәлән, түбәндәге график схема бирелә:

| | | |
|---|---|---|

Укучылар бу схемага туры китереп мин, син, без, сез, кем, үзе, шул, аңа, бар, һәр, кая, ник һ.б. алмашлыкларны әйтә алалар. Әгәр дә мондый схема бирелсә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|

укучылар һичкем, беркем, миннән, аларга, шундый, мондый, минеке, синеке, кайдан, кайчан, аларда, безнең, сезнең, бездән, сездән, кайдан, кемдер һ.б. алмашлыкларын искә төшерә алалар. Бу уен алмашлыкларны гына түгел, хәтта аларның килеш белән төрләнешен дә искә төшереп кабатларга ярдәм итә.

**«Биш сүз»** уены укучыларга сүзнең иҗек структурасын анализларга, алмашлыкларның килеш белән төрләнешен искә төшерергә, сүзлек запасын баетырга ярдәм итәчәк. Мәсәлән:

1 нче вариант. Иҗекләргә туры китереп бш сүз тап:

беренчедә – бер иҗек (мин, син, ул, үз, кем, ник һ.б.),

икенчедә – ике иҗек (алар, безгә, һичкем, болай, теге, нинди һ.б.),

өченчедә – өч иҗек (аларның, минеке, кайчандыр, бернинди һ.б.),

дүртенчедә – дүрт иҗек (кайсысыдыр, ничәнчедер, кайсыгызның һ.б.),

бишенчедә – биш иҗек (әллә нишләде, һәммәбезнеке, андыйракларның һ.б.).

Биш сүзне тапкач кына укучы җавап бирә ала.

2 нче вариант. Бер сызыкча бер иҗек булып бара. Укучыларга шул сызыкчаларга алмашлыкларны язып, баскычны тутырасылары була. Мәсәлән:

---

- мин

- -- син, те-ге

\- -- --- ул, а-лар, ми-не-ке

\- -- --- ---- шул, шу-лай, шу-ны-сы, һәр-нәр-сә-нең

\- -- --- ---- ----- бу, ү-зе, а-лар-ның, нәр-сә-ләр-дер, әл-лә ниш-лә-гән.

Уен **«Авазны тап»** дип атала. Укытучы төрле сүзләр әйтә, шул сүзләрдә билгеләнгән аваз булса, укучылар кул чабалар. Бу уенны физкультминут буларак уйнатырга да бик җиңел. Мәсәлән:

Укытучы: Мин әйткән сүзләрдә [һ] авазы булса, кул чабыгыз. Агач.

Укучылар кул чапмыйлар.

Укытучы: Хәреф.

Укучылар бу вакытта кул чабарга мөмкиннәр, чөнки кайберләре [х] һәм [һ] авазларын аерып бетермиләр. Мондый очракта укытучы бу авазларны тактага язып, мисаллар китереп аңлатып китә.

Укытучы: һава.

Укучылар кул чабалар.

Укытучы: хәтта.

Укучылар кул чапмыйлар.

Укытучы: һәммә.

Укучылар кул чабалар.

Бу уенда укытучы мисалга төрле сүз төркеменнән сүзләр китерергә мөмкин. Мәсәлән, һ хәрефе язылган алмашлыклар бик күп (һичнинди, һәркайсы, һәр, һәркем һ.б.). Алар бу алмашлыкларны ишетеп истә калдыралар һәм сүздәге авазларны аерырга да өйрәнәләр.

Укучыларга алмашлыклар язылган карточкалар таратыла. Мисал өчен түбәндәге сүзләрне китерик:

| |
|---|
| *Мин, алар, бернәрсә, әллә кем, һичнинди, ник, кайсы, ул, шулай, андый, аныкы, аларның, һәр, кайчанрак, әллә нишләгән, үзеңдә, синең, әллә ничек, һичкайчан, аларныкы, шуның.* |

Бирем төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, бирелгән алмашлыклар арасыннан [ә] авазы булганнарын күчереп языгыз. Бу очракта укучы шушы алмашлыклар арасыннан *бернәрсә, әллә кем, һәр, әллә нишләгән, үзеңдә, әллә ничек* сүзләрен язып алалар. Әгәр дә бирем мондый булса: бирелгән сүзләр арасыннан ике иҗеклеләрне күчереп языгыз, укучылар *алар, кайсы, шулай, андый, синең, шуның* алмашлыкларын күчереп язачаклар. Шулай ук биремне болай биреп була: килешләр белән төрләнгән алмашлыкларны языгыз. Җавабы: *аларның, үзеңдә, синең, шуның*. Яисә күрсәтү алмашлыкларын табыгыз дигән биремгә укучылар *шулай, андый, шуның* алмашлыкларын билгеләячәкләр. Биремне төрлечә бирергә мөмкин. Укучылар арасында ярыш башланып, начар укыган укучылар да кызыксынып эшләргә мөмкиннәр.

**«Аут»** уены хәреф һәм авазларны туры китерергә, фонематик ишетү һәм хәтерне үстерергә, орфографик күнегүләрне формалаштырырга ярдәм итә. Тартмада карталар ята, һәр картада бер аваз язылган. Беренче укучы тартмадан бер карта ала һәм авазны әйтә. Укучылар бергә «Бер! Ике! Өч!» дип саныйлар, һәм шуннан соң беренче укучы шул аваз булган берәр алмашлык әйтергә тиеш була. Әгәр дә укучы дөрес әйтмәсә яисә җитешми калса, ул уеннан чыга («Аут!»). Тартманы икенче уенчыга бирәләр. Иң күп алмашлык әйткән уенчы җиңүче дип санала.

Парларда һәм кечкенә төркемнәрдә уйнар өчен укучыларга **«Дуэль»** уенын тәкъдим итәргә була. Уенның кагыйдәләре мондый: һәр уйнаучы 10 карта ала. һәр картада төшеп калган хәрефләр белән алмашлык язылган була. Уйнаучылар бер-берсенә капма-каршы утыралар. Кулдагы карталар башка укучыларга күренергә тиеш түгел. «Бер! Ике! Өч!» командасыннан соң укучылар берешәр картаны алып, көндәшләренә күрсәтергә тиеш булалар, һәм алар шул сүзне белеп әйтәләр. Алмашлыкны әйтә алса, уйнаучы картаны үзенә ала. Кемнең кулында иң күп карта – шул җиңүче.

**Тизәйткечләр** тиз арада баланың "телен шомартырга" ярдәм итә. Дикциясен яхшыртырга теләгән әти-әниләргә дә мондый күнекмәләр файдага

гына булачак. Тизәйткечләр кызык итеп яңгырый, шуңа күрә татар теле дәресләрендә укучыларның кәефен дә күтәрә. Алмашлыклар булган тизәйткечләр телне генә шомартып калмый, ә сүз төркемен дә искә төшерергә ярдәм итәчәк.

– *Андый* төймә Ләбибәдә дә бар, Нәфидәдә дә бар.

– Талга кунар бер тартар,

*Ул* тартарны тал тартыр,

Тартар басып талны тартыр,

Тал тартыр, тартар калкыр,

Тартар калкыр, тал тартыр.

– *Синең* мускул мускулмыни, мускул түгел *ул* – мыскыл. *Минә* Мостафа мускулы мускул дисәң дә мускул.

– *Сезнең* кызлар *безнең* кызларга киндер тукмаклашмакчылар иде. Тукмаклашырлар микән, тукмаклашмаслар микән? Тукмаклашсалар, тукмакларын алып килсеннәр, тукмаклашмасалар, тукмакларын биреп торсыннар.

– Карамалының кара малаена чана карамаларга биргән идем, карамалады микән *шул* кара малай, карамаламады микән ул кара малай. Карамаласа карап кайт, карамаламаса карганганына, карганмаганына карамыйча алып кайт. *Ул* карамаламаса, *үзем* карамалармын.

– *Мин* әйтә алам,

*Кем* әйтә ала,

Әхмәт, *син* әйтеп кара.

– *Без*, Бәдәр белән бәрәңгегә барганда,

Бәдәрнең бидрәсенә балчык белән бәрә-бәрә бардык.

– *Мин* агамның дагаланган

Атын дагалаганмын.

– Үгезегез *үзегезнеке*,

Мөгезе үгезегезнеке.

– Сыерчык, сыерчык,

*Нинди* матур сызгырчык!

– Быж-быж килә бер быжан,

Шөпшә түгел *ул* – быжан.

Кигәвен дә түгел *ул*,

Ә *аларга* охшаган.

Быжан-быжан, быж-быжык,

*Син* мине чага күрмә.

Тавышың ай-яй яман,

Өебезгә дә кермә.

**Нәтиҗә** ясап әйткәндә, алмашлык сүз төркемен өйрәнкәндә, укытучылар татар теле дәресләрендә түбәндәге фонетик уеннарны куллана алалар: «Дуэль», «Аут», «Авазны тап», «Биш сүз», «Сүзне уйлап тап», «Ничә аваз?», «Әйтеп бетер», «Детектив», «Сүз уйлау», «Сүзне әйт», «Нинди аваз әйтелә?», фонетик һәм лексик зарядка битләре, «Кем игътибарлырак?», «Шагыйрьнең хатасын тап», «Беренче авазны бел», тизәйткечләрдән алмашлыкларны табу һ.б. Фонетик уеннар аша укучылар татар авазларын дөрес әйтергә, хәрефләрне аерырга, алмашлыкларны дөрес язарга өйрәнәләр.

## 2.2. Лексик уеннар

Татар теле дәресләрендә укучыларның лексик запасын баету, алмашлыкларны өйрәтү максаты нигезендә түбәндәге уеннарны тәкъдим итәм.

**«Кар өеме»** кебек уен бик тә нәтиҗәле була. Укучылар түгәрәк өстәл принцибы буенча утыралар, ә өстәл уртасында өйрәнелүче сүзләр һәм әйтелмәләр язылган карточкалар куелган. Бер укучы карточка ала, аны бөтенесенә күрсәтә һәм әлеге сүзне яки әйтелмәне җөмләдә куллана. Чираттагы укучы икенче карточканы ала һәм алдагысы белән логик яктан бәйләнгән тагын бер җөмлә уйлап әйтә. Укучыларга уен бер төрле булып

тоелмасын өчен карточкалар күгәрчен, чәчәк һәм башка формаларда төзеләләр. Мәсәлән, укучылар коллектив хикәя төзиләр. Һәр фраза билгеле бер сандагы сүзләрдән тора: беренчесе бердән, икенчесе икедән һ.б. Соңгы фразаны төзеп чыгучы җиңеп чыга. Алып баручы (яхшы өлгерүче укучы) бөтен җөмләләрне тактага язып бара.

**«Киресен әйтешле»** уены. Ак-кара, җиңел- ..., кечкенә-..., сары-..., җан- ... һ.б. Бу уенда без антоним парлары буларак алмашлыкны да китерә алабыз. Мәсәлән, укытучы «мин» дисә, укучылар «син» дип җавап бирәчәкләр. Шулай ук болай – тегеләй, без – сез, шул – теге һ.б. парларын мисал итеп китерергә мөмкин.

**«Йөзек салыш»** уены. Уен җитәкчесе йөзек ала да, сүзләрнең берсен әйтә, ә уенчы шул сүзне дөрес алмашлык белән алыштырырга тиеш һәм йөзекне икенче укучыга башка сүз әйтеп бирә. Мәсәлән, Айдар – ул, балалар – алар, тәмле – нинди һ.б. Бу уен алмашлыкларны кабатлаганда ярдәм итәр.

**«Кызык телефон»** уены. Тактада зур телефон рәсеме ясала. Дискта саннар урынына хәрефләр языла. Укучылар билгеле вакыт аралыгында күбрәк итеп (специфик татар авазларын кулланып) сүзләр (төрле сүз төркеменә караган) җыярга һәм аларны әйтергә тиешләр.

**«Сүзләр тап»** уены. Бик кызыклы һәм мавыктыргыч уен. Укучыларга озын сүз бирелә. Мәсәлән, «Бу сүздә кем күбрәк сүзләр таба?» дип сорау бирелә. Укучылар шушы озын сүздәге хәрефләрне кулланып, сүзләр төзергә тиеш булалар. Балалар ярыша-ярыша сүзләр эзли башлыйлар. Күргәнебезчә, җаваплар арасында алмашлыклар да булырга мөмкин.

**«Эстафета»** уенында укучылар ике рәткә басалар. Укытучы «башладык» диюгә, беренче укучы, тәкъдим ителгән темага караган сүз әйтеп, таякны иптәшенә тапшыра, анысы – икенчесенә. Эстафета таягы финишка алданрак барып җиткән төркем җиңүче була. Бу уенда укучылар белән алмашлыкларны кабатларга мөмкин. Мәсәлән, беренче төркем билгеләү алмашлыкларын (һәркем, барлык, барча һ.б.), ә икенче төркем

билгесезлек алмашлыкларын (кемдер, әллә ничек, һичнәрсә һ.б.) әйтергә мөмкин. Уен барышында кайсы укучыларның теманы аңлый алмаганы күренә. Бу уенны санарга өйрәткәндә дә уйнарга мөмкин. Бердән унга һәм киресенчә – уннан бергә кадәр саный-саный, балалар таякны бер-берсенә тапшыралар.

**«Югалган алмашлыкларны тап»** уены. Мәсәлән, Р.Миңнуллинның «Югалган хәрефләр» исемле шигыре буенча:

Мич почмагын сөзә-сөзә,
Авыртуга түзә-түзә,
Ак маңгаен бәрә-бәрә,
Үсә ...(*безнең*) бөдрә бәрән .
Табыныгыз ай-яй-яй бай,
Катык та сөт, каймак та май —
Бөтенесе кунак сые!
Рәхмәт инде ... (*сиңа)*, сыер .
Әллә юри котыртмакчы,
Әллә инде куркытмакчы,
Булмаса да бер дә көче,
Өргән була ... (*безгә*) көчек
Оя дер-дер килә,
Әллә инде дер-дер көлә?!
Ахры чак-чак куркып куя
... (*шул*) ояда батыр куян
... (*бу*) – бүре, дип уйламагыз,
Ә ... (*шулай*) да уйнамагыз,
Булмасам да ...(*үзем*) бүре,
... (*Минем*) башта бүре бүрек.

**«Кем җитез?»** уены. Алмашлыклар темасы буенча сүзле карточкалар әзерләнә (мәсәлән, «Исем алмашлыклары», «Сыйфат алмашлыклары»).

Бутыйлар. Такта янына ике укучы чакырыла (аларның белемнәре бер дәрәҗәдә булырга тиеш). Алар 1 минут эчендә үзләренең темаларына караган сүзләрне баганаларга җыялар. Аннан чират буенча үзләренең сүзләрен укыйлар. Калганнар игътибар белән тыңлыйлар һәм хаталарны төзәтәләр. Уенда катнашучылар сүзләр җыйганда башка укучыларга сүзләр (авырдан өлгерүчеләргә), сүзтезмәләр (уртача өлгерүчеләргә) һәм җөмләләр (яхшы өлгерүчеләргә) язарга бирергә була.

Әлеге уенны начар өлгерүчеләр белән, аларга темалар буенча әзрәк сүзләр биреп, башлау уңышлы. Уртача һәм яхшы өлгерүчеләргә һәрберсенә 3-6 сүздән күбрәк бирергә кирәк.

**«Исеңдә калдыр»** уены ишетеп истә калдыруга һәм игътибарлылыкка юнәлгән. Иң башта укытучы уен өчен аерым бер төркем лексиканы сайлый. Мәсәлән, «сорау алмашлыклары» булсын. Беренче сүзне укытучы үзе әйтә: кем алмашлыгы. Беренче укучы шушы сүзне кабатлый һәм соңыннан үзенекен әйтә. Мәсәлән: кем, нәрсә. Икенче укучы шушы ике сүзне кабатлый һәм үзенекен дә әйтә. Кем сүзләрне онытa яки урыннары белән алмаштыра, шул укучы уеннан чыга. Бер хата да ясамаган укучы җиңүче була.

**«Кем нәрсә турында уйлады?»** уенында укытучы бер алмашлык әйтә, ә укучы шул алмашлыкка туры килгән сүзне әйтергә тиеш. Мәсәлән, укытучы «мин» дип әйтсә, укучылар «язам, укыйм, эшлим, сикерәм» һәм башка бик күп фигыльләрне әйтергә мөмкиннәр. Бу мисал аша укучылар хикәя фигыльнең I зат берлек сандагы кушымчаны искә төшерәләр. Укытучы «синең» дип әйтсә, укучылар «дусың, күлмәгең, әниең, китабың, телефоның» дип әйтергә мөмкиннәр. Без монда балалар белән тартым кушымчаларын искә төшерәбез. Бу уен аша укучылар кайсы алмашлыкның нинди сүзләр янәшәсендә килүен күзаллыйлар, җөмләләр, сүзтезмәләр төзергә өйрәнәләр.

**«Чәчәк бәйләмнәре»** уенында укытучы тактада берничә ваза әзерли. Һәр вазаның исеме була. Мәсәлән, «зат алмашлыклары», «күрсәтү алмашлыклары», «билгеләү алмашлыклары», «сорау алмашлыклары»,

«юклык алмашлыклары», «билгесезлек алмашлыклары» исемле вазалар. Аларның берничәсен генә дә алырга мөмкин. Һәр укучыда чәчәкләр һәм ул чәчәкләрдә төрле алмашлыклар язылган. Һәр укучы үзенең чәчәген туры килгән вазага салырга тиеш. Азактан тикшереп нәтиҗә ясала. Бу уен алмашлыкларны кабатларга һәм истә калдырырга ярдәм итә.

**«Дәфтәрләрне җыю»** уенында укучылар алдында дәфтәрләр формасында сүзләр (төрле алмашлыклар) язылган карточкалар ята. Ә тактада берничә портфель рәсеме, һәр портфельнең исеме бар. Мәсәлән, «исем алмашлыклары», «сыйфат алмашлыклары», «рәвеш алмашлыклары», «сан алмашлыклары», «фигыль алмашлыклары». Һәр укучы үзенең дәфтәр формасында ясалган карточкаларны туры килгән сумкага салырга тиеш. Мәсәлән, нишли дип язылган дәфтәрне укучы «фигыль алмашлыклары» портфеленә салырга тиеш, ә «ничәнче» дәфтәрен – «сан алмашлыклары»на. Бу портфельләрне укытучы башка төрле дә исемләргә мөмкин. Мәсәлән, алмашлыкларның мәгънә төркемчәләреннән чыгып эшләргә була.

**«Сүзләр төркемнәре»** уены. Бу уенда укытучы бер төркем сүзләрне әйтә, ә укучылар шушы төркем сүзләрне бер сүз белән алмаштырырга тиеш булалар. Укытучы «ул, бу, шул, теге, алай, болай» дип әйтсә, укучылар «күрсәтү алмашлыклары» диләр. Укытучы әйткән «һичкем, беркем, һичнинди, берничек» сүзләрен укучылар «юклык алмашлыклары» сүзе белән алмаштыралар. Ягъни дәреснең 2-3 минуты эчендә алмашлыкларны тиз генә искә төшереп, кабатлар үтәргә мөмкин.

**«Уңыш җыю»** уены өчен укытучыга алмалар һәм кәрзиннәр кирәк була. Һәр алма рәсеме ясалган карточкаларда төрле алмашлыклар языла. Мәсәлән: һәрбер, бернәрсә, нинди, әллә кем һ.б. Ә кәрзиннәргә төрле алмашлык төркемнәре язылган була: зат алмашлыклары, юклык алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары һ.б. Ничә алмашлык төркемен алабыз, шулкадәр сыйныфны төркемнәргә бүләргә кирәк булачак. Алга таба һәр төркемгә бер кәрзин бирелә. Укучылар үзләренең кәрзиннәренә туры

килгән алмаларны җыярга тиеш булалар. Бу уенны укытучы авырайтып бирә ала: төркемнәргә алмашлыклар төшеп калган текст һәм язылмаган алмалар бирелә. Һәр команда тексттагы алмашлыкларны билгеләп, алмаларны үзләре исемләргә тиеш булалар.

Алдагы уенның исеме – **«сүзне тап».** Укучыларга урыннары белән алмашкан хәрефләр язылган карточкалар таратыла. Алар шушы хәрефләрдән алмашлыклар уйларга тиеш булалар. Кем беренче булып барлык алмашлыкларны да дөрес яза – шул җиңүче була.

| | | |
|---|---|---|
| йалшу - | ерһбәр - | редекм- |
| тенөб - | гидетне - | әгзеб - |
| әмһәм - | енүзә - | әнннис - |
| меним - | кеичн - | әледшин - |
| ңиас - | кенеемк - | ларага - |
| әрсән - | чиһреб - | чайакн - |

**«Артык вагон»** уены алмашлыкның төркемчәләрен кабатлап истә калдырырга ярдәм итә. Уен өчен укытучыга дүрт вагоннан торган, сүзләр язылган поезд рәсемнәре кирәк булачак.

Укытучы: Хәзер, укучылар, без сезнең белән уйнап алабыз. Станциягә 3 поезд килгән. Һәр поезд 4 вагоннан тора. Вагоннарны бер-берсенә ялгаганда, поездга туры килмәгән артык вагонны кушып, хата ясаганнар. Укучылар, сез шушы артык вагонны табарга тиеш буласыз. Сезгә ярдәм итәр өчен, һәр вагонда сүзләр язылган була. Артык сүз калган сүзләрдән аерылып торачак. Һәр рәткә бер поезд туры килә. Җавап бирер алдыннан, үзегезнең рәттәге сыйныфташларыгыз белән яхшылап уйлагыз һәм бер кешене җавап бирер өчен сайлагыз.

1 нче поезд. Шундый, тегеләй, ул, әллә кем.

Укытучы: Кайсы вагон артык?

Укучы: 4нче вагон артык, чөнки бу алмашлык – билгесезлек алмашлыгы, ә калганнары күрсәтү алмашлыкларына керәләр.

2 нче поезд. Кайчан, нишли, һәркем, ничек.

Укытучы: Кайсы вагон артык?

Укучы: 3 нче вагон артык, чөнки бу – билгеләү алмашлыгы. Ә калганнары – сорау алмашлыклары.

3 нче поезд. Минем, миңа, миннән, минеке.

Укытучы: Кайсы вагон артык?

Укучы: 4 нче вагон, чөнки минеке алмашлыгы тартым алмашлыкларына карый. Ә калганнар мин алмашлыгының килеш белән төрләнгән формалары гына.

Татар теле дәресендә бу уен укучыларның сүз байлыгын, хәтерен һәм игътибарын үстерергә ярдәм итә. Алар бер хәрефкә башланган алмашлыкларны искә төшереп язарга тиеш булалар. Мәсәлән, һ хәрефенә башланган алмашлыклар: *һәрбер, һичкем, һичнинди, һичничек, һәммә, һәрнәрсә, һәркайсы, һәр* һ.б. Ш хәрефенә башланган алмашлыкларны да кабатларга була: *шул, шундый, шулай, шушы, шунысы* һ.б.

Алдагы уен укучыларның хәтерен, дөрес һәм хатасыз язуын, коммуникатив күнегүләрен ныгытырга ярдәм итә. Укытучы бер лексик тема бирә, ә укучылар шул темага караган сүзләр язарга тиеш булалар. Алмашлыкның төркемчәләрен кабатлау максатыннан, укытучы, мәсәлән, күрсәтү алмашлыкларын бирә ала. Балалар үзләре белгән барлык алмашлыкларны дәфтәрләренә язарга тиеш булалар: ул, бу, мондый, тегенди, шулай, алай, болай һ.б.

**«Кем иң бай?»** уенын укучылар әз булган сыйныфта үткәрергә бик җайлы. Алар түгәрәк буенча утыралар, ә өстәлнең уртасында алмашлыклар язылган карточкалар. Укытучы зат алмашлыклары дип әйткәч, укучылар шул сүзләр арасыннан зат алмашлыкларын табарга тиеш булалар. Бу уен кыска вакыт аралыгында уйнатыла. Һәр укучы үзенең карточкаларындагы алмашлыкларны укыгач, аның дөрес яки хата булуы билгеләнелә. Кем күбрәк дөрес җавап тапкан – шул укучы «иң бай», җиңүче була.

**«Кәрзинне тутыр»** уенында тактада ике кәрзин ясалган була. Бер кәрзиннең исеме – билгеләү алмашлыклары, икенче кәрзиннең исеме – билгесезлек алмашлыклары. Сыйныф ике төркемгә бүленә. Кайсы төркем кәрзинне беренче тутырачак – шул җиңүче була. кәрзиннең рәсемнәре зур итеп ясалганга күрә, укучылар алмашлыкларны кәрзиннең эченә язачаклар. Бу уен алмашлыкларны дөрес язарга һәм истә калдырырга ярдәм итә.

**«Сүз киресенчә»** уенында укытучы төрле алмашлыклар әйтә, ә укучылар шушы алмашлыкларны киресенчә язарга тиеш булалар. Мәсәлән, һәммә сүзен укучылар дәфтәрләренә «әммәһ» дип язып куялар. Ә һичничек алмашлыгын «кечинчиһ» дип язалар. Бу сүзләрне укыгач, укучыларның кәефләре күтәреләчәк. Чөнки киресенчә язылган алашлыклардан көләсе килә башлый. Бу уенны шулай ук икенче төрле уйнарга мөмкин. Мәсәлән, укытучы алмашлыкны киресенчә әйтә, ә укучылар дөрес әйтелешен язарга тиеш булалар. Мәсәлән, укытучы «редәсрән» дип әйтсә, укучылар дәфтәрләренә нәрсәдер билгесезлек алмашлыгын язып куячаклар.

«Алмашлык» темасын узганда актуальләштерү этабында, **«Тылсымчы», «Кояш», «Кайсы артык»** уеннарын кулланам. Укучылар конвертларда, яки кояш нурларында язылган алмашлыкларны килешләр белән төрләндерәләр. Бу уеннар гадәти дәреслектәге күнегүләрдән аермалы буларак укучыларда кызыксыну хисе уята**.** Укучылар дәресне көтеп алалар, уенны уйнар өчен теманы өйдә яхшырак үзләштерәләр. Башлангыч сыйныф укучылары мөстәкыйль эш яки тест сүзләреннән куркалар. Укучыларга «хәзер бер уен уйнап алабыз» дигәч, аларның кәефләре күтәрелә, һәм биремне бик уңышлы үтиләр. Шуңа мин уен алымын укучыларның алган белемнәрен тикшерү, уңай психилогик халәт тудыру өчен дә кулланам.

**«Бу нинди сүз»** уенында алмашлыкның беренче һәм соңгы хәрефләре билгеле. Алар арасында язылырга тиешле хәрефләр санынча сызыклар куела. Укучылар схемага туры килгән сүзләрне уйлап әйтәләр. Мәсәлән, һ----м

(һичкем), н---к (ничек), к---ы (кайсы), к----н (кайчан), н---и (нинди), ш---й (шулай), б---й (болай), н---ә (нәрсә) һ.б.

**«Сүзне исеңдә калдыр»** уены сүзлек тупларга, хәтерне үстерергә ярдәм итә. Алып баручы 5-6 алмашлык әйтә, уйнаучылар әйткән тәртиптә кабатларга тиеш. Тукталу яки сүзне төшереп калдыру оттыру булып санала. Кем беренче булып хатасыз кабатлый – шул уенның җиңүчесе була.

**Кроссвордлар** укучыларда һәрвакыт кызыксындыру уята. Алар аны үзләре төзергә дә, чишәргә дә яраталар. Алмашлык сүз төркемен үтеп бетергәч, шундый җайлы гына кроссвордлар чишеп була.

**А)**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | **М** | **И** | **Н** | |
| | | | | **Һ** | **Ә** | **Р** | | |
| | | | | | **К** | **Е** | **М** | |
| | | | | | **Т** | **Е** | **Г** | **Е** |
| | | | | **Н** | **Ә** | **Р** | **С** | **Ә** |
| **Н** | **И** | **Ш** | **Л** | **Ә** | **П** | | | |

1. Зат алмашлыгы.
2. Билгеләү алмашлыгы.
3. Сорау алмашлыгы.
4. Күрсәтү алмашлыгы.
5. Сорау алмашлыгы.
6. Сорау алмашлыгы (грамматик төркемчә буенча фигыльгә карый).

**Б)**

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | **Һ** | **Ә** | **Р** | **Б** | **Е** | **Р** |
| **Т** | **Е** | **Г** | **Е** | **Л** | **Ә** | **Й** | | | | |
| | | **А** | **Л** | **А** | **Й** | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Н | И | К | | | | | | |
| | | Һ | Ә | Р | К | А | Й | С | Ы |
| Н | И | Ш | Л | И | | | | | |

1. Билгеләү алмашлыгы.
2. Күрсәтү алмашлыгы.
3. Күрсәтү алмашлыгы.
4. Сорау алмашлыгы.
5. Билгеләү алмашлыгы.
6. Сорау алмашлыгы.

**В)**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | А | Л | А | Р | |
| | | | У | Л | | | | |
| | | | | М | И | Н | Е | М |
| | | | К | А | Й | Д | А | |
| | | | | Ш | У | Л | | |
| | Б | А | Р | Л | Ы | К | | |
| М | О | Н | Д | Ы | Й | | | |
| Н | И | Ч | Е | К | | | | |

1. Зат алмашлыгы.
2. Зат алмашлыгы.
3. Иялек килешендәге зат алмашлыгы.
4. Сорау алмашлыгы.
5. Күрсәтү алмашлыгы.
6. Билгеләү алмашлыгы.
7. Күрсәтү алмашлыгы.
8. Сорау алмашлыгы.

**«Белмәмешнең шаяруы»** уенында җөмләләрдәге сүзләргә сораулар куярга кирәк була. Укытучы: «Мин тактага җөмләләр язган идем. Ләкин тәнәфес вакытында Белмәмеш шаярткан: кайбер сүзләрнең сорауларын сөрткән һәм үзе качкан. Укучылар, миңа сорауларны язырга ярдәм итегез әле». Мәсәлән, түбәндәге текстгагы сүзләргә укучылар сорау алмашлыкларын язып чыгалар:

*Кыш* (нәрсә?) җитте. Балалар *урамга* (кая?) чыктылар. *Алар* (кемнәр?) Кар бабай ясадылар. Кар бабай *зур* (нинди?) һәм *матур* (нинди?) булды. Бөтен җир *кар* (нәрсә?) белән капланган. Кар бабай янына кунакка *куян* (нәрсә?) килде. Алар әйлән-бәйлән уйнадылар. *Кышын* (кайчан?) күңелле.

**«Җиде таҗлы чәчәк»** уены (сүзлек белән эш). Укытучы: «Күрәсезме, балалар, бүген безнең дәрестә нинди матур чәчәк бар. Әйдәгез әле саныйбыз, ничә таҗы бар аның?». Һәр таҗ артында әлегә өйрәнелмәгән русча алмашлыклар бирелә. Шуларны укучылар үзләре сүзлектән эзләп табып, тактага язарга тиеш булалар. Шулай итеп яңа темага бик матур, җиңел кереп китәргә мөмкин.

**«Адым саен»** уенында тактага укучы чакырыла. Адым белән алмашлыкларны санарга тиеш. Ялгышмыйча, тоткарлыксыз санап атлый алган укучы җиңүче була.

**«Иң җитез»** уенында укучылар карточкалар таратыла. Карточканың беренче баганасында татарча алмашлыклар язылган була. Ә икенче һәм өченче баганаларында алмашлыкларның транскрипцияләре һәм русча тәрҗемәләре бирелә, ләкин алар тәртип буенча бирелмәгән. Укытучының сигналы белән укучылар һәр алмашлыкның дөрес транскрипциясен һәм тәрҗемәсен табарга тиеш булалар. Алар аны сан яки сызыклар белән тоташтыра алалар. Кем хатасыз һәм беренче булып эшне тәмамлый – шул җиңүче була. Бер карточканың мисалын китерәм:

| | | |
|---|---|---|
| синең | [үзэмдә] | какой |

| | | |
|---|---|---|
| бу | [аңа] | что-то |
| нинди | [бу] | у себя |
| һәркем | [синэң] | у тебя |
| нәрсәдер | [бөтөн] | ему, ей |
| бөтен | [һәркэм] | каждый |
| аңа | [нинди] | весь |
| үземдә | [нәрсәдэр] | этот |

Бу уенның төп максаты – вакыт **(«Кем тизрәк?»)**. Ягъни кем тизрәк без өйрәнгән күрсәтү алмашлыкларын яза, яки алмашлыкның башка төркемчәләрен дә бирергә була. Бу уенны башка төрле дә бирергә мөмкин. Мәсәлән: бер минут эчендә алмашлыклар белән күбрәк җөмләләр төзегез.

Татар теле дәресләрендә укучыларга алмашлык сүз төркемен «Кар өеме», «Киресен әйтешле», «Йөзек салыш», «Кызык телефон», «Сүзләр тап», «Эстафета», «Югалган алмашлыкларны тап», «Кем җитез?», «Исеңдә калдыр», «Кем нәрсә турында уйлады?», «Чәчәк бәйләмнәре», «Дәфтәрләрне җыю», «Сүзләр төркемнәре», «Уңыш җыю», «Артык вагон», «Кем иң бай?», «Кәрзинне тутыр», «Сүз киресенчә», «Тылсымчы», «Кояш», «Кайсы артык», «Бу нинди сүз», «Сүзне исеңдә калдыр», «Белмәмешнең шаяруы», «Җиде таҗлы чәчәк», «Адым саен», «Иң җитез», «Кем тизрәк?» кебек лексик уеннар аша өйрәтү күпкә уңышлырак булачак, чөнки уен балаларда һәрвакыт кызыксындыру уята.

## 2.3. Грамматик уеннар

Кеше тормышында уен хезмәт, эш кебек үк әһәмиятле урын тота. Шуңа күрә дә кешене балачактан тәрбияләү, аның киләчәктәге эшчәнлегенә юл салу уен процессында башлана. Бала уенда нинди булса, үскәч, эшендә дә шундый ук була. Аерым кешенең яшәү тарихын, ягъни аның эшчәнлеген һәм нинди шәхес булып җитүен балачактагы уенның алга таба үсеше, аның

акрынлап эшчәнлеккә күчүе итеп карарга мөмкин. Элекке заманнардан ук кешеләр уенны өлкәннәрнең тәҗрибәсен буыннан-буынга тапшыруда нәтиҗәле чара буларак файдаланганнар. Уен – бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз бер өлеше. Тәрбия чарасы буларак, ул балаларның камилләшүенә, шәхес буларак формалашуына, үзгәрүенә этәргеч булып тора. Укучыларның белем һәм күнекмәләрен арттыруда, аларның үз фикерләрен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, үзара аралашу осталыгына ирешүдә, шулай ук балаларны тел фәне белән кызыксындыруда да уеннарның әһәмияте зур. Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар укучыларны активлаштыра, аларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә һәм иҗади халәт булдыра. Уеннар вакытында фән нигезләрен үзләштерү белән бергә укучы үз фикерләрен формалаштыра белү күнекмәләре дә ала.

Татар теле дәресләрендә, аерым тел фактын өйрәнгәндә, сөйләү һәм язу күнекмәләре биргәндә, мавыктыргыч уеннар белән читенлек ситуациясе тудырылырга, уен элементлары кертеп, проблемалы сорау һәм мәсьәләләр куелырга тиеш. Аларны чишү балада үз көченә ышану тойгысы уята, аннан зуррак эшләрне башкаруга, катлаулы күнегүләрне эшләүгә дәртләндерә, максатка ирешүдә бернинди киртәләр алдында да тукталып калмау сыйфатын формалаштыра. Укучы дәрестә никадәр актив катнашса, мөстәкыйль фикер йөртсә, һәр яңаны нәтиҗәле итеп тану ысуллары белән коралланса, грамматик теорияне һәм сөйләм практикасын үзләштерү процессы да шулкадәр уңышлы барачак. Укучылар тел фактларын кызыксынып, мөстәкыйль фикер йөртеп, анализлап өйрәнсә, шул анализга карата үзләре нәтиҗәләр дә ясап караса, материалны үзләштерү, һичшиксез, нәтиҗәле булачак. Уен күнегүләре туган телне өйрәнү белән укучыларны мавыктыру, сыйныфта грамматика дәресләрен җанлы, кызыклы итү, балаларның дөрес сөйләү һәм язу күнекмәләрен аңлап һәм җиңел үзләштерү булдыру теләгеннән чыгып эшләнде. Дәресләрдә үзем куллана торган берничә грамматик уенны тасвирлап китәм.

Дәресләрдә иң яратып кулланган һәм шулай ук укучыларның күңеленә яткан уеннарның берсе – татарча төрле мультфильмнардан ишеткән алмашлыкларны язып алу. Бу уен укучыларның игътибар булуын таләп итә. Укучылар дәртләнеп, ярыша-ярыша яза башлыйлар. Мәсәлән, «Алтын бөртекләр» исемле мультфильмнан 6 нчы сыйныф укучылары түбәндәге алмашлыкларны ишетеп язып алдылар: аларның, үзе, үз, мин, сезне, үзегез, без, үзебез, син, безгә, ул, аны, әнә, алар, менә, шул, болай, миңа, шулар, аларны, үзләрен һ.б. «Эш беткәч, уйнарга ярый» мультфильмыннан укучылар шул, бу, ул, нинди, барсыны, кем, мин, аңар, шунда, һәрбер, сез, нәрсә алмашлыкларын язып алалар. Бик яратып каралган «Бал корты белән Шөпшә»дән минем, алар, үз, менә, мин, шул, кемгә, бар, кем, барлык, шуңа, һәркайсының, син, миңа, сезгә, ничек, бу, барысы, кайда, нинди, без алмашлыкларын язып алырга мөмкин. Ә «Ике кыз» экиятеннән аларның, шуның, беркем, аның, моңа, ул, син, мин, моның, безнең, алар, һәрберсенә, үз, бу, безгә, сезгә, үземә, аны, үзе һ.б. сүзләрне яза алалар. Алмашлыкларны язып алгач, без һәр алмашлыкның төркемчәсен әйтеп, аның җөмләдә кайсы кисәк булып килүен билгелибез. Кирәк булса, бу алмашлыкларның кайсы килеш белән төрләнүен дә кабатлап китә алабыз. Бу алым аша укучылар татар сөйләмен ишетеп аңлауга ирешәләр. Сөйләмне тыңлау белән бергә, алар сүз төркемнәрен аерырга өйрәнәләр.

**«Дәрес-шоу»** уенын алмашлык сүз төркемен тулысынча үткәч, кабатлау рәвешендә үткәрергә мөмкин. Дәресне уздыру өчен, сыйныф берничә төркемгә бүленә, һәм һәр төркем үзенең җитәкчесен сайлый. Төркемнең җитәкчесе укытучы биргән тема буенча әңгәмә оештырырга һәм аны сыйныфка тәкъдим итәргә тиеш. Алмашлыкка бәйле түбәндәге темаларны аерып чыгарырга мөмкин: зат алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, сорау алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары, билгесезлек алмашлыклары һ.б. яки исем алмашлыклары, сыйфат алмашлыклары, рәвеш алмашлыклары, сан алмашлыклары һ.б. Әңгәмәгә башка төркем укучылары

да кушыла. Шул тәртиптә барлык төркемнәр дә үзләренең темалары буенча чыгышлар ясый, алмашлыклар темасы кабатлана.

**«Нәрсә? Кайда? Кайчан?»** дәрес-уены. Бу уен телетапшыру үрнәгендә алып барыла. Аны алмашлык темасы буенча алган белем һәм күнекмәләрне тикшерү максатыннан чыгып оештырырга була. Мәсәлән, теманы өйрәнеп бетергәч, чирек, яки уку елы ахырында һ.б.

**«Җитәкче бул»** уены. Сүзләр төрле сүз төркеменнән булырга тиеш. Мәсәлән, *урман, ачы, өлгерде, миләш*. Сүзләрне әйткәч, укытучы өч мәртәбә кул чаба. Шул вакыт эчендә уйнаучылар, шушы сүзләрне кертеп, җөмлә төзиләр. Бу уенда җөмлә төзер өчен, без сүзләр җыелмасына алмашлыкларны да кертә алабыз. Мәсәлән: *базар, ул, кишер, сатып ал, зур* сүзләреннән укучылар *Ул базарда зур кишер сатып алды* җөмләсен төзиләр яки *Ул зур базарда кишер сатып алды* җөмләсен дә төзергә була һ.б.

Уен технологиясен күбрәк I-VI сыйныфларда татар теле дәресләрендә кулланырга мөмкин. Бу бигрәк тә кабатлау-йомгаклау дәресләрендә **грамматик күнегүләр** эшләгәндә отышлы. Мәсәлән: "Сүз төркемнәре иленә сәяхәт", "Кайчан? Кем? Нәрсә эшләгән?", "Тамчы шоу", "Укытучы шоу" кебек телевизион уеннар укучыларның туган тел белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, зирәклеген үстерә, аларны коллектив рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә. Уен технологиясен йомшак укучы балалар белән эшләгәндә дә кулланырга була, чөнки белемне уен элементлары белән бирү тиз үзләштерергә ярдәм итә.

**«Күршеләр»** уены. Иң башта укучылар үзләренең күршеләре турында сөйлиләр. Укытучы укучылардан күршеләре белән ничек яшәүләрен сораштыра: күршеләре аларны борчымыймы, бигрәк тә нәрсә аларга комачаулый (кирәкле-кирәксез шакылдау, көчле тавыш белән телевизор карау, музыка тыңлау һ.б.). Күршеләрдән канәгатьсезлек сәбәпләре тактага язылып куела. Шуннан соң төркем парларга бүленә, биремнәр таратыла.

Һәрбер пар күрсәтелгән сәбәпләрнең берсен сайлап ала, диалог төзеп, аны уйнап күрсәтә. Аннан соң парлар яңадан төркемнәргә берләшәләр һәм күршеләр белән яхшы яшәү кагыйдәләрен төзиләр.

Бу уен мәгълүмат җыюга нигезләнеп төзелә. Уенда катнашучылар бәйрәм табыны янына чакырыла. Табын янында күрше утыручылар арасында әңгәмә оештырыла, алар кайчандыр бер-берсен күргән кебек, ләкин кайчан, ничек очрашулары турында хәтерли алмыйлар. Уенчыларның төп максаты – шул очрашуны ачыклау. Сөйләшү барышында кунаклар бер-берсе белән танышалар, кайда яшәүләре, кайда укулары турында һ.б. сорашалар. Әлбәттә, укучылар үзләренең күршеләре турында сөйләгәндә алмашлыкларны кулланырга мәҗбүр булалар. Ягъни, алмашлыклар кабатлана һәм искә төшерелә.

**«Рәсем буенча сөйлә»** уенында без алмашлыкларны кулланмыйча булдыра алмыйбыз. Чөнки ярышның һәр катнашучысы рәсем буенча, эчтәлек логикасын саклап, берәр җөмлә әйтәләр. Кем иң соңгы җөмләне әйтә, шул җиңүче була. Ә текст матур килеп чыксын өчен, укучылар алмашлыклар белән җөмләләр төзергә мәҗбүр булалар.

Уен технологиясен уку-укыту процессында куллана башлаганчы, иң башта кайсы темаларны уен аша өйрәнү максатчан булуын ачыкларга кирәк. Уенны оештырганда, вакыт бүленешен төгәл билгеләргә кирәк, чөнки ял вакытларында уен кагыйдәләре бозылырга һәм уенның нәтиҗәлелеге түбән булырга мөмкин. Уеннар куллану балаларга тел материалын гамәли эшчәнлектә үзләштерергә булыша.

**«Фоторобот ясa»** уены. Һәрбер укучыда кәгазь бите һәм төсле карандашлар. Класс өч командага бүленә (һәрберсе – милиция бүлеге). Өч алып баручы билгеләнә (яхшы өлгерешле укучылар). Алар милиция бүлегенә югалган дусларын табу үтенече белән мөрәҗәгать итәләр. Алып баручылар тышкы кыяфәтен сурәтлиләр, ә балалар туры килүче рәсемнәр ясыйлар. Әгәр рәсем сөйләмгә туры килсә, югалучы табылган дип санала. Мәсәлән, «Бу

минем сеңлем. Аның исеме Гүзәл. Гүзәл укучы. Аның чәче озын, күзләре зәңгәр. Ул кызыл күлмәктән иде». Бу уенны уйнаганда, укучылар үзләренең югалган дусларын тасвирлар өчен, алмашлыкларны кулланырга тиеш булалар. Бу уен аша алмашлыклар укучыларның сөйләмендә активлаша.

**«Ул нинди төстә?»** уены. Уен укучыларның төсләрне белдерүче лексика куллануны кабатлауга юнәлтелгән. Өстәлдә төрле төстәге уенчыклар җәеп салынган. Укытучы бер укучыга (алып баручыга) берәр хайванны уйлап куярга киңәш итә. Калганнар аның нинди хайван яки җәнлек икәнен белергә тиешләр. Башта алар сораулар бирәләр: «Ул ак төстәме?», «Ул кызылмы?», «Ул зәңгәрсу төстәме?», «Ул карамы?» һ.б. Шуннан төсне дөрес атаган укучы икенче сорау бирә: «Бу ак куянмы?». Әгәр укучы ялгышмаган икән, ул алып баручы була. Укучылар сораулар уйлаганда, үзләренең сөйләмендә алмашлыклар кулланырга мәҗбүр булалар. Чөнки хайваннарны исемнәре белән әйтергә ярамый.

**«Нәрсә кайда?»** уены. Укытучы сыйныф бүлмәсендәге, өстәлдәге, сумкадагы әйберләр турында сорый. Укучылар аларның урыны турында, өйрәнелгән җөмлә үрнәкләреннән файдаланып хәбәр итә. Мәсәлән, Бу нәрсә? – Бу карандаш. Карандаш кайда? – Карандаш өстәлдә. Укучылар алмашлык сүз төркемен белмәсәләр дә, алар аны кабатлаган саен истә калдырып, үзләренең сөйләмендә актив кулланачаклар. Һәм, әлбәттә, алмашлык темасын тирәннән өйрәнә башлагач, укучыларга авыр булмаячак.

**«Татар телен яратучылар»клубы утырышы**. Утырыш һәр чирек ахырында оештырылырга мөмкин. Ул татар теленнән теоретик, гамәли белем һәм күнекмәләрне тирәнәйтү максатыннан чыгып оештырыла. Һәр утырыш аерым бер темага багышлана. Мондый дәрестә без алмашлык сүз төркемен кабатлый алабыз. Өй эше буларак, тема буенча зур булмаган теоретик чыгышлар әзерләү тәкъдим ителә ала.

**«Тәрҗемәче»** уены. Укучыларга тема бирелә. Беренче укучы бу теманы рус телендә үстерә, икенче укучы тәрҗемә итә. Бу уенда без төрле

тема тәкъдим итә алабыз. Тәрҗемә вакытында укучылар үзләренең сөйләмендә алмашлыкларны кулланырга мәҗбүр булалар. Чөнки бер сүзне текстта гел кабатлап булмый, чөнки сөйләм матур яңгырашлы, аһәңле булмый.

**«Журналист»** уенында беренче укучы – журналист, башка (берничә укучы булырга мөмкин) укучы – таныклы шәхес. Журналист интервью ала. Беләбез: интервью зат алмашлыкларыннан һәм сорау алмашлыкларыннан була алмый. Журналист таныклы шәхескә һәрвакыт «сез» дип мөрәҗәгать итәчәк.

**«Кем син»** уены. Беренче укучыга алдан роль бирелә (мәсәлән, син таныклы, рәссам яки шагыйрь, очучы, программист һ.б.), башкалар шәхеснең кем икәнен белер өчен аңа төрле сораулар бирәләр. Бу уенда сорауларны биргәндә, укучылар алмашлык сүз төркемен кулланырга мәҗбүр булалар.

**«Яраткан әкият геройларыңны таны»** уены. Укытучы (яки яхшы өлгерүче укучы) яраткан әкият геройларын сурәтли яисә алар турында укый. Укучылар тыңлыйлар. Алар кайсы әкият геройлары турында сүз барганын белергә тиешләр. Мәсәлән:

а) Аның чәче коңгырт, кыска. Борыны озын, кашлары кара. Колаклары зур, чиста. Ул матур, шаян малай. Аның исеме ничек? (Буратино).

б) Бу – кыз. Аның чәче зәңгәр, озын. Кашлары кара. Күзләре зәңгәр, зур. Борыны кечкенә. Ул матур кыз. Аның исеме ничек? (Мальвина). Укытучы әкият геройларын тасвирлаганда, алмашлыкларны кулланмыйча булдыра алмый. Укучылар ишетеп исә калдыралар һәм үзләренед сөйләмендә кулланалар.

**«Шәвәли»** уены. Шәвәли ролен укытучы да, укучы да башкарырга мөмкин. Минемчә, укучы булса, тагы да кызыклырак булачак. Өйрәнелгән темалар буенча укучылар аңа сораулар бирәләр. Шәвәли аларга ялгыш җаваплар бирә. Укучылар аны төзәтергә тиеш булалар. Мәсәлән, Син кем? – Шәвәли. Мин кыз. (Дөрес җавап: Мин Шәвәли. Мин малай). Бу уенны татар

теле дәресендә үткән, грамматикага караган темаларга багышларга була. Мәсәлән, укучы сорау бирә: Кем эшләми, шул ашамый мәкалендә кем сүзе җөмләнең кайсы кисәге була? Шәвәли хаталы җавап бирә: Бу мәкальдә кем сүзе аергыч булып килгән. Укучылар Шәвәлине төзәтәләр: Кем сүзе җөмләдә – ия. Бу уен укучыларны кагыйдәләрне истә калдырырга, тел нормаларына игътибарлы булырга өйрәтә, сүзләрне дөрес куллану күнекмәләре формалаштыруга ярдәм итә.

**«Танышу»** уенын 1 нче сыйныфта укучылар бик яратып уйныйлар. Укучылар дәрескә төрле хайван, кош битлекләре алып киләләр һәм үзара түбәндәгечә сөйләшәләр.

1 нче вариант: – Исәнме! Син кем?

– Исәнме! Мин Куян. Ә син кем?

– Мин сыер.

2 нче вариант: – Исәнме! Синең исемең ничек?

– Исәнме! Минем исемем Тавык. Ә синең исемең ничек?

– Минем исемем Әтәч.

Танышканда, алар үзләренең сөйләмендә алмашлыкларны актив кулланып истә калдыралар.

**«Кемнең хәтере яхшы?»** дигән уен балаларны сөйләмдә бер-берсенең сүзенә игътибарлы булырга өйрәтә. Бер укучы нинди дә булса җөмлә әйтә («Мәсәлән: «Мин кибеткә барам»). Икенчесе шул җөмләне кабатлап, эчтәлеге белән аңа бәйләнешле башка бер җөмлә әйтә. Уен шулай дәвам итә. Иң ахыргы укучы тулы бер текстны сөйли. Текстны төзер өчен, балалар алмашлыкларны искә төшереп кулланачаклар.

**«Серле тартма»** уены. Ике укучының кулында берәр тартма. Аларда төрле әйберләр, рәсемнәр бар. Балалар, тартмадан әйберләрне, рәсемнәрне берәм-берәм алып, бер-берсенә алмашлыкларны кулланып: «Бу нәрсә?», «Бу кем?» сораулары һәм аларга җавап бирәләр.

Кече яшьтәге мәктәп балалары 45 минут буе дәрес тыңларга күнекмәгән. Парта арасында хәрәкәтсез утыру ялыктыра, аларның дәрескә игътибары кими. Яшь организм әледән-әле хәрәкәт таләп итә. Һәр дәрестә, 15 – 20 минут узгач, физик һәм музыкаль тәнәфесләр ясау эшнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итә. Кул, бармак, гәүдә хәрәкәтләрен эченә алган гимнастик күнегүләр уен хәлендә күңелле узсын өчен, алар төрле санавычлар, җыр, такмаклар белән башкарылалар.

Уен сүзләре исә үз чиратында балаларны ритм, рифманы аңларга гадәтләндерә һәм алардагы сөйләү кимчелекләрен бетерергә ярдәм итә.

Җырлы түгәрәк уеннары, сүзле-хәрәкәтле уеннар уйнаганда балалар сүзләрне тизрәк үзләштерәләр. Алар бу уеннарны дәрес вакытында да, дәрестән тыш та яратып уйныйлар. Җырлы-сүзле уеннарны балалар хәрәкәтләр белән ныгыталар. Уеннарны физкультминутка өчен сайлаганда, тексты кыска булырга тиеш. Ул аларга истә калдыру өчен уңай.

Телне өйрәнгәндә **уеннар, шигырьләр, җырлар** темага яраклаштырып сайланылса, нәтиҗәсе уңай була. Мәсәлән, без беренче сыйныфларда «Мәктәптә» темасын өйрәнгәндә мондый җыр тәкъдим итәбез.

Мин, син, ул, без, сез, алар,
Мин, син, ул, без, сез, алар,
Без хәзер укучылар, укучылар.
Мәктәпкә бүген килдек,
Кулда дәфтәр, дәреслек,
Акбур, каләм, бетергеч тә кирәк безгә. («Өйрәтәләр мәктәпләрдә» көенә дә, «Улыбка» көенә дә җырларга була.)

Балалар әлеге җыр текстындагы сүзләрне автомат рәвештә генә ятламыйча, мәгънәсен дә истә калдыралар. Җырның беренче юлындагы алмашлыкларны кабатлап, укучылар зат алмашлыкларының тәртибен дә исләрендә калдыралар. Әлбәттә, әлегә алар аны алмашлык буларак белмиләр, ләкин бу белемнәр аларга киләчәк өчен нигез булып тора.

**«Ышанам-ышанмыйм»** уены. Укытучы алмашлыклар темасына караган җөмләләр әйтә. Шуларның кайберләре дөрес булмый. Балалар укытучы әйткәннәргә ышануларын яки ышанмауларын белдерергә тиешләр. Уен игътибарлылык һәм хәтерне үстерүгә ярдәм итә. Укучылар җөмлә дөрес дип ышансалар – кул чабалар, ә ышанмасалар аякларын тыпырдаталар.

Дөрес һәм дөрес булмаган җөмләләр үрнәге:

– Мин алмашлыгы зат алмашлыгына керә.

– Һичбер алмашлыгы билгеләү алмашлыгына керә.

– Алар алмашлыгы килеш белән төрләнә.

– Һәркем алмашлыгы сорау алмашлыгына керә.

– Үзе алмашлыгы иялек килешендә үзендә була һ.б.

**«Тылсымчы»** уены. Укучыларга конвертлар таратыла. Ә анда – сүзләр. Шулардан дөрес итеп жөмләләр, текст төзергә кирәк. Темалар төрле булырга мөмкин. Карточкада жөмлә башындагы сүз калын хәреф белән күрсәтелә, жөмлә ахырындагы сүз артыннан тыныш билгесе куелган була. Баштарак гади текст бирелсә, соңыннан катлаулырак текстлар бирелә. Укучылар үзләре дә бер-берсенә карточкалар төзеп алып киләләр. Кабатлау максатыннан, укытучы конвертларга алмашлык сүз төркемен дә кертә ала.

**«Поезд»** уены. Тактада эшләү өчен зур вариантта поезд рәсеменә алмашлыклар, вагоннарга – килеш кушымчалары язылып эшләнә. Бу уен аша укучылар кушымчаның дөресен сайлап, алмашлыкларны төрләндерергә өйрәнәләр.

**«Хатаны тап»** уенында берничә җөмлә аудиоязма аша укучыларга тыңлатыла. Шушы җөмләләр арасында берсе хаталы була. Мәсәлән, аудиоязмада биш җөмлә яздырылган:

1) Алар алмашлыгы зат алмашлыкларына керә.
2) Бу алмашлыгы күрсәтү алмашлыкларына керә.
3) Бөтен алмашлыгы билгесезлек алмашлыкларына керә.
4) Һәркем алмашлыгы билгеләү алмашлыкларына керә.

5) Ничек сүзе сорау алмашлыкларына керә.

Укучылар аудиоязманы игътибар белән тыңлыйлар, хатаны тапкан укучы кулын күтәрә һәм җавап бирә һәм хаталы җөмлә төзәтелә. Күбрәк хата тапкан укучы уенның җиңүчесе була. Уенның азагында нәтиҗә ясап, алмашлыкларның төркемнәрен искә төшереп алырга мөмкин.

**«Үзеңнең урыныңны тап»** уенында сыйныф ике төркемгә бүленә. Тактада зат алмашлыклары язылган: мин, син, ул, без, сез, алар. Беренче төркем укучыларга зат-сан белән төрләнгән хикәя фигыльләр язылган карточкалар таратыла. Мәсәлән: яшим, ашыйм, бүләк итә, укыйсың һ.б. Укытучы сигналы белән уйнаучылар үзләренең карточкаларындагы фигыльләргә туры килгән тактада язылган алмашлык алдына килеп басалар. Алга таба һәр укучы шушы алмашлык һәм фигыль белән җөмлә төзергә тиеш була. Мәсәлән: мин шәһәрдә яшим. Һәр дөрес җавап өчен командага балл бирелә. Әгәр җавапта хата булса яки укучы фигыльгә туры килгән алмашлыкны таба алмаса, командага балл бирелми. Беренче төркем укучылары карточкаларны укытучыга тапшырып, урыннарына утыралар. Икенче төркемгә башка фигыльләр язылган карточкалар таратыла: рәсем ясый, җырлыйлар, биим һ.б. Күп балл җыйган команда җиңүче була.

**«Татар телен яхшы беләсезме?»** уены укучыларга алмашлыкларның килеш белән төрләнешен искә төшерергә ярдәм итәчәк.

Укытучы: Укучылар, мин сезгә алмашлыклар әйтәм, сез аларны төрле килешләрдә төрләндереп әйтергә тиеш буласыз. Мин иялек килешендә?

Укучылар: минем.

Укытучы: алар иялек килешендә?

Укучылар: аларның.

Укытучы: сез юнәлеш килешендә ничек була?

Укучылар: сезгә.

Укытучы: үзе алмашлыгын урын-вакыт килешендә төрләндерегез.

Укучылар: үзендә.

Укытучы: без алмашлыгын чыгыш килешендә төрләндерегез.

Укучылар: бездән һ.б.

**«Сорауларга җавап бирәбез»** уенында укучыларга таблица ясалган карточкалар таратыла. Юлларда фигыльләр язылган була, ә багана башларында төрле сораулар. Укучылар шушы фигыльләргә мәгънәсе буенча туры килгән җаваплар язарга тиеш булалар. Мәсәлән:

| | Кайчан? | Ничек? | Кайдан? | Кая? | Кайда? |
|---|---|---|---|---|---|
| барырга | | | | | |
| тыңларга | | | | | |
| йөгерергә | | | | | |
| көрешергә | | | | | |

Бу уен аша укучылар сүзтезмәләр төзергә һәм татар телендә иркен сөйләшергә өйрәнәләр.

**«Алма жыю»** уены болай оештырыла. Ике зур кәгазьгә «алма агачы» ясала. Ботакларга килеш исемнәре дә языла. «Алма»ларның артына төрле килештәге алмашлыклар язылган була. Сыйныф ике командага бүленә. Командалардан берәр укучы чыга. Алар ярыша-ярыша, «алмаларын» ботакларга элә. Кем алдан элеп бетерә, шул жиңүче була. «Алмалар» өчен мисаллар: мин, үзеннән, синең, аңа, безне, сездән, аларда, үземә, анда, шуның, моңа һ.б.

**«Гөмбә җыю»** уенын алмашлыкларның мәгънә төркемчәләрен өйрәнгәндә куллану отышлы. Кәрзиннәргә алмашлык төркемчәләренең исемнәре языла. «Гөмбә»ләрнең артына төрле алмашлыклар язылган. Укучылар «Гөмбә»ләрне тиешле кәрзиннәргә салырга тиешләр. Укучыларга җиңелрәк булсын өчен, 2 яки 3 төркемчәне генә алып та уйнарга мөмкин.

Алмашлыкларны үткәндә **«Кем тапкыррак?»** уены уйнала. Укытучы табышмаклар укый. Укучылар жавапларын табалар һәм очраган алмашлыкларны төркемчәләргә бүлеп язып алалар (зат, тартым, күрсәтү, сорау, билгеләү, билгесезлек, юклык). Мисал өчен табышмаклар:

– Жәен соры, кышын ак, *аңа* (зат алм.) *шулай* (күрсәтү алм.) яхшырак. (Куян)

– Бер йомгакта мең энә, *сиңа* (зат алм.) тими, *син* (зат алм.) тимә. (Керпе)

– *Моны* (күрсәтү алм.) *миңа* (зат алм.) сөйләде Алдар,
Әгәр *сиңа* (зат алм.) очраса,
*Ул* (зат алм.) *сине* (зат алм.) дә алдар;
*Болар* (күрсәтү алм.) барсы да ялган,
Ялган булса да,
Ак кәгазьгә язылган. (Әкият)

– Аршынлы түгел, потлы түгел,
*Һәркемдә* (билгеләү алм.) бар. (Акыл)

– Теле юк – *үзе* (билгеләү алм.) аңлата. (Китап)

– Ак җир, кара тап,
*Нәрсә* (сорау алм.) булыр, уйлап тап. (Китап)

– Киштә башында төпле төргәк,
*Аңа* (зат алм.) *һәр* (билгеләү алм.) өйдә хөрмәт,
*Һәркемгә* (билгеләү алм.) дә иң кирәк. (Китап)

– Җаны юк, *үзе* (билгеләү алм.) кырык төрле тел белә. (Каләм)

– *Үзе* (билгеләү алм.) йөзә – чылбыр тезә. (Каләм)

– Әйтермен – *миннән* (зат алм.) китәр,
Тыңламасаң – *синнән* (зат алм.) китәр. (Сүз)

– Теле юк, *теләсә кем* (билгесезлек алм.) белән сөйләшә,
Гәүдәсе юк, кәгазьдән күлмәк кия. (Хат)

– Кабат-кабат,
Бер кошта өч йөз алтмыш биш канат,
*Мин* (зат алм.) торам *аны* (зат алм.) санап,
Көн дә кими бер канат. (Календарь)

– *Ул* (зат алм.) булса, көн була.

*Ул* (зат алм.) булмаса, төн була. (Кояш)

– Тау башында җәүһәр таш,

*Аңа* (зат алм.) туры караган кешенең күзе яшь,

*Аны* (зат алм.) тапкан кешегә йөз егерме яшь. (Кояш)

Язма эшләр тикшерелә һәм очколар бирелә. Табышмакларның жавапларын тапкан өчен дә очко бирергә мөмкин. Иң күп балл алган укучы жиңүче була.

«**Җиләк җыю», «Ромашка»** уеннары алмашлык турында алган белемнәрне ныгыту этабында уздыру уңышлы. Укучылар чәчәк таҗларына, яисә җиләк артына үткән тема буенча сораулар язалар. Бирелгән вакыт эчендә бу сорауларны бер-берсенә биреп, карточкалары белән алмашалар. Бу бирем ярдәмендә укучылар диалогик сөйләм күнекмәләрен ныгыталар. Шул ук вакытта хәрәкәт итеп ял итәләр, үзара аралашалар. Кайбер укучылар дәрестә «җавабым дөрес булмаса укытучы түбән билге куя» дип кулын күтәрмичә утыралар. Ә сыйныфташларына җавап бирү аңа күпкә җиңелрәк. Аралашу ярдәмендә «артта калучы» укучылар да үткән тема буенча белемләрен шомарталар, нәтиҗәдә укытучы сорагач аларда оялу хисе югала.

Ишетү игътибарын үстерү өчен **«Яшел светофор»** уенын тәкъдим итәм. Укытучы төрле җөмләләр әйтә, ә укучылар игътибар белән тыңлыйлар. Алмашлык булган җөмлә булса, укучылар светофорны күтәрәләр. Мәсәлән, «Мин мәктәпкә барам», «Җәй күңелле узды», «Мин чана шуам», «Синең кәефең ничек?», «Малайлар елгада су коеналар», «Каникуллар җиткәч, мин авылга китәм», «Матур чәчәккә күбәләк кунды», «Дуслар белән кинотеатрга бардык» җөмләләре арасыннан укытучы «Мин мәктәпкә барам», «Мин чана шуам», «Синең кәефең ничек?», «Каникуллар җиткәч, мин авылга китәм» укыганда, укучылар кулларындагы светофорны күтәрергә тиеш булалар һәм шул җөмләне кычкырып кабатлыйлар (аудирование).

**«Нәрсә үзгәрде?»** уены хәтерне үстерү, истә калдыру күнегүе буларак тәкъдим ителә. Тактада алмашлыклар язылган 3-5 рәсем ябыштырыла.

Мәсәлән: без елгада, алар су керә, мин кояшта кызынам, ул җиләк җыя, син туп белән уйныйсың һ.б. Рәсемнәрне 10-15 секунд караганнан соң, балалар күзләрен йомалар. Укытучы рәсемнәрнең урыннарын алмаштыра һәм нәрсә үзгәргәнен сорый. Бер җиңүчене билгеләгәнче уенны дәвам итәргә мөмкин.

Бу уен – игътибарлылыкны үстерү өчен физкультминут. «Укучылар, мин сезне хәзер тикшереп карыйм. Зат (күрсәтү, сорау, билгеләү, билгесезлек, юклык) алмашлыкларын әйбәт беләсезме икән? Зат (күрсәтү, сорау, билгеләү, билгесезлек, юклык) алмашлыкларын әйтсәм – басыгыз, башка сүзләр әйтсәм – басмагыз», – дип, укытучы бар баланы да бастыра һәм зарядка уздыра.

**«Җөмлә төзе»** уенын башлангыч сыйныфларда зат алмашлыкларын өйрәнгәч уйнарга була. Монда укучылар дөрес итеп җөмлә төзергә өйрәнәләр. Такта янына өч укучы чакырыла. Укытучы аларның һәммәсенә берәр сүз тарата: йөзәм, мин, бассейнда. Укучылар дөрес басып, карточкаларын күтәрергә тиешләр. Сыйныф укый: «Мин бассейнда йөзәм» һ.б.

Бу уен аша укучыларның сүз төркемнәрен белүләрен тикшерергә була. Укучыларга текст бирелә. Һәр сүз төркеме бер төс аша билгеләнә. Укучы бирелгән текстның төсле диаграммасын төзергә тиеш. Бу уенны икенче төрледә бирергә мөмкин. Мәсәлән, төсле диаграмма бирелә, ә укучылар шуңа туры китереп үзләре текст төзергә тиеш булалар. Мәсәлән һәр сүз төркеме мондый төсләргә җавап бирә:

исем – кызыл,

сыйфат – зәңгәр,

сан – яшел,

фигыль – сары,

алмашлык – кызгылт-сары,

рәвеш – шәмәхә,

бәйлек, теркәгеч – кара.

Укучыларга бирелгән текст: Минем кечкенә энем бар. Аның исеме Артур. Аңа биш яшь. Ул балалар бакчасына йөри. Көндез мин мәктәптән кайткач, дәресләремне әзерлим. Кич Артурны балалар бакчасыннан алып кайтабыз. Без бергә төрле уеннар уйныйбыз. Азактан мин уенчыкларны җыям, ә Артур миңа ярдәм итә. Укучылар әлеге текстның диаграммасын түбәндәгечә эшлиләр:



**Нәтиҗә** ясап әйткәндә, грамматик уеннар телнең бөтен ярусларын да кабатлау өчен файдалы. Монда укучылар сүз белән генә түгел, ә җөмлә белән эшлиләр, ягъни сөйләм күнекмәләрен ныгыталар. Грамматик уеннардан «Җөмлә төзе», «Нәрсә үзгәрде?», «Яшел светофор», «Җиләк җыю», «Ромашка», «Кем тапкыррак?», «Гөмбә җыю», «Алма җыю», «Сорауларга җавап бирәбез», «Татар телен яхшы беләсезме?», «Үзеңнең урыныңны тап», «Хатаны тап», «Поезд», «Тылсымчы», «Ышанам-ышанмыйм», «Серле тартма», «Кемнең хәтере яхшы?», «Танышу», «Шәвәли», «Яраткан әкият геройларыңны таны», «Кем син», «Журналист», «Тәрҗемәче», «Татар телен яратучылар»клубы утырышы, «Нәрсә кайда?», «Ул нинди төстә?», «Фоторобот ясა», «Рәсем буенча сөйлә», «Күршеләр», «Җитәкче бул», «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» уеннарын тәкъдим итәбез.

## 2.4. Рольле уеннар

Татар теленә өйрәткәндә, бигрәк тә рус телендә сөйләшүче балаларны, **рольле уеннар** аеруча актив кулланыла. Бу уеннарның өйрәтү мөмкинлекләре зур, һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар алар белән иркен эш итәләр. Шуның белән беррәттән, укучыларның дәрес белән кызыксынулары арта, тел һәм сөйләм материалын өйрәнү дә нәтиҗәлерәк була. Рольле уенны парлап һәм төркемнәрдә дә оештырырга мөмкин. Бу вакытта сөйләмгә бәйле һәм аңа бәйле булмаган хәлдә дә катнашучылар бер-берсенә йогынты ясыйлар. Балаларда, табигый рәвештә, нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау ихтыяҗы яки әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа. Рольле уеннар берничә этаптан тора: өйдә яки сыйныфта әзерләнү, сыйныфта уенны оештыру, йомгаклау этаплары. Уенны оештырганда, укытучы берничә факторны истә тотарга тиеш:

– укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыру;

– сөйләм эшчәнлеге дәрәҗәсенең төрле булуын истә тотып, балаларга рольләрне дөрес бүлеп бирү;

– уенның нәтиҗәсе укучыларның хисси халәтенә бәйле булу;

– укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне файдалану;

– үзара ярдәмләшү, телдә актив аралашу мохите булдыру.

Рольле уеннарны ничек оештырып була соң? Ф. Ф. Харисов билгеләвенчә, аларны оештыруның методикада кабул ителгән этаплары бар.

1. Әзерләнү этабы (сценарий төзү, план төзү, уенга гомуми тасвирлама бирү, уйнаучыларга хас булган билгеләр, рольләрне бүлү).

2. Аңлату этабы (катнашучыларга юнәлеш бирү, төп максатны билгеләү, проблема кую, катнашучыларны психологик яктан әзерләү).

3. Үткәрү этабы (уйнау, киңәшләр бирү).

4. Анализлау һәм йомгаклау этабы (анализ ясау, рефлексия; бәя һәм үзбәя; нәтиҗә һәм йомгак ясау; тәкъдимнәр әйтү).

Рольле уен – уку-укыту процессы барышында билгеле бер сөйләм ситуациясен өйрәнү чарасы. Аның нигезендә, бирелгән сюжетка һәм бүленгән рольләргә нигезләнеп, билгеле бер темага сөйләшү оештыру ята. Уен вакытында тигезлек, бер дәрәҗәгә куелу балаларда оялу, тартынуны бетерә һәм аларны мавыктырып җибәрә. Бу ягы белән рольле уеннар бигрәк тә уңышлы.

Рольле уен вакытында бер кечкенә ситуация уйнатыла, ул берничә мәртәбә һәм төрле вариантта кабатлана. Әлеге процесста укучы өчен көтелмәгән сораулар яңгыры й һәм ул уйланырга мәҗбүр була. Шуңа күрә бу вакытта сөйләм үстерелә.

Күренеп тора: рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора.

Мәсәлән, татар теле дәресендә укытучы һәм укучы булып уйнарга мөмкин. Дәреснең кызыгы нәрсәдә соң? Бу дәресне без гади традицион дип әйтә дә алабыз, ләкин укытучы ролендә гади укучы була. Мәсәлән, алмашлык темасын кабатлаганда, укытучы сораулар бирә, ә укучы мисаллар белән җавап бирергә тиеш була.

Укытучы: Укучылар, без бүген алмашлык сүз төркемен кабатлыйбыз. Дәресне башлар өчен, иң беренче искә төшерик: нәрсә соң ул алмашлык?

Укучы: Алмашлык – җөмләдә исем, сыйфат, сан, рәвеш, фигыльләрне алыштырып, алар урынында кулланыла торган сүз төркеме.

Укытучы: Алмашлыкның нинди төркемчәләрен беләбез?

Укучы: Зат, күрсәтү, билгеләү, билгесезлек, юклык, сорау алмашлыклары бар.

Укытучы: Мин сезгә хәзер алмашлыклар әйтәм – сез кайсы төркемчәгә каравын билгелисез. Алар ...

Укучы: Зат алмашлыгы.

Укытучы: Монысы ...

Укучы: Күрсәтү алмашлыгы.

Укытучы: Ничек, кайчан ...

Укучы: Сорау алмашлыгы.

Шул рәвештә дәресне дәвам итәбез. Укытучы ролендәге укучыны алдан билгеләп була, ягъни ул өйдә бераз әзерләнеп, сораулар уйлап, дәрес өчен план төзеп килсә, дәрес күпкә нәтиҗәле узачак. Әлбәттә, укытучы роленә кыюрак бала билгеләнә. Чөнки оялчан балалар куркып, югалып калырга мөмкиннәр. Ролле уеннарны башкарыр өчен, төрле ситуацияләрне алырга мөмкин. Дәреснең 5-7 минуты идеяне ачыклауга, максатны җиткереп аңлатуга, рольләрне бүлүгә, һәр кешенең вазифасын ачыклауга үтәргә мөмкин. 25 минут эчендә укучылар шул вакыйга эчендә яшиләр. Һәм дәреснең ахырында һәр укучы үзләренең сөйләмендә иң күп кулланган алмашлыкларны барлап чыгалар, анализ ясыйлар, сыйныфташларына һәм үзләренә бәя бирәләр. Иң беренче уйналачак ситуацияне план рәвешендә төзергә кирәк. Мәсәлән: 1. Ике дусның кибеткә баруы. 2. Кибеттә. 3. Кәримнең тәкъдиме.

Хәзер план буенча һәр сөйләмне карап үтик:

1. Ралия: Сәлам, Гүзәл! Ничек хәлләрең?

Гүзәл: Сәлам! Яхшы. Синеке ничек?

Ралия: Ярыйсы, эш күп. Кая барасың?

Гүзәл: Әни кибеткә җибәрде. Син?

Ралия: Мин дә.

Гүзәл: Бик яхшы. Бергә барып кайтыйк. Күңелле булыр.

Ралия: Әйтмә дә. Бүген ничәдә уяндың?

Гүзәл: Сеңлем иртәнге 8дә өстемдә сикереп йөри иде инде. Йокларга бирми.

Ралия: Әәә... Мин дә йоклый алмадым. Әни 9нчыда уятты. Кичә кич өйгә кайткач нишләдең?

Гүзәл: Яраткан сериалымны карадым. Төрек сериаллары 2 сәгать буе бара. Бигрәк озак. Карамыйча да булмый.

Ралия: Шәп төшерәләр бит алар киноны.

Гүзәл: Анысы шулай, дөрес әйтәсең.

Беренче этапны шушы урында туктатып торыйк. Ралия һәм Гүзәлнең сөйләмендәге алашлыклар барлана.

Укытучы: Кызлар сөйләмендә кайсы алмашлыклар кулланылды?

Укучылар: мин, ничек, кая, син, алар, анысы, шулай.

2. Кызлар: Исәнмесез, Мөнирә апа!

Сатучы Мөнирә: Хәерле көн кызлар!

Ралия: Мөнирә апа, миңа ипи, ак май, тоз һәм әфлисун суе бирерсез әле.

Сатучы: Ничә ипи?

Ралия: Бер акны һәм бер караны. Ак майны берәр кило булса җитәдер.

Сатучы: Яхшы. Тәәк, ике ипи, бер кило май, тоз һәм сок. Синнән 234 сум.

Ралия: Менә алыгыз. Рәхмәт!

Гүзәл: Миңа 5 туңдырма, Чаллыныкы, бер ипи һәм 300 грамм голланд сыры. Әз генә пиццага кирәк иде.

Сатучы: Яхшыы, сезгә бүген пицца ашарга киләбез икән.

Гүзәл: Әлбәттә, килегез.

Сатучы: Синнән 246 сум.

Гүзәл: менә 250 сум.

Сатучы: Яхшы, рәхмәт чакыруына.

Дәрестә анализ ясала: бу өлештә миңа, ничә, синнән, менә, миңа,сезгә, синнән, менә алмашлыклары кулланылды.

3. Кибеткә кызларның дусы Кәрим килеп керә.

Кәрим: Ооо, сәлам, кызлар!

Кызлар: Сәлам, Кәрим! Ничек хәлләрең?

Кәрим: Яхшы, сезнеке ничек?

Ралия: Шәп.

Гүзәл: Ярыйсы. Нишләп йөрисең?

Кәрим: Әни приправа артыннан җибәрде. Мөнирә апа, 2не бирерсез әле.

Сатучы: Менә сиңа приправа, тагын нәрсә?

Кәрим: 2 пачка көнбагыш.

Сатучы: Синнән 59 сум.

Кәрим: Рәхмәт. Кызлар, әйдәгез елга буена су коенырга төшәбез.

Ралия: Кайчан?

Кәрим: Хәзер. Әйберләрне өйгә алып кайтабыз да. Аннан соң барырбыз. Алсуны, Миләүшәне дә чакырыгыз. Ә мин Азат белән Ринатны чакырам.

Кызлар: Без риза.

Укытучы: Безнең Ралия, Гүзәл, Кәрим һәм сатучы Мөнирә апа үзләренең сөйләмендә нинди алмашлыклар кулландылар?

Укучы: Бу өлештә без ничек, сезнеке, нишләп, сиңа, нәрсә, синнән, кайчан, мин, без алмашлыкларын ишеттек.

Рольле уеннарны төрлечә төзеп була. Алдан әзерләнгән уен уңышлы була. Ләкин укучылар өлкән сыйныфларда үзләре дә сөйләмне төзеп, ситуацияне тудыра алалар.

Ситуация сөйләмгә этәргеч була. Мондый уеннарда укучыда фикерләүне эшкә җигү нәтиҗәсендә нәрсәдер әйтү ихтыяҗы барлыкка килә. Образлы фикерләү логик фикерләү белән бергә алып барыла. Коммуникатив уеннар телдән сөйләмне үстерү, камилләштерү өчен баланы җанлы сөйләмгә яки күмәк сөйләмгә тарту максатыннан үткәрелә. Аларны төрле формада үткәрергә мөмкин. Төркемнәргә бүленеп уйнау (әйтик, гаилә, ял итүчеләр), уен-эзләнү (җитмәгән мәгълүматны табу), уен-хыял (класс бүлмәсе офиска яки кунакханә бүлмәсенә әйләнә) шундыйлардан.

**«Чират буенча сөйләшү»**

*Импровизация*. Уенда ике бала катнаша. Һәрберсе укытучы кушуы буенча үз хикәясен сөйли. Уенның максаты – туктамыйча сөйләүне дәвам итү. Ләкин чират буенча һәрберсе бер генә җөмлә әйтә. Мәсәлән, Коля белән Миша болай сөйләшергә мөмкин. Хикәянең темасы – «Ял көне».

**Коля**. Кичә мин циркка бардым.

**Миша.** Ә мин кибеткә бардым.

**Коля.** Сәгать 10да киттем.

**Миша**. Ипи, тоз, шикәр алдым.

**Коля.** Этләр, аюлар бар иде.

**Миша.** Туңдырма да алдым.

**Коля.** Клоун да бар иде.

**Миша**. Бик тәмле булды.

**Коля.** Ул мине көлдерде.

**Миша.** Аннан мин өйгә кайттым.

**Коля.** Бик күңелле булды.

Күргәнебезчә, укучылар хикәяне уйлап чыгарганда, үзләренең сөйләмнәрендә алмашлыкларны еш кулланалар. Алар аны кабатлап, үзләренең сөйләмнәренә үзләре дә сизмичә кертеп җибәрәләр. Сөйләмдә алмашлык сүз төркеме, исем һәм фигыль кебек үк, бик кирәкле һәм алыштыргысыз җөмлә кисәге булуына тагын бер кат инандык.

### Икенче бүлек нәтиҗәләре

1. Педагогик технология – белем бирү һәм тәрбияләү процессында психологик һәм педагогик яктан нигезләнгән, системалы һәм планлаштырылган нәтиҗәләргә алып барырдай итеп кулланыла торган махсус формалар, алымнар, методлар һәм ысуллар җыелмасы. Уен технологиясе – укучылар эшчәнлеген активлаштыруга һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләрнең берсе. Татар теле дәресләрендә кулланылган уеннар балаларга ныклы белем бирергә,

тотрыклы күнекмәләр булдырырга, мөстәкыйль рәвештә танып белү эшчәнлеге белән кызыксынуларын уятырга ярдәм итәләр.

2. Татар теле дәресләрендә укучыларны башлангыч сыйныфлардан ук татар авазларын дөрес әйтергә өйрәтү – иң мөһим бурычларның берсе. Татар телен чит тел буларак өйрәнгәндә, укучылар хәрефләрне, алар белдергән авазларны аерырга, сүзләргә басымны дөрес куярга өйрәнәләр, ишетеп аңлау, ишетеп истә калдыру күнекмәләрен булдыралар. Алмашлык сүз төркемен өйрәнкәндә, укытучылар татар теле дәресләрендә түбәндәге фонетик уеннарны куллана алалар: «Дуэль», «Аут», «Авазны тап», «Биш сүз», «Сүзне уйлап тап», «Ничә аваз?», «Әйтеп бетер», «Детектив», «Сүз уйлау», «Сүзне әйт», «Нинди аваз әйтелә?», фонетик һәм лексик зарядка битләре, «Кем игътибарлырак?», «Шагыйрьнең хатасын тап», «Беренче авазны бел», тизәйткечләрдән алмашлыкларны табу һ.б.

3. Татар теле дәресләрендә укучыларның лексик сүз байлыгын арттыру өчен «Кар өеме», «Киресен әйтешле», «Йөзек салыш», «Кызык телефон», «Сүзләр тап», «Эстафета», «Югалган алмашлыкларны тап», «Кем җитез?», «Исеңдә калдыр», «Кем нәрсә турында уйлады?», «Чәчәк бәйләмнәре», «Дәфтәрләрне җыю», «Сүзләр төркемнәре», «Уңыш җыю», «Артык вагон», «Кем иң бай?», «Кәрзинне тутыр», «Сүз киресенчә», «Тылсымчы», «Кояш», «Кайсы артык», «Бу нинди сүз», «Сүзне исеңдә калдыр», «Белмәмешнең шаяруы», «Җиде таҗлы чәчәк», «Адым саен», «Иң җитез», «Кем тизрәк?» лексик уеннары ярдәм итәчәк.

4. Грамматик уен күнегүләре татар телен өйрәнү белән укучыларны мавыктыру, сыйныфта грамматика дәресләрен җанлы, кызыклы итү, балаларның дөрес сөйләү һәм язу күнекмәләрен аңлап һәм җиңел үзләштерү булдыру теләгеннән чыгып эшләнде: «Җөмлә төзе», «Нәрсә үзгәрде?», «Яшел светофор», «Җиләк җыю», «Ромашка», «Кем тапкыррак?», «Гөмбә җыю», «Алма жыю», «Сорауларга җавап бирәбез», «Татар телен яхшы беләсезме?», «Үзеңнең урыныңны тап», «Хатаны тап», «Поезд»,

«Тылсымчы», «Ышанам-ышанмыйм», «Серле тартма», «Кемнең хәтере яхшы?», «Танышу», «Шәвәли», «Яраткан әкият геройларыңны таны», «Кем син», «Журналист», «Тәрҗемәче», «Татар телен яратучылар»клубы утырышы, «Нәрсә кайда?» һ.б.

5. Татар телен өйрәткәндә, рольле уеннар аеруча актив кулланыла. Бу уеннарның өйрәтү мөмкинлекләре зур, һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар алар белән иркен эш итәләр. Бу вакытта катнашучылар бер-берсенә йогынты ясыйлар. Аларда нәрсәдер әйтү, сорау ихтыяҗы туа. Рольле уеннар дәресне җанландыра һәм уңай нәтиҗәләргә генә китерә.

# ЙОМГАК

Әлеге диссертация эшендә максат буларак, татар телен укытуда алмашлыкларны өйрәтүнең лингводидактик нигезләрен ачыклау һәм аларны уен технологияләре белән бәйләп өйрәтү алымнарын билгеләү куелды. Мәктәптә алмашлыкларны өйрәткәндә, укучыларда телдән һәм язма сөйләмдә аларны яңа технологияләр кулланып, ныклы белем һәм күнекмәләр формалаштыру төп мәсьәләләрдән берсе булып тора.

Алмашлыкларны өйрәнүгә куелган максатларны тормышка ашыру өчен түбәндәге эшләр башкарылды һәм нәтиҗәләр ясалды:

1. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башыннан алып, бүгенге көнгә кадәр булган хезмәтләргә анализ ясалды, фәнни хезмәтләрдә алмашлыкларның өйрәнелү дәрәҗәсе тикшерелде; алмашлыкларны өйрәнүнең лингводидактик үзенчәлекләре ачыкланды (А.Казембек, К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Г.Алпаров, В.Н.Хангилдин, З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, Д. Г. Тумашева, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый , Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Л.Җәләй, Г.Нугайбәк, Ч. М. Харисова, Ф. С. Сафиуллина, Д. Г. Тумашева, З. М. Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, В. Н. Хангилдин, Ф. М. Хисамова һ.б.). Алмашлык сүз төркемен өйрәнү тарихы буенча хезмәтләр аны билгеле бер системага салып анализлау мөмкинлеге бирә;

2. Рус мәктәпләре өчен чыккан программалар һәм дәреслекләрдә алмашлыкларның бирелеше өйрәнелде (Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева, Г. М. Әхмәтҗанова, З. Р. Нәҗипова, Р. Л. Малафеева; К. С. Фәтхуллова; Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова; Ф. С. Сафиуллина; И. Л. Литвинов, Э. Р. Садыйкова, Л. И. Гарипова; В. Н. Мещерякова, Р. Р. Нигъматуллина, Ф. С. Фәизова). Рус мәктәпләре өчен чыккан дәреслекләр һәм программаларга ясалган анализны истә тоту мәктәптә алмашлыкларны билгеле бер системага салып өйрәнү мөмкинлекләре бирә;

3. Яңа педагогик технологияләрнең берсе буларак, уен технологиясе тикшерелде (Уен технологиясе – укучылар эшчәнлеген активлаштыруга һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләрнең берсе). Уен технологиясен яңа педагогик технологияләрнең берсе буларак таныргa һәм актив кулланырга мөмкин;

4. Алмашлыкларны өйрәтү вакытында укучыларның эшчәнлеге заманча уен технологиясенә нигезләнде (фонетик, лексик, грамматик, рольле уеннар). Татар теле дәресләрендә алмашлыкларны өйрәткәндә яңа педагогик технология буларак, уен технологиясен куллану уңышлы.

Укучыларны сөйләмә һәм язма телгә нигезләп, алмашлыкларны дөрес язарга, сөйләмдә иркен кулланырга, аларны кертеп, диалоглар, монологлар, хикәяләр төзергә, матур әдәбият үрнәкләре, халык авыз иҗаты әсәрләреннән өзекләр, табышмаклар, үстерелешле күнегүләр укучыларның фикер йөртү сәләтен үстерә. Татар теле дәресләрендә укучыларга алмашлык сүз төркемен өйрәткәндә фонетик уеннардан «Дуэль», «Аут», «Авазны тап», «Биш сүз», «Сүзне уйлап тап», «Ничә аваз?», «Әйтеп бетер», «Детектив», «Сүз уйлау», «Сүзне әйт», «Нинди аваз әйтелә?», фонетик һәм лексик зарядка битләре, «Кем игътибарлырак?», «Шагыйрьнең хатасын тап», «Беренче авазны бел»; лексик уеннардан «Кар өеме», «Киресен әйтешле», «Йөзек салыш», «Кызык телефон», «Сүзләр тап», «Эстафета», «Югалган алмашлыкларны тап», «Кем җитез?», «Исеңдә калдыр», «Кем нәрсә турында уйлады?», «Чәчәк бәйләмнәре», «Дәфтәрләрне җыю», «Сүзләр төркемнәре», «Уңыш җыю», «Артык вагон», «Кем иң бай?», «Кәрзинне тутыр», «Сүз киресенчә», «Тылсымчы», «Кояш», «Кайсы артык», «Бу нинди сүз», «Сүзне исеңдә калдыр», «Белмәмешнең шаяруы», «Җиде таҗлы чәчәк», «Адым саен», «Иң җитез», «Кем тизрәк?»; грамматик уеннардан «Җөмлә төзе», «Нәрсә үзгәрде?», «Яшел светофор», «Җиләк җыю», «Ромашка», «Кем тапкыррак?», «Гөмбә җыю», «Алма җыю», «Сорауларга җавап бирәбез», «Татар телен яхшы беләсезме?», «Үзеңнең урыныңны тап», «Хатаны тап», «Поезд»,

«Тылсымчы», «Ышанам-ышанмыйм», «Серле тартма», «Кемнең хәтере яхшы?», «Танышу», «Шәвәли», «Яраткан әкият геройларыңны таны», «Кем син», «Журналист», «Тәрҗемәче», «Татар телен яратучылар»клубы утырышы, «Нәрсә кайда?», рольле уеннар кулланырга тәкъдим итәм.

Мәктәптә алмашлыкларны өйрәтү укытучыдан зур игътибар һәм хезмәт сорый. Алмашлыкның төп билгеләмәсеннән тыш, укучыларга аның грамматик төркемчәләрен (исем, сыйфат, сан, фигыль, рәвеш алмашлыклары), мәгънә төркемчәләрен (зат, күрсәтү, сорау, билгеләү, юклык, билгесезлек, тартым алмашлыклары), алмашлыкларның башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәтен, җөмләдәге ролен аңлатырга кирәк.

## Кулланылган әдәбият исемлеге

### Татар телендә


1. Айдарова С.Х. К знаниям через игру: Методические разработки для учителей нач. классов, обучающих русскоязычных детей татар. языку/ С.Х.Айдарова. – Казань, 1998. – 115с.

2. Айдарова С.Х. Дидактические условия дифференциации упражнений в прцессе обучения русскоязычных учащихся татарскому языку: Дис. канд. пед. наук/ С.Х.Айдарова. – Казань, 2006. – 250с.

3. Айдарова С.Х. Упражнения по татарскому языку для русскоязычных учащихся (1-3 классы)/ С.Х.Айдарова. – Казань: ТГГИ, 2002. – 36с.

4. Айдарова С.Х. Игры на уроках татарского языка: Методическое пособие/ С.Х.Айдарова. – Казань: Gumanitarya, 2004. – 20с.

5. Алпаров Г. Шәкли нигездә татар грамматикасы / Г. Алпаров - Казан, 1945.

6. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре/ А.Ш.Әсәдуллин, Р.А.Юсупов. – Казан: Мәгариф, 1998. – 151б.

7. Вафин Ф. «Тел өйрәтүдә коммуникатив уеннар». «Мәгариф» , №11, 2008, 28-30нчы битләр.

8. Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы / Җ.Вәлиди. - Казан, 1919.

9. Вәлидов Җ. Җ. Сайланма хезмәтләр / Җамал Вәлиди. – Казан : Мәгариф, 2007. – 271 б.

10. Вәлиева Ф.С., Саттарова Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы/ Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттарова. – Казан: Раннур, 2000. – 455 б.

11. Вәлиуллина З. М., Зиннәтуллина, Сәгыйтов М. А. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе: студентлар һәм укытучылар өчен / З. М.

Вәлиуллина, К. З. Зиннәтуллина, М. А. Сәгыйтов : Казан дәүләт педагогия институты. – Казан, 1972. – 206 б.

12. Волкова Р., Гарәфетдинова Р. Башлангыч мәктәптә татар телен чит тел буларак өйрәтүдә уен алымнарын һәм методларын куллану. – Казан: Мәгариф, 2014. – 128 б.

13. Гайфуллин В. Педагогик технологияләр // Мәгариф, 2000. – №4. – 7-10б.

14. Галиуллина Г. Р., Шәкүрова М. М. Телләргә өйрәтү методикасын камилләштерү: алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу мәйданчыгы: Халыкара фәнни-методик онлайн семинар материаллары (Казан – Астана – Измир, 2017 елның 22 феврале) – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. – С. 168-172.

15. Галиуллина Г.Р., Шакурова М.М. Татар телен укытуның яңа концепциясе // Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе / Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. - Казан: КДАТУ, 2017. - Б. 109-114

16. Галиуллина Г. Р., Шәкүрова М. М. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 нче сыйныфлар / (басма өчен Г.Р. Галиуллина Д.Ф. Заһидуллина җаваплы - Казан: Татар. кит. нәшр., 2011 - Б 85-121

17. Гыйбад Алпаров. Сайланма хезмәтләр (татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). – Казан : Татгосиздат, 1945.

18. Җәләй Л. Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар) / Л. Җәләй; Татарстан фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. – Казан : Фикер, 2000. – 288 б.

19. Зәкиев М.З. Туган телне укытуның кайбер гомуми дидактик принциплары һәм методлары / М.З.Зәкиев. — Кит.: Татар телен укыту мәсьәләләре . — Казан, 1975. — Б. 6-32

20. Литвинов И.Л. Татарский язык в русской школе: Методические разработки уроков для 1 класса (русскоязычные группы)/ И.Л.Литвинов. – Казань: КАРПОЛ, 1994. – 76с.

21. Литвинов И. Л. Татар теле: Рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәкт. 3 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / И. Л. Литвинов, Э. Р. Садыйкова, Л. И. Гарипова. – Казан: Мәгариф, 2004. – 142 б.: рәс б-н.

22. Мияссарова И.Х. Азрак ял итеп алыйк: Физкультминутлар, сүзле-хәрәкәтле уеннар (Башлангыч мәктәп, татар теле укытучылары, тәрбиячеләр һәм студентлар өчен кулланма)/ И.Х.Мияссарова. – Казан, 1998. – 60б.

23. Насыйри К. Әнмүзәҗ / К.Насыйри. - Казань, 1895.

24. Нуриева А. Х. Татар теле тарихыннан материаллар: лексикология, морфология / А. Х. Нуриева; В. И. Ульянв-Ленин исемендәге Хәзмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан дәүләт университеты. – Казан, 1975.

25. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары (1 – 11 нче сыйныфлар). – Казан : Мәгариф, 2003. – 120 б.

26. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту программасы: 5-9 сыйныфлар .-Казан: Мәгариф, 1993. – 45 б.

27. 5. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары: 1–11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2003. – 127 б.

28. Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле : Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек / Ф. С. Сафиуллина, М. З. Зәкиев. – 3 нче басма. – Казан : Мәгариф, 2006. – 407 б.

29. Сафиуллина Ф.С. Татар телен өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре/ Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2001. – 432б.

30. Сафиуллина Ф. С. Татар теле: Рус урта гомуми белем мәкт. 7 нче сыйныфы өчен дәреслек (Рус телендә сөйләшүче балалар өчен). – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2001. – 311 б.

31. Татар грамматикасы. – Т. II. – М.: «ИНСАН», Казань: «Фикер», 2002. – 448 б.

32. Татар теле: Татар урта гомуми белем мәкт. 6 нчы с-фы өчен д-лек /Д.Г.Тумашева, Ф.Ю.Юсупов, К.З.Зиннәтуллина, Б.М.Мифтахов, К.З.Зиннәтуллина редакциясендә.-Казан: Мәгариф, 2001. - 290 б.

33. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 нче сыйныфлар / (басма өчен Г.Р. Галиуллина, Д.Ф. Заһидуллина җаваплы - Казан: Татар. кит. нәшр., 2011 - 268 б.

34. Татарстан халыкларының телләре турында Закон // Ватаным Татарстан. — 1992. — 25 июль

35. Тумашева Д. Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология / Д. Г. Тумашева ; СССР Югары һәм махсус урта белем министрлыгы тарафыннан югары уку йорты өчен дәреслек-кулланма буларак рөхсәт ителә. – Казан: Казан университеты нәшрияте, 1978. – 222 б.

36. Тумашева Д.Г., Вәлиуллина З.М., Фасеев Ф.С. Татар теле. Морфология. 5 класс өчен дәреслек. 9 нчы басма / Д.Г.Тумашева һ.б. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.– 207 б.

37. Хангильдин В. Н. Татар теле грамматикасы (морфология һәм синтаксис) / В. Н. Хангильдин. – Казан : Татарстан китап нәшрияты, 1959. – 642 б.

38. Харисова Ч. М. Татар теле. Морфология: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2010. – 128 б.

39. Харисова Ч. М. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясеннән лекцияләр. – Казан : ТДГПУ, 2006. – 148 б.

40. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К.Нотфуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367б.

41. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. – 302б.

42. Харисов Ф.Ф. Заманча белем бирү технологияләре/ Харисов Ф.Ф.- Казан, 2005. – 62 б.

43. Харисов Ф.Ф., Ф.М.Хисамова, Харисова Ч.М. Татар теле: рус телендә башл. Гомуми белем бирү мәкт. 3 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) / Ф.Ф.Харисов, Ф.М.Хисамова, Ч.М.Харисова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.

44. Харисов Ф. Ф. Татар теле: Рус урта гомуми белем мәкт. 5 нче с-фында укучы татар балалары өчен дәреслек / Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова, З. М. Маханова. – Тулыл. икенче басма. – Казан: Мәгариф, 1998. – 143 б.

45. Харисов Ф. Ф. Татар теле : Рус телендә белем бирүче дүртьеллык башл. мәкт. 3 нче с-фы өчен дәреслек (татар балалары өчен) / Ф. Ф. Харисов, Ф. М. Хисамова, Ч. М. Харисова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан : Мәгариф, 2009. – 150 б.

46. Хәйдәрова Р.З. «Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту». – Яр Чаллы, 2015.

47. Р.З.Хәйдәрова, Н.Г.Галиева Күңелле татар теле: дүртьеллык башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1нче сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби уку дәреслеге( рус телендә сөйләшүче балалар өчен). – Казан ” Татармультфильм”нәшрияты, 2012– 100 б.

48. Фәтхуллова К.С., Денмөхәммәтова Э.Н. Тел дән сөйләмгә өйрәтү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 87 б.

49. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз. Р.Б.Камаева, А.Х.Мөхәммәтҗанова – Казан: ТРМҮИ, 2015 – 110 б.

50. Хисамова Ф. М. Татар теле морфологиясе : Югары уку йортлары өчен дәреслек / Ф. М. Хисамова. – Казан : Мәгариф, 2006. – 335 б.

51. Хисамова Ф.М., Борһанова Р.А. Татар теле өйрәнә нәниләр/ Ф.М.Хисамова, Р.А.Борһанова. – Казан: Мәгариф, 1994. – 79б.

52. Шәкүрова М.М. Татар мәктәпләрендә татар телен укыту методикасы/ Лекцияләрнең кыскача конспекты. – Казан, 2014.

53. 2014-2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр/ төз. Д. Ш. Гыйльманов. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2014. – 52 б.

**Рус телендә**

54. Аникеева Н.П. «Воспитание игрой.» Книга для учителя – М.: Просвещение, 2007.

55. Абасова З.А. Познавательная активность школьников.-/Советская педагогики № 7, 1999.

56. Абрамова Г. С., Степанович В. А. Деловые игры: теория и организация.

Екатеринбург: Деловая книга, 1999.

57. Беспалько В.П. Слагаемые педагогическойтехнологии. —1989, С. 136

58. Валиуллина З.М. Сопоставительная грамматика русского и татарского языков: Словообразование и морфология / З.М.Валиуллина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – 152 с.

59. Волков И.П. Много ли в школе талантов? / И.П. Волков. - М.: Знание, 1989. - 42 с.

60. Гайнуллина Г.Ф., Гиниятуллина Л.М., Татар теле дәресләрендә аралашуга өйрәтү технологиясе (1 нче сыйныф өчен күнегүләр системасы). - Мәгариф. Татар теле. - 2017. - №4.

61. Гайнуллина Г. Ф., Харисова Г. Ф., Зиннуров М. К., Хөснетдинов Д. Х. Татар теле. 8 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Ф.Гайнуллина, Г.Ф.Харисова, М.К.Зиннуров, Д.Х.Хөснетдинов. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. - 182 б.

62. Галиуллина Г. Р., Шакурова М. М. Примерная рабочая программа учебного предмета «Родной (татарский) язык» для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке (5-11 классы) // http://fgosreestr.ru/wp-content/uploads/2017/08/Rodnoi-tatarskii-yazyk-dlya-obshheobrazovatelnyh-organizatsii-s-obucheniem-na-tatarskom-yazyke-5-11-klassy-1.pdf

63. Галиуллина Г. Р., Хисамова Ф. М., Анварова М. Х., Гафурова А. А. Морфология современного татарского языка: учебно-методическое пособие / Ф.М. Хисамова, Г.Р. Галиуллина, М.Х. Анварова, А.А. Гафурова. - Казань: Казанский университет, 2010. - 127 с.

64. Казембек А. Общая грамматика турецко-татарского языка / А.Казембек, 1846.

65. Кузьмина Х. Х. Телләргә өйрәтү методикасын камилләштерү: алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу мәйданчыгы: II Халыкара фәнни-методик онлайн конференция материаллары (Казан – Астана – Измир, 2018 елның 20 феврале) – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. – Б. 383-387.

66. Кузьмина Х. Х., Галиуллина Г. Р., Хадиева Г. К. Хәзерге татар теле: фонетика, орфоэпия. http://do.kpfu.ru/course/view.php?id=3018

67. Лихачев Б.Т. Методологические основы педагогики / Б.Т. Лихачев. - Самара, 1998. - 141 с.

68. Троянский А. Краткая татарская грамматика / А. Троянский. - СПБ, 1814.

69. Чошанов М.А. Гибкая технология проблемно-модульного обучения: Методическое пособие – М.: Народное образование, 1996. – 160 с.

70. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному/ Под ред. проф. Л.З.Шакировой. – Спб.: филиал изд-ва «Просвещение», 2001. – 431с.

71. Шакурова М.М. Художественный текст в поликультурном пространстве // Современные проблемы филологии и методики преподавания языков: вопросы теории и практики: Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 50-летию факультета иностранных языков ЕИ К(П)ФУ (23 октября 2015 г.): Сборник научных трудов. – Елабуга: Изд-во Елабужского института Казанского федерального университета, 2015. – С. 252-254

## Интернет-ресурслар

1. https://dspace.kpfu.ru/xmlui/handle/net/109404

2. Электронное образование в Республике Татарстан edu.tatar.ru

3. https://kopilkaurokov.ru/prochee/prochee/tatar-tielie-d-riesl-riend-ghrammatik-uiennar

4. https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2013/08/31/tatar-tele-dreslrend-uennar

5. https://infourok.ru/ukitu-rus-telend-alip-barilgan-mktplrd-tatar-telen-yrngnd-uen-alimnari-1381106.html

6. https://edu.tatar.ru/upload/images/files/22(23).pdf

7. https://filiza-aglyamova5.jimdo.com/балачак-иң-күңелле-чак/үстерешле-уеннар/

8. https://nsportal.ru/nachalnaya-shkola/russkii-yazyk/2013/11/29/didakticheskie-igry-na-urokakh-russkogo-yazyka-iz-opyta

## Кушымта

Төрле авторларның дәреслекләрендә алмашлык сүз төркеменең бирелешен һәм күнегүләрен фотосурәтләрдә китерәм. Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М., Маханова З. М. төзегән рус урта гомуми белем бирү мәктәпләре 5 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслектәге күнегүләр:

### ЗАТ АЛМАШЛЫКЛАРЫ

**51.** Бирелгән җөмләләрдә алмашлыкларны табыгыз. Алар нинди сүзләрне алыштырып киләләр?

Камил мәктәпкә китте. Ул бишенче сыйныфта укый. Әлфия, Рөстәм һәм Фәрит Фатих Әмирхан урамында яшиләр. Алар җиденче гимназиядә укыйлар. Ә сез кайсы мәктәптә укыйсыз?

**52.** Нокталар урынына тиешле зат алмашлыкларын куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1. ... әкиятләр укырга яратам. 2. ... бу чирекне яхшы тәмамлады. 3. ... нинди китаплар укырга яратасың? 4. ... иртәгә китәбез, ... калалар. 5. Ә ... кайчан китәсез? 6. ... алмагачлар утырткан идек. ... быел беренче тапкыр уңыш бирделәр.

* Җөмләләрне русчага тәрҗемә итегез.

**53.** Шигырьне укыгыз. Зат алмашлыкларын табып, аларга сораулар куегыз.

**Гел янәшә...**

Әнием бер атлаганны
Мин вак-вак биш атладым.
Ул елмаеп карый килде:
— И балакай, синең адым...
Инде хәзер киресенчә —
Мин эре атлый башладым.
Әнием сокланып бара:
— И балакай, синең адым!
Әни мине калдырмады,
Мин әнине ташламамын,
Эреле-ваклы булса да,
Гел янәшә безнең адым!

*Шәүкәт Галиев.*

**209.** Рәсемнәрне карагыз. Зат алмашлыкларын әйтеп чыгыгыз




**211.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Син кем?
2. Синең исемең ничек?
3. Сиңа ничә яшь?
4. Син нинди китаплар укырга яратасың?
5. Синең нинди хыялларың бар?

* Җавап биргәндә, ничәнче зат алмашлыгын кулландыгыз? Җавапларыгызга III зат алмашлыгын да куеп карагыз.

**212.** Укыгыз да табышмакларның җавапларын әйтегез. Алмашлыкларны күрсәтегез.

1. Сырлы, сырлы, сырлы ул,
   Безнең белән җырлый ул,
   Биетә дә җырлата,
   Күңелле ул, моңлы ул.
2. Ул үзе шундый көчле,
   Тешле-тешле чүмечле.
   Берүзе эшли ала
   Җитмеш кешелек эшне.
3. Син туктасаң — туктый,
   Син барсаң — бара.
   Ул нәрсә?
   Я, уйлап кара!

**213.** Ребусны чишегез.




**216.** Әти-әниегезгә, иптәшегезгә яки укытучыгызга котлау хаты языгыз. Зат алмашлыкларын төрле килештә кулланыгыз.

Үрнәк:

*Хөрмәтле Зөһрә апа! Сезне туган көнегез белән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, эшегездә зур уңышлар, шатлык телибез.*

*Сезнен укучыларыгыз.*
*17 нче март, 1994 нче ел.*

* Алмашлыкларның килешләрен күрсәтегез. Ни өчен аерым кешегә карата *Сез* алмашлыгын кулландыгыз?

*Сәламәтлек, эшегездә, шатлык* сүзләренең тамыр һәм кушымчаларын билгеләгез.

**222.** Укыгыз. *-ныкы, -неке* кушымчалары нинди сүзләргә ялганган? Ул сүзләр җөмләнең кайсы урынында килгән?

1. Бу мәктәп безнеке. 2. Теге уенчык синеке. 3. Китап Әлфиянеке, ә карандаш Булатныкы. 4. Күлмәк минеке. 5. Сәгать әтинеке. 6. Бу яулык әбинеке, ә түбәтәй бабайныкы. 7. Чана Рамилнеке, чаңгы Азатныкы.

И. Л. Литвинов, Э. Р. Садыйкова, Л. И. Гарипова төзегән рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәбе 3 нче сыйныфы өчен дәреслектәге күнегүләр (рус телендә сөйләшүче балалар өчен):

**1.** Татарча әйт.

Поздравь! Он поздравляет. Он не поздравляет.
Отдыхай! Он отдыхает. Он не отдыхает.
Помоги! Он помогает. Он не помогает.
Подари! Он дарит. Он не дарит.



**2.** Исеңә төшер.

приди Он идет. пришел
Бар! Ул барды.
узнай Он узнал
Бел! Ул белде.

Мин барды́м (белде́м).
Син барды́ң (белде́ң).
Ул барды́ (белде́).

Без барды́к (белде́к).
Сез барды́гыз (белде́гез).
Алар бардыла́р (белделә́р).

**3.** Татарча әйт.

Мы радовались. Вы начали. Я пожелал. Ты приготовил. Они угощали. Она подарила. Вы проснулись. Мы кормили.

**2.** Тәрҗемә ит.

Синнән, безгә, минем, аңа, сездә, сиңа, аннан, миңа, синдә, безне, аларга, миннән, сезне, бездән.

**3.** Татарча әйт.

Он меня испугался. Я подарил им цветы. Мне нужны чистые тетради. Учитель задал ему вопрос. Мы её не понимаем. У него много времени. Возьми у неё.

**4.** Җөмләләрне дөрес укы.

Бүге́н укытучы́ апа́ (мин) бишле́ куйды́. Без (ул) сәга́ть 7 дә генә́ килде́к. Мин (ала́р) белә́н уйна́мыйм. Ала́р (ул) тата́рча сорадыла́рмы? Дуслары́м (без) хат яза́лар.

**6.** Укы һәм тәрҗемә ит.

Без а́чмадык, ала́р әзерлә́мәделәр, ул ише́тмәде, сез ә́йтмәдегез, мин аңла́мадым, сез куры́кмадыгыз, син күрсә́тмәдең, без я́пмадык.

**7.** Үрнәк буенча әйт.

Үрнәк: *Мин киендé м. — Мин киéнмәдем.*

Без рәсем ясадык. — ... Сез күрдегез. — ... Син сөйләштең. — ... Ул йөрде. — ... Сез ошадыгыз. — ...

**8.** Татарча әйт.



Я читал. — Я не читал.
Вы умылись. — Вы не умылись.
Ты сшил. — Ты не сшил.
Мы выросли. — Мы не выросли.
Вы почистили. — Вы не почистили.
Мы кашляли. — Мы не кашляли.
Они поздравили. — Они не поздравили.

**2.** Өйрән.

**Ке́мнеке?** — Чей, чья, чьё?
Күзле́к **ке́мнеке?** — Әби**неке́**.
Чыная́к **ке́мнеке?** — Бабай**нықы́**.

**3.** Үрнәк буенча әйт.

Үрнәк: *мала́й — малайныкы́.*
а) курчак, китапханә, сатучы, биюче, кунак, бакчачы;
ә) алар, мин, без, сез, ул, син.

Ф. Ф. Харисов, Ф. М. Хисамова, Ч. М. Харисова төзегән рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпләре 3 нче сыйныфы өчен дәреслектә күнегүләр (татар балалары өчен):

**200.** Шигырьне укыгыз. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең нинди сүз төркеменә керүен әйтегез.

**Сыерчыктан хәбәр килгән.**

Сыерчыктан Вилгә
Телеграмма килгән.
— **Сезгә** кунак булып
Киләм,— дигән,— тиздән.

Шунда тудым **мин** дә
**Син** ясаган өйдә.
Әллә шуңар инде,
Бик барасым килә.

Бик сагындым **сезне**,
Якты йөзегезне.
Каршы аласыз шул
Бик яратып **безне**.

*(Бари Рәхмәт.)*

**201.** Укыгыз. Зат алмашлыкларын табыгыз. Алар ничәнче зат алмашлыклары, шуны әйтегез.

Кыш көне мин Рәшитне очраттым. Аның аягында бик матур чаңгы, кулында камыш таяклар иде.

— Бу — спортчылар чаңгысы, бик беләсең килсә! — дип мактанды ул.— Абыем бүләк итте. Шомалыгын күр син аның! — Һәм ул, кош кебек очып, таудан төшеп китте.

Яз көне мин Рәшитнең өенә бардым. Теге матур чаңгылар өй артында балчыкта ята. Камыш таякның берсе бөтенләй күренми.

— Нигә алып куймыйсың, әрәм булалар бит...— дидем мин, гаҗәпләнеп.

— Хәзер миңа чаңгы кирәкми. Велосипед вакыты җитә. Тик чылбыры тутыккан әле,— дип сөйләнде Рәшит.

*(Хәләф Гарданов.)*

Сез Рәшиткә нинди киңәш бирер идегез?

**202.** Күп нокталар урынына тиешле алмашлыкларны языгыз.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *мин* | *без* |
| II зат | ... | ... |
| III зат | ... | ... |

**203.** Калын хәрефләр белән бирелгән алмашлыкларны языгыз. Аларга сораулар куегыз.

— **Сиңа** ничә яшь?
— **Миңа** тугыз яшь, ә **сиңа**?
— **Миңа** ун яшь.

**204.** Укыгыз. Килешләр белән төрләнгән алмашлыкларны табыгыз.

1. Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын
Оя итте минем сөйгән карлыгачым.

(*Габдулла Тукай.*)

2. Һәр иртә сандугач
Чишмәдә коена.
Бу аңа чиксез зур
Дан булып тоела.

(*Муса Җәлил.*)

3. Хөрмәтле укытучы апа! Без Сезне 8 нче Март бәйрәме белән тәбрик итәбез.

**205.** Алмашлыкларның кулланылышын исегездә калдырыгыз.

Кемгә әйтергә? — Миңа / Сиңа / Аңа (аңар, аңарга) — әйтергә.

Кемне чакыралар? — Мине / Сине / Аны — чакыралар.

Кемнән сорадылар? — Миннән / Синнән / Аннан (аңардан) — сорадылар.

Билет кемдә? — Миндә. / Синдә. / Анда (аңарда).

9

**206.** Күп ноктала урынына тиешле алмашлыкларны куеп языгыз.

| **кем?** | **кемнең китабы?** | **кемгә?** |
|---|---|---|
| *мин* | *минем китабым* | *миңа* |
| син | ... китабың | ... |
| ул | ... китабы | ... |
| без | ... китабыбыз | ... |
| сез | ... китабыгыз | ... |
| алар | ... китаплары | ... |

| **кемне?** | **кемнән?** | **кемдә?** |
|---|---|---|
| *мине* | *миннән* | *миндә* |
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |

Төрле килештә килгән алмашлыклар белән җөмләләр уйлап языгыз.

**207.** Укыгыз. Алмашлыкларны табыгыз.

1. Безнең илләр — ямьле җирләр,
Бездә үсә ал гөлләр.

(*Җыр.*)

2. Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең
таңында мин,
И Казан арты, сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

(*Габдулла Тукай.*)

Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова төзегән рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен 4 нче сыйныф дәреслеге (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен):

**65.** Шигырьне сәнгатьле итеп укы.

## Бораў

Сорамадым соравын,
Алдым бабай боравын.
Нинди файда эшләсе?
Кайда, нәрсә тишәсе?
Җиләс һава керсен дип,
Өф-өф итеп өрсен дип,

Тишеп чыктым бишекне,
Тәрәзне һәм ишекне.
Бораўны борам, борам,
Борам, остара барам!
Боравымны кулдан алып,
Колакны борды бабам!

*Шәүкәт Галиев*

**бораў** — сверло
**тишәсе** — просверлить
**җиләс** — свежий
**өрсен** — пусть подует
**бишек** — люлька, колыбыль
**борам** — верчу
**колакны борды** — дёрнул за ухо

Сорау алмашлыклары булган җөмләләрне күрсәт. Анда нинди тыныш билгесе куелган? Ни өчен?
Шигырьне ятла.
Алмашлыклар нинди максат белән кулланыла?
Зат һәм сорау алмашлыкларын әйт.

**66.** Нокталар урынына зат һәм сорау алмашлыкларын куеп күчереп яз.

1. ... сәяхәтчеләр турында укырга яратам. 2. Ә ... ... китапла укыйсың? 3. Иртәгә ... походка китәбез. 4. ... ... барасыз? 5. ... бик матур рәсем ясады. 6. ... ... төсләр сайлаган?

Җөмләләрне русчага тәрҗемә итеп әйт.

...ШЛЫКЛАР

### Тартым алмашлыклары

**186.** Укы. Исемнәр нәрсә белән төрләнгән?

Дәү әнием

Әниемнең әнисе
Әбием була минем,
Әби генә түгел әле,
Ул минем дәү әнием.

*Әминә Бикчәнтәева*

* * *

Ал чәчәкле илебез,
Гөл чәчәкле илебез.
Җир шарында кояш булып
Балкый безнең илебез.

*Халык җыры*

*Дәү әнием, әниемнең, әнисе, әбием, илебез, шарында* сүзләрендә *-ем, -се, -ебез, -ы* кушымчалары нәрсәне белдерә?

**188.** Сүзтезмәләрне тартым алмашлыклары ярдәмендә үзгәртеп яз. Берничәсе белән җөмлә төзеп әйт.

минем тубым, синең иптәшләрең, аның дәфтәре, безнең бүлмәбез, сезнең киемегез, аларның фатиры

Үрнәк: *минем тубым — туп минеке, ...*

**189.** Укы. *-ныкы, -неке* кушымчалары нинди сүзләргә ялганган? Ул сүзләр җөмләнең кайсы урынында килгән?

1. Бу мәктәп безнеке. 2. Теге уенчык синеке. 3. Китап Әлфиянеке, ә карандаш Булатныкы. 4. Күлмәк минеке. 5. Сәгать әтинеке. 6. Бу яулык әбинеке, ә түбәтәй бабайныкы. 7. Чана Рамилнеке, чаңгы Азатныкы.

**192.** Сәнгатьле итеп укы. Тартым алмашлыкларын күрсәт.

### Синеке — Илнеке

Бу таулар да синеке!
Елгалар да, таллар да,
Кышкы ап-ак бураннар да,
Җәйге алсу таңнар да...
Күргән, ишеткән, тойган
Һәммә нәрсә синеке!
Син үзең соң кемнеке?
Ә син — туган җирнеке.
Сөенечләр китерсәң дә,
Көенечләр китерсәң дә
Барысы газиз Илнеке!

*Равил Фәйзуллин*

**тойган** — ощущавший
**көенеч** — горе
**газиз** — дорогой

Исемнәрнең күплек сан кушымчаларын күрсәт.
Сыйфатларны табып, дәрәҗәләрен әйт.

**195.** Сүзтезмәләрне укы. Русчага тәрҗемә итеп, үрнәктәгечә яз.

бу йорт, теге урам, шул тәрәзә, бу укучылар, теге кыз, шул кешеләр, теге малай, шул китап, бу мәктәп, теге агач, бу күлмәк

Үрнәк: *бу йорт — этот дом, ...*

Русча сүзтезмәләрдә алмашлыкларның кушымчалары үзгәрдеме? Ә татар телендә ничек? Нәтиҗә ясa.

Үзең сайлаган дүрт сүзтезмә белән җөмлә төзеп яз.

**197.** Укы.

## Михаил Ломоносов

Бу исем бик күпләргә таныш. М. В. Ломоносов крестьян гаиләсендә туа. Ул кечкенәдән укырга өйрәнә. Аның укуын дәвам итәсе килә. Шул максат белән, йөкчеләргә ияреп, Мәскәүгә килә.

Белем алу өчен, зур хезмәт куеп, Ломоносов галим булып танылa. Әнә шул хезмәт аны химик һәм шагыйрь, физик һәм рәссам, астроном һәм металлург, географ һәм тарихчы, мәгърифәтче һәм дәүләт эшлеклесе итеп таныта.

*«Кем ул? Нәрсә ул?» китабыннан*

**таныш** — знаком
**максат** — цель
**йөкчеләр** — извозчики
**мәгърифәтче** — просветитель
**таныта** — показал себя

Күрсәтү алмашлыкларын файдаланып, хикәянең эчтәлеген сөйлә.

Фәннең төрле өлкәләрендә танылган галимнәрдән кемнәрне беләсең?

Ф. С. Сафиуллина, К. С. Фәтхуллова төзегән рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч 3 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен):

**3.** Укыйбыз һәм тәрҗемә итәбез.

Без ... сыйныфта укыйбыз. Безнең сыйныфта ... укучы бар. Бүген ... сентябрь. Бүген ... бәйрәме. Без ... барабыз. Укытучы безне ... һәм бәйрәм белән ... . Без аңа чәчәкләр ... .

**4.** Җавап бирәбез.

Ни́чә кыз бар? (19)
Ни́чә малай бар? (13)
Бу ни́чәнче мәктәп? (122)
Бу ни́чәнче сыйныф? (3)
Ни́чә көн бар? (7)
Ни́чә ай бар? (12)
Сәгать ни́чә? (6)
Сәгать ни́чәнче? (8)

**5.** Җөмләләр төзибез.

Мәктәптә, ул, укый, тугызынчы. Язалар, алар, сөйләшәләр, дәрестә, татарча, һәм. Яратабыз, мәктәпне, без, бик. Сентябрь, бик, бәйрәм, күңелле, беренче.

**8.** Җөмләләрне дәвам итәбез.

Без өченче сыйныфта ... . Без рус теле, татар теле, инглиз теле ... . Дәресләрдә без күнегүләр ... .

**9.** Җавап бирәбез.

Нә́рсә? Мәктәп. Нә́рсәнең? Мәктәп... . Ка́я? Мәктәп... . Нә́рсәне? Мәктәп... . Ка́йдан? Мәктәп... .

**10.** Сораулар куябыз.

... ? Мин авылда ял иттем. ... ? Син яхшы ял иттең. ... ? Ул өч ай ял итте. ... ? Без бакчада ял иттек. ... ? Сез күңелле ял иттегез. ... ? Алар безнең белән ял иттеләр.

**8.** Җавап бирәбез.

| Ка́я? | Ке́мнән? | Ке́мгә? |
|---|---|---|
| ашханә... | Роман... | Булат... |
| бакча... | Гүзәл... | Ләйсән... |
| урам... | Илдар... | Рәшит... |
| мәктәп... | Гөлназ... | Илшат... |

| Ка́йда? | Ка́йдан? | Ка́йчан? |
|---|---|---|
| өй... | бәйрәм... | сентябрь... |
| цирк... | стадион... | август... |
| мәктәп... | дәрес... | май... |
| урман... | өй... | июнь... |

... җыярга кирәк.

**7.** Укыйбыз һәм тәрҗемә итәбез.

> **шул** — тот (та, то), этот (эта, это)

Кем авырый, шул мәтрүшкә белән чәй эчә. Кем еш авырый, шуңа чыныгырга кирәк. Кем спорт белән шөгыльләнә, шул кеше сәламәт була. Әни нәрсә әйтә, мин шуны эшлим.

**8.** Искә төшерәбез.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Минем | апам | абыем | энем |
| Синең | ... | ... | ... |
| Аның | ... | ... | ... |
| Безнең | ... | ... | ... |
| Сезнең | ... | ... | ... |
| Аларның | ... | ... | ... |

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. А. Гыйниятуллина төзегән 3 нче сыйныф өчен дәреслек:

**5. Исеңә төшер! Вспомни!**

**Кем?** (кто?) – син, сез
**Ке́мне?** (кого?) – сине́, сезне́
**Ке́мгә?** (кому?) – сиңа́, сезгә́

**6.** Найди подходящие рисунки к предложениям: **Сине́ котлы́йм! Сезне́ котлы́йм!** Чем они отличаются?



**9. Исеңә төшер! Вспомни!**

| Ка́я? – Куда? | Ка́йда? – Где? | Ка́йдан? – Откуда? |
| --- | --- | --- |
| -га/-гә<br>-ка/-кә | -да/-дә<br>-та/-тә | -дан/-дән<br>-тан/-тән<br>-нан/-нән |

**10.** Марат нишли?

**4. Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **миңá** — мне | **кирәк** — надо |
| **синá** — тебе | **кирә́к тү́гел** — не надо |
| **аңá** — ему (ей) | **кирә́кми** — не надо |

**5. Исеңдә калдыр!**



**үзé́м** – сам(а)

Мин **үзé́м** эшли́м. – Я сам(а) делаю.

Син **үзé́ң** эшли́сең. – Ты сам(а) делаешь.

Ул **үзé́** эшли́. – Он (она) сам(а) делает.

Ф. Ф. Харисов, Ф. М. Хисамова, Ч. М. Харисова төзегән 3 нче сыйныф өчен татар теле дәреслеге:

**208.** Шигырьне укы. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә керүен әйт.

## Сыерчыктан хәбәр килгән

Сыерчыктан Вилгә
Телеграмма килгән.
— **Сезгә** кунак булып
Киләм, дигән, тиздән.

Шунда тудым **мин** дә —
**Син** ясаган өйдә.
Әллә шуңар инде,
Бик барасым килә.

Бик сагындым **сезне**,
Якты йөзегезне.
Каршы аласыз шул
Бик яратып **безне**.

*Бари Рәхмәт*



*Син, без, сез* алмашлыкларын кертеп, җөмләләр яз.

Алмашлыклар төрле сүз төркемнәрен алыштырып киләләр.

*Мин, син, ул, без, сез, алар* — зат алмашлыклары.

*Мин, без* — I зат алмашлыклары, алар сөйләүче кешеләрне белдерә.

*Син, сез* — II зат алмашлыклары, алар тыңлаучы кешеләрне белдерә.

*Ул, алар* — III зат алмашлыклары, алар аның турында сүз барган кешеләрне яки предметларны белдерә.

**209.** Укы, зат алмашлыкларын тап. Алар ничәнче зат алмашлыклары, шуны әйт.

Кыш көне мин Рәшитне очраттым. Аның аягында бик матур чаңгы, кулында камыш таяклар иде.

— Бу — спортчылар чаңгысы, бик беләсең килсә! — дип мактанды ул. — Абыем бүләк итте. Шомалыгын күр син аның! — һәм ул, кош кебек очып, таудан төшеп китте.

Яз көне мин Рәшитнең өенә бардым. Теге матур чаңгылар өй артында балчыкта ята. Камыш таякның берсе бөтенләй күренми.

— Нигә алып куймыйсың, әрәм булалар бит... — дидем мин, гаҗәпләнеп.

— Хәзер миңа чаңгы кирәкми. Велосипед вакыты җитә. Тик чылбыры тутыккан әле, — дип сөйләнде Рәшит.

*Хәләф Гарданов*

Нокталар урынына тиешле алмашлыкларны яз.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *мин* | *без* |
| II зат | ... | ... |
| III зат | ... | ... |

Калын хәрефләр белән бирелгән алмашлыкларга сораулар куй.

— **Сиңа** ничә яшь?
— **Миңа** тугыз яшь, ә **сиңа**?
— **Миңа** ун яшь.
— **Синең** кечкенә сеңлең ничә яшьтә?
— **Аңа** дүрт яшь.
— **Минем** сеңлем инде мәктәптә укый, **аңа** җиде яшь.